МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№10 / октябрь 2013

ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ

Болгар хәрабәләренең гомуми күренеше.
XIX гасыр. Билгесез автор

МИРАС
ЧЫН
ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ
№10 (22)/октябрь 2013

12 +

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

Баш мөхәррир —
Илфак Мирза улы ИБРАҺИМОВ
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары — җаваплы сәркатип —
Рамил ХАННАНОВ
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов
Разил Вәлиев
Резеда Ганиева
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Дания Заһидуллина
Илдус Заһидуллин
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Данил Мостафин
Рөстәм Мөхәммәдиев
Рафыйк Мөхәммәтшин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Индус Таһиров
Рамил Ханнанов
Рафаил Хәкимов
Әнвәр Хуҗиәхмәтов

Бүлек мөхәррирләре:
Илдус ЗАҺИДУЛЛИН
Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы —
Диләрә НӘҮРҮЗОВА
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректорлар:
Дания ФӘЙЗУЛЛИНА
Алия МӨБАРӘКШИНА
(843) 222-09-83 (17-90)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

Заказ №С-2257
Тираж — 2000 данә.
Формат 70 x 108 1/16
Басарга кул куелды: 02.10.2013
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Бәясе ирекле

Эчтәлек

ТАРИХ

4 **Үзенә тарта серле Болгар җире...** *Ленар Гобәйдуллин*
9 **Тарихыбызга гаид.** *Ризаэддин Фәхреддин*
14 **Болгар хәрабәләрендә.** *Гали Рәхим*
20 **Казан аксөякләре сәяси көрәшенең историографиядә һәм рус чыганакларында чагылышы.** *Максим Моисеев*
35 **Кеше.** *Саҗидә Сөләйманова*
36 **Кәшшаф Мохтаров — беренче суверенитет «атасы».** *Рәмзи Вәлиев*
43 **Әкъдәс Нигъмәт Куратның тәрҗемәи хәле һәм фәнни-педагогик эшчәнлеге.** *Фазыл Шәрәфетдинев*
46 **Китаплар арасында.** *Әкъдәс Нигъмәт Курат*
48 **Без — «бер Ана-йортның балалары».** *Хатыйп Миңнегулов*
54 **Әкъдәс Нигъмәт Курат хезмәтләрендә Алтын Урда тарихы.** *Илнур Миргалиев*

ӘДӘБИЯТ

60 **Йосыф Баласагунының «Котайткыч белек» әсәре — татар телендә.** *Рифкать Әхмәтҗанов*
65 **Кутадгу билик.** *Йосыф Баласагуни*
74 **Кылдан нәзек, кылычтан үткен.** *Аяз Гыйләҗев*
81 **Хатлар булып калган хатирәләр.** *Рөстәм Төхфәтуллин*
86 **Рәшид Рәшидов.** *Айдар Хәлим*
98 **«Толстой да белгән Мулла илен...»** *Тәлгат Галиуллин*
100 **Мине игелекле мөселман дип санавыгызны үтенәм.** *Равил Сәйфетдинов*
102 **Олуг шәһәрдә кунакта.** *Рухия Ахунҗанова*
110 **Тукай энциклопедиясенә.** *Айсылу Садыйкова*

БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ

114 **Корбан гаете.** *Нияз хәзрәт Сабиров*

120 **Яңа китаплар.** *Алия Мөбарәкшина*

Безнең журналга
54132 ИНДЕКСЫ
буенча Татарстанның һәм
70275 ИНДЕКСЫ
буенча Россия төбәкләренең
һәр элемтә бүлегендә язылырга
мөмкин.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-49398 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция хезмәткәрләренең фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.
Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.
Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Тышлыкның 1 нче битендә —
Казан. XVI гасыр.
Ф.Халиков рәсеменнән фрагмент

Бу санда авторларның архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

«Истинное наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Тарих

Гасырлар юган барын да –
кем каны кем канында.
Яралган җаннар –
яралы
бер тарих карынында.

Сәҗидә Сөләйманова

ҮЗЕНӘ ТАРТА СЕРЛЕ БОЛГАР ҖИРЕ...

ЛЕНАР ГОБӘЙДУЛЛИН,
Казан (Идел буе) Федераль университетының татарны өйрәнү кафедрасы аспиранты

«Үткән хәлләрне онытмау ахирәт тормышын искә төшерүгә сәбәп буладыр».
Ризаэддин Фәхреддин

БОЛГАР ШӘҺӘРЛЕГЕ ТАРИХНЫҢ АЕРЫМ ДӘВЕРЛӘРЕНДӘ КЕМНӘРНЕ ГЕНӘ КЫЗЫКСЫНДЫРМАДЫ ИКӘН? ҺӘМ, ИҢ МӨҺИМЕ, БУ КЫЗЫКСЫНУ ТӨРЛЕ БУЛГАН. КЕМНӘРДЕР АҢА НИБАРЫ ТАШ ӨЕМЕ ДИП КЕНӘ КАРАГАННАР, ШӘҺӘРЛЕКТӘГЕ ТАШЛАРНЫ ЙОРТ, ЧИРКӘҮ, КАРАЛТЫ-КУРА ТӨЗЕЛЕШЛӘРЕНДӘ ФАЙДАЛАНГАННАР. Ә КАЙБЕРӘҮЛӘР БУ ЯДКӘРЛӘР АША ҮЗЛӘРЕНЕҢ ҮТКӘН ШАНЛЫ ТАРИХЛАРЫН ИСКӘ ТӨШЕРЕРГӘ, БИРЕГӘ КИЛЕП, АТА-БАБАЛАРЫ РУХЫНА БАГЫШЛАП ДОГАЛАР КЫЛГАН.

Галимнәр, фәнни ачышлар ясыйм, тарихтагы кара тапларны бетерәм дип, бу җирләрне казыса, «кара археологлар» исә, кесә ягын калынайту өчен, алтын-көмеш эзләгән. Шәһре Болгар Идел буйлап йөзеп барган сәяхәтчеләрне дә җәлеп иткән. Күп кешеләр өчен Болгар җире җан сихәте, дәва чыганагы да булган…

Шәһре Болгар ядкәрләрен тасвирлау турында беренче указ XVII гасырның икенче яртысында патша Фёдор Алексеевич (1661-1682) тарафыннан имзалана. 1712 елдан соң шәһәрлек территориясенә, Пётр I указы нигезендә, православие монастыре төзү нияте белән килгән дьяк Андрей Михайлович тарафыннан беренче мәртәбә 70ләп тарихи бина хәрабәләре тасвирлана. Тиздән шәһәрлекнең үзәгенә — элеккеге җәмигъ мәчете һәм хан сарае урынында монастырь да төзелә. Сакланып калган тарихи биналарны, шул исәптән төрбәләрне, монахлар хуҗалык максатларыннан файдаланалар, ә Көнчыгыш төрбәдән «Изге Николай чиркәве» ясап куялар. 1732 елда бай Казан сәүдәгәре Мехляев тарафыннан монастырь өчен «во имя Успения Богоматери» чиркәве төзелә. 1764 елда монастырь ябыла, ә аның бистәсе Успенское авылы, соңрак Болгар авылы дип атала башлый.

Мәгълүм булганча, император Пётр I 1722 елда, хәрби походка барганда, Болгар шәһәрлегендә туктала. Ул таш биналарны һәм каберташларны саклау, алардагы гарәби һәм әрмән имлясындагы эпитафик язмаларны укып тасвирлау турында әмер бирә. 1767 елда Болгар хәрабәләре Екатерина II нең игътибарын җәлеп итә. XVIII гасыр — XX йөз башларында Болгарны сәяхәтчеләр,

галимнәр, язучылар, шагыйрьләр, журналистлар, җәмәгать эшлеклеләре зиярәт кыла. Арада П.С.Паллас, И.И.Лепёхин, Ф.И.Эрдман, М.С.Рыбушкин, И.А.Второв, Э.П.Турнерелли, И.Н.Березин, Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, Г.Әхмәров, Р.Фәхреддин, Г.Рәхим кебек шәхесләр бар. Аларның күбесе Болгар шәһәрлеге һәм аның архитектура ядкәрләре, археологик казылмалары турында тәфсилләп язып калдырган, белемнәрен фәнни, әдәби, публицистик хезмәтләрендә файдаланган.

Болгар шәһәрлегендә археологик казу эшләре 1860-1870 елларда башланып китә. 1864 елда танылган шәрык белгече һәм археолог В.Г.Тизенгаузен биредә казу эшләрен башлый. 1877 елда Казан каласында төбәкнең тарихи, мәдәни мирасын өйрәнүдә мөһим вакыйга — Россиянең IV археологик съезды була һәм анда Болгар шәһәрлеге ядкәрләрен даими күзәтүгә алырга кирәклеге искәртелә. Шул ук елда съездда катнашучы В.В.Радлов, Л.К.Ивановский, Б.И.Поповский, Э.Д.Пельцам тарафыннан ике атналык казу эшләре оештырыла. 1878 елда Казан университеты каршында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте оеша, һәм әлеге ядкәрләр язмышы 1917 елга кадәр шушы оешма белән бәйле була. Әйтик, аңа 1880 елда Болгар хәрабәләре урнашкан 862 кв. сажин җир, 1881 елдан, борынгы тарихи-мәдәни ядкәрләрне саклау һәм тәртиптә тоту өчен, дәүләт казнасыннан ел саен 300 сум акча бүленеп бирелә. 1888 елда бирегә каравылчы-сакчы куела, ә тарихи биналар агач киртә белән уратып алына, хәтта табылган ядкәрләр нигезендә Кара пулатта музей да оештырыла. Болгар шәһәрлеге 1880 елда Н.М.Малиев, Н.Ф.Высоцкий, 1887 елда И.И.Ващук, В.В.Глинский, 1892 елда А.А.Штукенберг, И.А.Износков, Ф.Г.Мищенко, Н.А.Фирсов, И.Н.Смирнов, 1893 елда П.А.Пономарёв, И.Н.Смирнов, А.И.Александров кебек археологлар тарафыннан берникадәр казылса да (алар эшләгән эшләрнең барысы да фәнни әсәрләрдә чагылыш тапмаган), Р.Фәхреддин язганча, «асыл шәһәр урыны әһәмият вә дикъкать илә тәфтиш ителми». Биредә беренче зур масштаблы археологик эзләнүләр 1913-1915 елларда Россия Халык мәгарифе министрлыгы акчасына (археологлар П.И.Кротов, М.М.Хомяков, Л.К.Ильинский, М.Г.Худяков, С.И.Покровский, Б.Е.Крелленберг, В.Ф.Смолин) үткәрелә. Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте тарафыннан 1884, 1885, 1889, 1896 һәм 1905 елларда тарихи биналарны төзекләндерү һәм чистарту эшләре башкарыла. XX йөз башында Болгарда булган Р.Фәхреддин «Бу хәрабәләр дә көннән-көн бозылып вә югалып торадыр. Шулай итеп, моннан берничә еллар соңгында бу урында бер өем кирпеч илә куркыныч урның үзеннән башка бернәрсә дә күрелмәячәк (Р.Фәхреддин. Тарихыбызга гаид // Шура. — 1912. — №22. — Б.678). ...Руслар да ташларын, вә кирпечләрен үзләренең кирәкләренә ташып куярлар» (Шунда ук. — Б.680), — дип ачынып яза. Дөрестән дә, бу төзекләндерү сизелерлек дәрәҗәдә булмый, чөнки Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең тарихи һәйкәлләрне тиешле дәрәҗәдә кайгыртырга матди мөмкинлеге нык чикләнгән була, шәһәрлек, аеруча аның әлеге фәнни оешма карамагына бирелгән территориягә кермәгән бина калдыклары талана, җимерелә бара.

Революциядән соң, Болгар шәһәрлеген саклау Татар мәгариф халык комиссариатының Гыйльми үзәге каршында 1919 елның августында ачылган музей эшләре һәм тарих, сәнгать, табигать ядкәрләрен саклау бүлегенә йөкләнә. 1923 елда бу бүлек музей комиссиясе итеп үзгәртелә. Шул вакыттан башлап музей комиссиясе ТАССР территориясендәге барлык тарих, сәнгать, архитектура, сынлы сәнгать ядкәрләре сакланылышына җавап бирә башлый. 1919 елда Болгарда музей оештырыла, 1923 елда Болгар шәһәрлеге төбәк дәрәҗәсендәге тарихи-мәдәни тыюлык дип таныла, шул ук елда тарихи ядкәрләрне төзекләндерү планы төзелә һәм 1926 елда әлеге план гамәлгә

ашырыла. Нәтиҗәдә, Кече манарада, Хан сараенда, Төньяк һәм Көнчыгыш төрбәләрдә, җәмигъ мәчетендә, Кара пулатта төзекләндерү эшләре башкарыла. 1934 елда Болгар авылының, борынгы шәһәрлекнең барлык мәйданы вал белән әйләндереп алына һәм «кагылгысыз тыюлык» дип игълан ителә. 1938-1940, 1945-1949 еллардан Болгарда археолог А.П.Смирнов җитәкчелегендә (СССР ФАнең Матди мәдәният тарихы институты һәм Дәүләт тарих музее, ТАССР дәүләт музее) системалы рәвештә максатчан археологик казу эшләре башлана. Ел саен археологлар яңа әйберләр табалар, б.э.ның беренче меңьеллыгында болгарларга кадәр үк бу территориядә яшәгән кабиләләрнең эзләрен ачыклыйлар. Бу эзләнүләр Бөек Ватан сугышы елларында гына туктап тора, ә 1945 елдан кабат дәвам итә. 1950-1954 һәм 1957 елларда А.П.Смирнов җитәкчелегендә СССР Фәннәр академиясенең (Дәүләт тарих музее һәм ТАССРның дәүләт музее катнашында) Куйбышев археологик экспедициясе, Куйбышев сусаклагычы төзелү нәтиҗәсендә, су астында калачак мәйданнарны — Идел буе террасасын һәм Ага базар урынын тикшерә. 1964 елда Болгарда янәдән А.П.Смирнов җитәкчелегендә Идел буе экспедициясе (СССР ФА Археология институты, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Дәүләт тарих музее) эшли. 1960 еллардагы эзләнүләрнең төп юнәлеше — шәһәрлектәге архитектура һәйкәлләрен төзекләндерер өчен, аларны археологик яктан өйрәнү була. Шул ук елларда С.С.Айдаров җитәкчелегендә тарихи ядкәрләрне реставрацияләү һәм консервацияләү эшләре башланып китә. Урта гасыр татар тарихына кагылган бу катлаулы, масштаблы тикшеренүләр, реставрация һәм тарихи һәйкәлләрне саклау эшләре уңышлы башкарылсын өчен, 1962 елда Болгарда тарих-архитектура музее оештырыла, 1969 елда бу музей «Болгар дәүләт тарих-архитектура тыюлыгы» дигән статус ала. Музеефикация һәм туризмны үстерү өчен киң мөмкинлекләр ачыла. 1970-1990 елларда Болгарны өйрәнүдә археологлар Г.А.Фёдоров-Давыдов, Т.А.Хлебникова, Л.А.Беляев, В.С.Баранов, Н.Д.Аксёнова, М.М.Кавиев, Р.Ф.Шәрифуллин, М.Д.Полубояринова, Г.Ф.Полякова, Н.А.Кокорина, Җ.Г.Мөхәммәтшин, А.М.Гобәйдуллин һ.б. тарафыннан зур эшләр башкарыла: Болгар шәһәрлегенең культура катламнары өйрәнелә, биредә яшәгән халыкларның игенчелек, терлекчелек, һөнәрчелек, хәрби эшләре, архитектура һәм сынлы сәнгате, гореф-гадәтләре турында саллы мәкаләләр-монографияләр языла, өлешчә реставрация, концервация эшләре башкарыла, архитектура ядкәрләре төзекләндерелә. 1995 елда Болгар шәһәрлегенә федераль дәрәҗәдәге тарихи-мәдәни ядкәр статусы бирелә.

2010 елның 17 февралендә Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев тарафыннан Болгар тарих-архитектура музей-тыюлыгын, «Зөя утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музеен, ТР территориясендә урнашкан башка тарихи-мәдәни истәлекләрне торгызуга һәм үстерүгә, ТР күпмилләтле халкының тарихи, мәдәни, рухи традицияләрен, татарларның милли-мәдәни үзенчәлеген һәм традицияләрен саклап калу һәм үстерүгә ярдәмне оештыру, шулай ук моның өчен кирәкле финанс ресурсларын җәлеп итү максатында, Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фондын төзү турында указ имзалана. Әлеге фондның төп бурычлары булып: 1) Болгар тарих-архитектура музей-тыюлыгын саклап калуга, торгызуга, реставрацияләүгә, «Зөя утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музеен, тарихи, археологик, архитектура, шәһәр төзелеше, сәнгати, эстетик, этнологик яки антропологик, социаль мәдәният күзлегеннән карaганда, кыйммәткә ия дип табылган башка мәдәни байлыкларны архитектура-художество ягыннан торгызуга булышлык күрсәтү; 2) мәдәни мирас объект-

Хан төрбәсе һәм Кече манара. Бертуган Чернецовлар рәсеме. XIX гасыр

ларын популярлаштыру; 3) Татарстан Республикасының фәнни, мәдәни, интеллектуаль потенциалын булдыруга булышлык күрсәтү тора. РФ Президенты В.В.Путин һәм ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов фатихасы белән «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы шәһре Болгар һәм Зөя утрау-шәһәре» исемле федераль һәм республика казналарыннан финанаслана торган программа кабул ителә. Проектның бер өлеше хәйриячелек ярдәмендә финанслана. Шушы программа кысаларында Болгарда — 30, Зөядә 31 объектта киң масштаблы реставрация, төзелеш эшләре башкарыла, заманча методлар кулланып, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Казан (Идел буе) федераль университеты, РФАнең Археология институты белгечләре тарафыннан археологик казу эшләре алып барыла. Бүгенгә ислам динен 922 елда рәсми кабул итү вакыйгасына багышлап төзелгән Истәлек билгесе бинасы, сәхабәләр җирләнгән урында мемориаль истәлек билгесе. Ак мәчет-мәдрәсә, Габдрахман сәхабә коесы комплекслары, Икмәк, Табиб музейлары, Елга вокзалы (шунда ук Болгар цивилизациясе музее), Халыкара археология үзәге, палаткалы лагерь төзелде, берничә архитектура ядкәре концервацияләнде.

XX гасыр башында Болгар шәһәрлегендә булган татар әдипләре, галимнәренең истәлекләре тарихи һәйкәлләрнең торышын да, ул заман кешеләренең биредәге ядкәрләргә мөнәсәбәтен дә, авторларның күргәнтойганнары тәэсирендә туган уй-фикерләрен дә чагылдыра. Мәшһүр татар дин галиме, «Шура» журналының нашире Ризаэддин Фәхреддин үз гомерендә Болгарга берничә тапкыр килә, шундый сәяхәтләренең берсендә хәтта андагы хәрабәләрнең халәтен күреп, тәэсирләнеп елап та җибәрә. Галим үзе бу турында түбәндәгеләрне искә ала: «Әүвәл сәфәрем булдыгы җәһәте илә Болгар урынында булган рус карьясендә мөҗавирлек [кабер сакчысы] дәгъвасын иткән бер картны үземә юл күрсәтүче сыйфаты илә алырга мәҗбүр булдым. Бер микъдар йөрдегебез соңында, бер иске бина хәрабәләрендә үземне забыт итә [җиңә] алмаярак күзләремнән яшь бушалды. Карт та бу хәлгә бик гаҗәпләнде вә, ниһаять: «Сәхабәләр кабере янында егламадыгың хәлдә, таш егындыгы янында егларсың, үзең бер укымышлы адәм кеби күрелерсең, шулай да, каберләргә утырып, Коръән укымадың, кул күтәреп дога итмәдең, ялгыз руслар кеби аяк үзрә басып тордың да киттең!» — диде». (Р.Фәхреддин. Үзебезгә гаид // Шура.

— 1908. — №3). Р.Фәхреддин Болгар хәрабәләре янына каберләрдә гыйбадәт кылу, әрвахлардан ярдәм сорау өчен түгел, ә үткәннән гыйбрәт һәм тарихтан сабак алыр өчен барырга өнди.

Р.Фәхреддин «Шура» журналында «Тарихыбызга гаид» исемле мәкаләләр циклын бастра. Анда болгарларның килеп чыгышы, дәүләт төзелеше, һөнәрчелеге, сәүдә әйләнеше турында бай мәгълүмат бирелгән. Игътибарыгызга шушы цикл астында журналның 1912 елгы 22 нче санында басылган «Болгарларның пайтәхете булган Болгар шәһәре» исемле мәкаләне тәкъдим итәбез. Язмада галим Болгар шәһәрендә сакланып калган хәрабәләрне шул чордагы археологик әдәбиятка һәм үз күзәтүләренә нигезләнеп тасвирлый, аларның юкка чыга бару сәбәпләрен хуҗалык максатлары өчен талануда һәм «заман үтү сәбәбеннән» күрә. Р.Фәхреддин бу ядкәрләрне алтын хәзинәләренә тиң күреп саклау һәм шәһәрне археологик җәһәттән җентекләп тикшерү кирәклеге мәсьәләләрен күтәрә.

Язучы, әдәбиятчы Гали Рәхимнең «Болгар хәрабәләрендә» исемле мәкаләсе Казан каласында дөнья күргән «Аң» журналының 1914 елгы 15 нче санында басыла. Әдәбият галиме Дания Заһидуллина язуынча, әлеге әсәр әдәби һәм тарихи-публицистик катламны берләштерә, мәкаләдә «тарихи мәгълүмат белән хикәяләүченең әдәби формага төреп бирелгән мөнәсәбәте янәшә урнаша». (Заһидуллина Д. Кереш сүз // Г.Рәхим. Сайланма әсәрләр. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. — Б.32). Әдәби катламны романтик сюжет сызыгы тәшкил итсә, тарихи-публицистик катламда исә Болгар хәрабәләре тасвирлана һәм борынгы төрки тамырлардан килгән мәҗүсилек йолалары күзәтелә, Казан университеты каршындагы Тарих, археология һәм этнография җәмгыяте тарафыннан куелган хәрабәләрне рәсми сакчы (мөҗавир) һәм үз кесәсен генә кайгыртып йөрүче рәсми булмаган сакчы турында сөйләнелә. Әмма авторны иң тәэсирләндергәне — элеккеге ислам башкаласы булган Болгарга халыкның борынгы мәҗүси йолаларны башкарырга килүләре. Биредә халык еш кына куллары белән кабер ташларын сыпырган да аннан соң битләрен сыпырган, әүлия кабеpенә барып, теләкләр теләп дога кылган, Габдерахман сәхабә коесы янында әтәчләр суйган. Автор, тәэсирләнеп: «Татар-болгар балалары әле дә үзләренең моннан мең ел элеккеге диннәре фетишизмын онытып бетермәгәннәр икән», — дип яза. Шунысы кызык: Гали Рәхим узган гасыр башында ук Болгар шәһәрендә күзәткән мәҗүсилек йолаларының кайберләре халкыбыз арасында хәзер дә сакланып калган, һәм музей-тыюлыкка килгән кешеләр бу гадәтләрне әле дә башкаралар.

Г.Рәхимне Казан университеты каршындагы Тарих, археология һәм этнография җәмгыяте тарафыннан биредәге һәйкәлләрне саклар өчен махсус куелган кешегә аз хезмәт хакы түләнүе гаҗәпләндерә. Хикәянең башында ап-ак сакаллы, күзләре начар күрүче картның һәйкәл ачкычларын кулында бик «нык тотуы» язылса да, азакка таба, хәрабәләрнең биналары Успенское авылы рухание карамагында булуы, ә сакчының аның кул астында хезмәтче генә булуы ачыклана. Өстәвенә ишан кебек күренгән картның укый яз-белмәве, тарихи һәйкәлләр турында хәбәрдар булмавы ачыклана. Аңа капма-каршы булган образ — рәсми булмаган мөҗавир сезон вакытында гына килеп-китүче хәйләкәр казан татары. Гомумән, Гали Рәхим, Болгарга садака җыярга гына килүче карт сукыр суфиларның күп булуы турында яза. Бу ике мөҗавир образы аша автор, Болгар шәһәренең тарихи ядкәрләр саклана торган урын булудан бигрәк, эшләмичә, гамәл кылмыйча гына хәер җыйнап яту урынына әверелгәнлеге турында сызланып яза.

Гомумән алганда, әлеге укучыларыбыз игътибарына тәкъдим ителә торган татар зыялылары язмалары һәр кешегә үткәнгә әйләнеп карап, уйланырлык мәгълүмат бирә. ■

ТАРИХЫБЫЗГА ГАИД

(өзек)

РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН

БОЛГАРЛАРНЫҢ ПАЙТӘХЕТЕ БУЛГАН БОЛГАР ШӘҺӘРЕ

Болгар мәмләкәтенең пайтәхет шәһәре Волгадан дүрт чакрым читтә [1] вә этрафы хисар (имән койма булса кирәк) илә ихата иттерелмеш Болгар шәһәре иде. Шәһәрнең эчендә берникадәр агач йортлар вә болардан башка һәм тирмә вә чатырлар булыныр иде [2].

Болгар кавемнәре күбесенчә кыш көннәрендә шәһәрдә торып, җәй көннәрендә тирмәләре илә күчеп йөрерләр иде.

Ошбу пайтәхет Болгар шәһәренә Багдадтан иң элек мәртәбә хәлифә илчеләре килдекләрендә ун мең кадәр җан [3] хисабы булмыштыр. Хәлбуки, ул гасырларда ун мең җан булган шәһәрләр дөньяның бөек шәһәрләреннән саналыр иде.

Ошбу мәдәният вә гыйлем мәркәзе, сәүдә тугрысында Аурупа илә Азия арасында васиталык [арадашлык] хезмәтен итеп тормыш бөек шәһәрнең бу көндә бары тик хәрабәләре калмыштыр. Бу хәрабәләр дә көннән-көн бозылып вә югалып торадыр. Шулай итеп, моннан берничә еллар соңгында бу урында бер өем кирпеч илә куркынычлы урның үзеннән башка нәрсә күрелмәячәк.

Хәзер бу шәһәр урынында Болгар яки Успенское исемендә булган рус карьясенең йөз елдан әүвәл тордыгы риваять ителер [4].

Шәһәрнең астындагы бөтен җирләр үткән гасырдан Успенский монастыре милкендә булмыш. Ошбу монастырь ни вакыт вә кемнәр тарафыннан инша ителдеге [төзелгәнлеге] вә бу җирләрнең аның кулына кем вә ни тарикъ [юл] илә биреллдеге хакында мәгълүмат юктыр.

Хәзерге чиркәү янында Болгар шәһәреннән ядкәр буларак таш бер өй (сарай) калмыш вә бу өй Болгарда булган башка өйләр планы буенча салынмыштыр [5].

Болгар шәһәре бигрәк тә XIV гасырда бозылмыш вә шуннан соң һаман бозыла килмештер. Фәкать бу бозулар чит кавемнәр һөҗүменнән түгел, бәлки заман үтү сәбәбеннән иде.

Болгар тирәсендә булган хисарның бу көндә эзе бар. Мондый шәйләрнең гыйлемнәрен белүче мөтәхассыйсләр [белгечләр] фикеренә күрә, мәзкүр хисар бик зур булып, бер башы Волгага барып тоташмыш, Волга да шәһәр ихатасының читеннән акмыш, имеш.

Хисар эче тәкърибән [чама белән] өч ярым мөрәббәгъ (кв.км.) булып, эчендә 520гә кадәр өй бар иде. Моннан башка читләрдән килмеш сәүдәгәрләрнең вә әшья [әйбер] алмаштырырга ерактан килүчеләрнең малларын куячак җирләр вә үзләре өчен йөзләр вә меңнәр илә чатырлар корырлык урыннар булмыштыр. Читтән килеп Болгар шәһәре эчендә чатыр корып ятучы ошбу сәүдәгәрләр болгар падишаһына ясак түләп торырлар иде.

Саф [рәт-рәт тезелеп] илә сугышырга кулай булсын өчен, ошбу биек хисарның почмагы киселгән, аның алдындагы хисар (кальга) җире хәзер дә сәламәттер. Моның исеме халык телендә городище, ягъни кальга исеме белән йөртелер. Ошбу хисар (кальга) исә мөхарәбә [дошман белән сугышу]

өчен ясалып, эчендә икенче бер хисар һәм ур вә бәгъзе бер урында таш илә әйләндерелмеш яңадан бер кремль урыны булдыгы искә алыныр.

Бу иске заман әсәрләрен, борынгы халыклардан вә ошбу мәмләкәтне башлап гыйлем вә мәдәният илә тәгъмир кылучы [коручы] кавемнәрдән калмыш газиз ядкәрләрне алтын хәзинәләреннән күреп, дикъкать вә игътибар илә сакларга тиешле булдыгы хәлдә, моңга лязим дәрәҗәдә тырышлык сарыф ителмәмеш вә бу тарихи әсәрләрнең кыйммәтләре тәкъдир ителмәмештер. Кирпеч вә башка нәрсәләр шундагы халыклар тарафыннан йортларга ташылып, пич вә учаклар салынып тордыгы риваять кылынадыр.

Бу мөбарәк шәһәр әгәр дә гыйлемгә рәгъбәтле [сәләтле] бер халык тарафыннан забыт ителеп [яулап алынып], аларның мәмләкәтләре эченә кермеш булса иде, бу кадәр харап вә бу кадәр байгыш оясы булып калмас иде. Бәлки һәр тарафтан унар чакрым җирдән ур илә ихата ителеп, кирпеч түгел, балчыкларына кадәр сакланыр вә өсләрендә дуңгызлар илә «Ызнаком капичка!» дип кычкырып йөрүче касавәтле [рәхимсез] теләнчеләрдән таптатмаслар иде. Рус мөхәррирләреннән бере: «Озерецковский [6] килдеге вакыт, Болгар кальгасы эчендә дүрт урында хәрабә булмыш, Риттих [7] килдеге вакыт ялгыз ике урында гына булмыш, әмма без үзебез ялгыз берне генә күрдек, ул да булса казылып, бозылып бетмеш иде», — диде.

Әлеге хәрабаләр элек вакытта берничә кальгалар булып, агач капкалар өстеннән арка илә бер-беренә тоташтырылмыш һәм дә бу капкалар каршысында шәһәргә керер өчен ур аркылы күпер куелмыш, имеш.

Урның ар ягында яңадан бер имән хисар булдыгы искә алыныр. Моны исә 1136 милядидә (һиҗри илә 531 яки 532дә) Болгар шәһәрен күрмеш Әбү Габдулла [8] әйтәдер. Әгәр дә мондый хисар булмаса иде, мондый озын урны, аеруча аның төн тарафын сакламак мөшкел булыр иде.

Болгар шәһәрендә зур ядкәр булып калмыш биналардан кара сарай, ак сарай, кечек манара исемендә биналар бар [9]. Кара сарайга [10] хөкем сарае дип тә әйтерләр. Моның архитектурасы шулкадәр гүзәлдер ки, аның Русиядә булган иске биналарның иң яхшыларыннан идекендә шөбһә юк. Ошбу сарай болгариларның мәһарәтләрен [осталыкларын], бина гыйлеме тугрысында кәмаләтләрен күрсәтеп тормактадыр. Бу өйнең ни кеби эштә истигъмаль ителдеге [файдаланылганы] мәгълүм түгел. Халыклар мәзкүр йортта усал кешеләргә хөкем вә җәза ителер иде вә шуның өчен дә хөкем сарае дип мәгъруф булды [танылды], диләр. Өйнең тыштан кара күрелүе сәбәбеннәнме яки хөкем йорты булганнанмы, моңа кара сарай диярләр.

Ошбу өй дүрт катлы булып, өсте купол рәвешендә ябылмыш вә купол уртасы тишекледер. Түбән каты мөрәббәгъ [квадрат] шәкелдә нигез хөкемендә булып, һәр тарафның озынлыгы унҗиде аршин вә өч аршин биеклектәдер. Бинаның бер микъдары, заман үтмәк тәэсире илә булса кирәк, бераз җиргә батып торадыр. Ишеге шимал тарафыннан булып, ишек янында астан өскә таба килмеш ике кыек тиешекләр бар.

Халыкларның сүзләренә ышанмак җаиз исә [ышанырга яраса], ошбу ас катта мәхкүм [хөкем ителгән] вә гаеплеләр тордыгыннан, мәхкүмнәрнең тавышлары, зар вә моңнары хакимнәргә ишетелсен өчен, ошбу рәвештә ясалмыш, имеш. Гүя хакимнәр ошбу тишекләрдән мәхкүмнәрнең аһларын ишетәләр дә аларның эшләрен яхшы вә дикъкать белән, игътибар вә шәфкать илә тәфтиш итмәкләренә [тикшерүләренә] сәбәп буладыр.

Икенче катта өч ишек [11] вә баскычлары илә гайре катлардан тәмам аерым хөкемдә торадыр. Бу бүлмә җәнүб [көньяк] тарафындагы ишекнең ике ягында булган ике тәрәзәдән яктырадыр. Боларның һәр икесенең янна-

рында, юыначак савытларны куяр өчен булса кирәк, тишекләр бар [12].

Өченче каты [13] бик тәбәнәк (3/4 сажин микъдарында) булып, диварларында булган дүрт тәрәзәдән яктырадыр.

Дүртенче каты [14] өченче кат илә бертигез биеклектә булып, сигез почмаклы вә сигез тәрәзә илә яктырадыр. Ошбу сәбәптән бу каты бик яктыдыр. Халык телендә булган хәбәрләргә күрә, ошбу дүртенче катта махсус тәгаен ителмеш адәмнәр һәрвакыт нәүбәт [чират] илә шәһәрне вә шәһәрнең әтрафын карап торалар, имеш. (Монысы ут вә янгыннарны карар өчен булган урын түгелме икән?)

Ак сарай диелмеш өй архитектурасы да, археология игътибарынча, кара сарайдан түбән дәрәҗәдә түгелдер. Фәкать тәәссефтер [кызганыч] ки, хәзерге вакытта хәрабә хәленә килмеш [15] вә, аз көннәрдән соң харап булып, бер өем таш булып калачактыр. Моңа ак сарай димәкнең сәбәбе, төсе ак булдыгыннандыр. Бина шул җирдә чыкмакта булган ак таштан [16] бина булынмыштыр. Бу өй дә мөрәббәгъ [квадрат] шәкелдә булып, купол илә капланмыштыр. Почмакларында да үз рәвешендә башлары купол илә капланмыш кечек өйләр бар. Ошбу почмакта булган дүрт бүлмә уртада булганы илә ишекләр илә тоташмыштыр.

Ошбу ак өйнең астына ерак җиргә бармакта булган дүрт торба кергезелмеш идеге соң тәфтишләрдән [тикшеренүләрдән] мәгълүм булды. Ошбу трубаларның киңлекләре 1,5 фут булып, биеклекләре дә 2,5 футтыр. Ошбу трубалардан вә аларның тормыш вә юлларының рәвешләреннән мәзкүр бинаның мунча булганлыгын гөман иттеләр [ачыкладылар]. Фәкать мунча булдыгы сурәттә дә, гомуми мунча булмый, бәлки хосусый адәмнәр мунчасы булыр [17].

Бәгъзе бер кешеләр ошбу ак өйне мәсҗид булмыш, хәтта бу өйдә иске Һиндстан мәгъбәден [гыйбадәтханәсен] күрәбез дияр булсалар да, бер бинаның мөселман мәсҗиде вә браһман мәгъбәде арасында мөштәрәк [уртак] булмакы мөмкин түгелдер.

Элек вакытта Болгар шәһәренең астындагы җирдә зур чокырлар булмыштыр. Бу чокырларның су тутыра торган урыннар (бассейн) икәнлеген әйтерләр [18].

Бу шәһәр урынында нигез галәмәтләре илә өем-өем чүп булып кына калмыш хәрабәләр бик күп. Ошбу нигезләрнең бәгъзеләре дивар буенча икегә аерылмыш вә бәгъзеләре дә мөрәббәгъ [квадрат] шәкелдә булып, кальгалар нигезе булырга тугры киләдер.

Ошбу кальга вә манараларның хезмәтләре исә намаз вакытларында азан укымак вә ерткыч халыклар, аеруча русларның һөҗүмнәреннән сакланып тормак өчен каравылчылар тотмактан гыйбарәт булмыштыр [19].

Хәзерендә сәламәт булган манара вә аның тирәсендә булган хәрабәләргә күрә, Болгар шәһәренә кереләчәк җирдә өч мәсҗид илә өч манара булып, моннан башка биналар меллаларга махсус таш өйләр булырга тиешле [20].

Болгарның иң урта бер җиреннән бер микъдар шәрык тарафында бер өем хәрабәләр бар. Болар исә хан сарайларының хәрабәләре булса кирәк [21]. Ошбу хәрабәләрдән ерак түгел бер бина бар. Архитектурасына караганда, бу бина мөхарәбә [дошман белән сугышу] өчен хәзерләнмеш булачагы аңлашылса да, халык арасында асыл вә биек җамигъ булмагы илә мәшһүрдер. Җамигъ булуын бик биек манара хәрабәсе дә дәлиллидер. Ошбу манара бик күп заманнарга кадәр сәламәт торып, бары тик 1842 тарихында җимерелмештер [22].

Бу манараның биеклеге 83 фут булып, җимерелмәк ихтималы булдыгыннан, бөек Пётр заманында югары өлешен тимер кыршау илә кыршауламышлар иде. Манараның ишеге кыйбла тарафыннан булып, югары менмәк өчен эчендә 74 борылма баскычы булмыш-

тыр. Эче берничә тар гына тәрәзәләр илә яктырылмыш.

Бинаның дүрт почмагында ясалмыш кыйлялләрнең [кече манараларның] ишекләренә керелмәктә булган җирдә таштан юнып эшләнмеш баскычлар 1839 елда сәламәт булган. Ошбу бина хан сарайларыннан булганлыгы турында да мәзнун [уйланган]. Бина уртасында ошбу зур манараның булып торуы хан сарайлары булырга манигъ [яраклы] түгеллеген дәлилли.

Архитектурасы илә мәшһүр вә иске әсәрләрнең иң соңгысы — кечек манара. Моның янында да харәбәләр бар. Бәхеткә каршы, бу манара бик яхшы сакланмыш вә хәзергә кадәр бозылмамыштыр.

Бу манара шулвакытта булган манараларның бер үрнәге булып, төбе мөрәббәгъ [квадрат] шәкелдә һәр тарафы 6 аршин озынлыкта вә 4 аршин биеклектәдер. Ошбу төпкә (нигезгә) мәзкүр манара куелмыштыр. Өскә менгәндә, манараның даирәсе (әйләнәсе) кечерәядер. Биеклеге исә 28 фут булып, өстә булган мәйдан әйләнәсе бик аз, бары тик бер сажин биеклегендә икенче бер манарасы бар. Манараның эчендә борылма баскыч булып, шимал [төньяк] тарафыннан ясалмыш ишектән манараның эченә керелә вә аннан да борылма баскыч илә югары чыгыла.

Манара төбендә гареб [көнбатыш] тарафында чокыр сыман җир бар. Монда исә элек вакытларда Коръән (шәриф) аятьләре язылмыш бер таш булдыгы риваять ителәдер. Бу ташны кемдер алып заегъ итмеш [югалткан] булыр.

Манара түбәсе тимер илә ябылмыш вә иң өстендә матурлап ай рәсеме тормыштыр.

Шөһрәтле булган Багдад вә Һиндстан тарафларыннан бөек кәрваннар килеп йөрмәктә булган Бөек Болгар шәһәренең калмыш ядкәрләре ошбу шәйләрдер. Моннан беркадәр еллар үттегендә, ошбу ядкәрләр дә ватылырлар, тәләф [һәлак] булырлар, руслар да ташларын вә кирпечләрен үзләренең кирәкләренә ташып куярлар.

Озерецковский Болгарга килдеге вакыт 44 әсәр булдыгы хәлдә, бу көндә исә 3 кенә гадед калмыш вә алар да көннән-көн бозылырга вә егылырга торалар. Гәрчә археология һәм антропологиягә хезмәт итмәк нияте илә бәгъзе вакытларда тәфтиш [тикшерүләр] һәм казулар итмеш итсәләр дә, асыл шәһәр урыны әһәмият вә дикъкать илә тәфтиш ителдеге юктыр.

Күптән түгел генә Э.Д.Пельцам [23] исемендә бер зат казып, кара өй янында 15 вә бабий бугорда (әби түбәлеге) 34 данә адәм башы тапмыштыр. Боларның сөякәләре вә башлары шәрык тарафына карап ятмышлар [24], куллары да ике якка сузылмыш, имеш. Бәгъзе гәүдәләрнең башлары беркадәр читтә аерым булып, бәгъзе вакыт бөтенләй тоташ булырлар, имеш. Бәгъзе бервакыт ике-өч баш сөяге бер җирдә вә гәүдә сөякләре таралмыш хәлдә булмыш вә яки бөтен гәүдә сөякләре дә тапмыштыр. Ошбу сөякләр хакында фәнни тәдкыйклар [хезмәтләр] иҗарә ителмәдегеннән [язылмаганлыктан] нә кеби кавемнәр сөякләре булдыгы бу көнгә кадәр мәгълүм булмамыштыр.

Болгар шәһәре урынында хәзерендә Успенское исемендә рус авылы бар. Моннан 300-350 еллар мөкаддәм [элек] ошбу урында Казан ханлыгының зур бер касабәсе [кечкенә шәһәре] булыр иде. Аннан да мөкаддәм [әүвәл] ошбу җирдә Һиндстан, Бохара, Киев, Печора вилаятьләреннән [өлкәләреннән] килмеш сәүдәгәрләр илә, боланнар җигеп, тире сатар өчен җыелмыш төньяк халыклары берлектә сату-алу итеп, шаулап торырлар иде.

Кәрваннар илә килмеш гарәп вә бохаралыларны, Аурупа мәгълүматы китермеш русларны, таш бизәкләре өчен кулланачак нәрсәләр китермеш хәйләкәр юнанлыларны күрмеш — Болгар шәһәренең хәрабәләрен күрмәк инсан өчен гаять әсәрле бер шәйдер.

Болгарларның хәтта бу җирдә тимер

дәверләреннән мөкаддәм [элек] тордыклары бронза нәрсәләрнең күплегеннән дәлилләнер. Хәтта монда болгарлармы яки алардан башкалармы, мәгъдән истигъмален [тимер эшкәртә] белмәмеш вә һәрбер хаҗәтләре өчен таш истигъмал итмеш кавемнәр мәгыйшәт иттеге табылмакта булган әсәрләреннән мәгълүмдер.

Болгар урыны дикъкать вә һиммәт илә казылыр булса, бик күп әсәрләр табылачагы вә болар хакында күп мәгълүматлар булыначагы шөбһәсездер.

Болгар дәүләте тәэсис ителде [төзелде], дөньяда күпме-азмы яшәде, иң соңрада гомеренең сәхифәсе өзелеп, хәяте [тормышы] киселде, вафат итте, бетте. Фәкать хөкүмәт бетте исә дә, шул хөкүмәтне тәшкил итүче халыклар бетмәде, болар һәмишә [һаман да] сәламәтләрдер. Болгар төрекләре бу көндә Казан, Самара, Уфа, Оренбург, Вятка, Саратов вә Әстерхан вилаятьләрендә [губерналарында] яшәрләр.

Шура. — 1912. — №22. — Б.677-681.

Искәрмәләр

1. Бирелә XVIII-XIX гасырларда Болгар шәһәрлегенә иң якын торган Переволоки пристане күрсәтелә булса кирәк.
2. Р.Фәхреддин Әл-Бәлхи язмаларына таяна.
3. X йөзгә караган мәгълүмат.
4. Болгар-Успенское авылы XVII гасыр ахырында пәйда була дип фараз ителә. Авыл башта Болгар шәһәрлегенең аскы өлешендә урнашкан (хәзер су астында калды). XVIII йөз башында шәһәрлекнең өске өлешендә Успенский ирләр монастыре урнаша һәм аның янында монастырь бистәсе барлыкка килә. Монастырь 1764 елга кадәр эшли.
5. Успенский чиркәве янында Жамигъ мәчет һәм ике мавзолей сакланып калган. Бирелә кайсы һәйкәл турында сүз баруы аңлашылмый.
6. Озерецковский Николай Яковлевич — академик, сәяхәтче. Студент вакытта, 1768 елда, академик И.И.Лепёхин экспедициясендә катнаша; Болгар шәһәрлеге һәм аның сакланып калган һәйкәлләренә тулы тасвирлама бирә.
7. Риттих Александр Фед — географ, картограф, этнограф; 1869 елда А.М.Штраус белән Болгар шәһәренең һәм тарихи һәйкәлләрнең планнарын эшли.
8. Сүз Әбү Хәмид әл-Гарнати турында бара. Ул Болгар җирендә ике тапкыр — 1136, 1150 елларда була.
9 Р.Фәхреддин төньяк, көнчыгыш һәм хан төрбәләрен тасвирламый.
10. Бүгенгәчә сакланган әлеге һәйкәл Кара пулат дип атала.
11. Кара пулатның икенче ярусында 4 ишек.
12. Икенче ярустагы ишек янындагы уентылар язу әсбаплары һәм китаплар кую өчен эшләнгән дип фараз ителә.
13. Өченче ярус.
14. Кара пулат ике катлы, ул дүрт ярустан тора.
15. Һәйкәл XIX гасырның 60 нчы елларында җимерелә.
16. Шәһре Болгар урнашкан Иделнең сул ягында таш карьерлары юк, ул элек тә булмаган. Болгарлар биналар төзү өчен ак ташны Иделнең уң ягында урнашкан (хәзер Кама Тамагы районына кергән Сөйки авылы яны) карьердан алганнар.
17. Болгарда археологлар алты мунчаның нигезен казып тапты. Кайберләре белән туристлар да таныша ала. Галимнәр аларны җәмәгать мунчалары булуын ачыклады. Бу мунчаларда теләгән һәр кеше күпмедер акча түләп юына алган.
18. Р.Фәхреддиннең нәрсә турында сүз алып баруын аңлавы кыен. XVII-XIX гасырларда Болгарда известь заводлары эшләгән, Казандагы Крестовников сабын заводы өчен сөяк җыйганнар, төрле кыйммәтле әйберләр, акчалар эзләп чокыр казучылар да аз булмаган. Р.Фәхреддин әйткән чокырлар, бәлки, шуларның эзләредер.
19. Халык телендә Кече манара XVIII-XIX йөзләрдә пожар каланчасы ролен үтәгән дигән сүз йөри. Шулай ук археологлар шәһәр нигытмаларында агач манараларның нигезләрен тапты, ә Кече шәһәр манарасының бары тик каравыл манарасы икәнлеге расланды.
20. Болгарда кеше яши торган таш йортлар булуы билгеле түгел. Идән астыннан җылытыла торган кирпеч йортлар Болгар, Биләр, Сувар шәһәрләрендә табылды.
21. Бу бина археологлар тарафыннан ачылып, халыкка күрсәтер дәрәҗәгә китерелде. Алтын Урда ханнары Сарай шәһәрендә яшәгән. Болгар олысы белән Олыс бәге идарә иткән. Җамигъ мәчет кырында Бурашбәкләр мавзолее сакланган. Түбәндә Җамигъ мәчетнең манарасы турында сүз бара.
22. Фазыйль [галим] Мәрҗани 1844 (1260) тарихында рамазан 19да (сентябрьдә) җимерелдеген нәкыль итмештер [яза]. (Мөстафадел-әхбар. I т. — Б.94). — *Авт.*
23. «Бабий бугор»да (Кызлар тавы) 1880 елда Н.Ф.Высоцкий, 1913 елда М.М.Хомяков казу эшләре алып бара.
24. Болар исламга кадәр күмелмеш кешеләрнең гәүдәләре булса кирәк. — *Авт.*

Текстны һәм искәрмәләрне басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *һәм* ***Җәмил Мөхәммәтшин*** *әзерләде.*

БОЛГАР ХӘРАБӘЛӘРЕНДӘ

(Юл хатирәләре)

ГАЛИ РӘХИМ

Пароходтан төшүгә, безне бер көтү ямщиклар чолгап алдылар.

— Кая алып барыйк? Кая барасыз?

— Болгарга! — дидек.

Ямщиклар арасында төрле этнография типлары күренергә мөмкин иде. Әнә сирәк сакаллы урыс — чын-чын славян. Әнә тәбәнәк буйлы, кечкенә күзле, сирәк сакаллы, почмаклы йөзле татар, аның моннан җиде йөз ел элек Азиядән килеп, узып барышлый Иске Болгар шәһәрен басып узып киткән бабалары да нәкъ шуның төсле булганнардыр инде. Җыелган ямщикларның күпчелеген бөтенләй башка типтагы кешеләр тәшкил итәләр, алар озын буйлы, мәһабәт кыяфәтле, түгәрәк сакаллы татарлар — чын-чын болгар балалары. Аларны күргәч, миңа теге борынгы замандагы чабаталы урыс һәм фин җаулары тарафыннан йөдәтелә торган итекле болгарлар да нәкъ шулар төсле үз-үзләрен эре тотарга ярата торган, зур гәүдәле, мәһабәт кешеләр булганнардыр шикелле тоелды.

Атларга утырып, Идел буендагы киң яшел болыннар эченә кереп киттек. Болгар хәзер дә турыдан исәпләгәндә

Иделдән җиде чакрым ераклыгында гына булса да, ул турыда пароход пристане булмаганга, байтак кына әйләнеч ясап, Идел буйлап барырга туры килә.

Бер сәгатьләп барганнан соң, Спас шәһәрен уздык. Кечкенә-кечкенә берәр генә катлы мещан йортлары белән тулган бу шәһәрнең таш та җәелмәгән урамнарында озын баганаларга соңгы системадагы керосин фонарьлар асылган булуы, өстенә чикмән, аягына чабата кигән авыл мужигының башына ялт иткән кара цилиндр киертеп куйган төсле, көлке тоела иде.

Спастан соң өч сәгатьләп юл кала иде әле. Ике ягына йөзәр яшьлек карт каеннар тезелгән киң юл уртасыннан киттек. Бу каеннарның кем тарафыннан, кайвакытта утыртылганлыкларын белүче булмады. Әби патша [1] Болгарга килгән чакта утыртылганнардыр дип уйладым.

Әнә ахырда, сабырсызлык белән көтелгән Болгар манарасы еракта, томан арасында чыбык очы шикелле генә булып күренде. Бераз гына күренде дә агачлар, таулар артына кереп югалды. Кич була... Караңгылык төшкәнче барып җитә алабызмы, юкмы?

Менә килеп җитәбез. Берничә минуттан Иске Болгар нигезенә беренче тапкыр басачакмын...

Иске риваятьләр, легендалар, Гаяз әфәнденең инкыйразлары [2] тәэсире белән минем күңелемә кереп урынлашкан иске Болгар шәһәренең, Болгар халкының романтизмга буялган хыялый сурәтләре яңадан күз алдыма килгән күк булдылар. Көндез күкне каплаган болытлар таралдылар. Күк йөзендә ярты ай күренде. Җәгъфәр исемә төште [3].

Кояш баеган турыларга килеп җиттек. Болгар урынында хәзер Великие Булгары исемле зур гына урыс авылы утыра. Авылның зуррак кыйсеме (өлеше — Төз.) элек тә Болгар шәһәре булган урында — биек яр өстендә; калган кыйсеме яр астында...

Без инде яр астына килеп җитеп, авыл эченә кергән идек. Атбашчым чыбыркы белән җиргә күрсәтте:

— Кызык түгелме, бәлки, нәкъ хәзер без бара торган шушы комлы-тузанлы юл урынында берничә йөз ел элек гарәпләрнең Хәзәр диңгезеннән суда килгән көймәләре Идел дулкыннары өстендә акрын-акрын гына селкенеп торганнардыр... Киң Идел өсте исәпсез-хисапсыз җилкәннәр, әләмнәр белән чуарланган булгандыр.

Сөзәк таудан яр өстенә мендек. Хәзер без Иске Болгар шәһәренең нигезе өстендә.

Болгар авылында ике мөҗавир (каберлекләр сакчысы. — *Төз.*) тора икән. Берсе рәсми, икенчесе гайре рәсми. Беренчесенең йортында урын

булмаганлыктан, без соңгысының йортына туктадык. Рәсми мөҗавир монда унбиш елдан бирле торып, археология җәмгыяте [4] тарафыннан өч сум (!) вазифа ала икән. Ул — ак кәләпүшле, ап-ак сакаллы, ишаннар кыяфәтле бер карт. Үзе бик бетерешкән; күзләре яхшы күрмиләр. Алай да әле үзенең ачкычларын кулында бик нык тота... Бер яңа хикәят, яңа легенда ишетү өмете белән мин аннан Болгар хәрабәләре хакында байтак сораштырдым. Ләкин хәрабәләр турысында бик күп ишетелгән, билгеле сүзләрдән башка әйбер ишетә алмадым. Мөҗавирым, күп сөйләшергә яратмау өстенә, шактый ук надан да булып чыкты.

Икенче гайре рәсми Мөҗавирга килсәк, ул — Болгарга җәй көне, «сезон» вакытында гына килеп тора торган хәйләкәр, чын Казан татары. Ул Болгарга зиярәт кылырга килүчеләрне кабул итү, аларга мөҗавирлык дәлиллек итү белән кәсеп итә икән. Өстенә кигән сары бикасап казакие аның инде бабалары Болгарлар тора торган галәмгә китәргә вакыт җиткән, карт мөҗавир урынына претендент булганлыгын халь (хәл, торыш, кыя-фәт. — *Төз.*) теле белән әйтеп тора.

Хәзер дә ике мөҗавир арасында, дөресрәге, рәсми мөҗавирның яшь кенә хатыны белән гайре рәсми мөҗавир арасында бик каты конкуренция һәм дошманлык хөкем сөрә икән.

Караңгылык төшәр вакыт җиткән иде. Шунлыктан хәрабәләрне тизрәк карарга ашыктык. Иң әлек урам буйлап «Хәбесханә» (зиндан. – *Төз.*) исеме белән мәшһүр булган бинаны карарга киттек. Безнең барышыбыз чын-чын бер процессия-рәсми кәчид (демонстрация. — *Төз.*) хәлен алды: иң алдан без, безнең арттан кулларына таяклар, ачкычлар тоткан, өсләренә чапаннар, башларына чалмалар кигән ике мөҗавир, алар артында бер көтү зиярәт кылырга килгән хатыннар, карчыклар белән карт мөҗавирнең хатыны, аннан соң хатыннары белән өч пар, таякка таянган сукыр суфилар [5]. Бу суфилар, һәр елны җәй көне Болгарга килүче мөселманнардан садака җыеп яталар икән. Алар нәкъ Казан урамнарында теләнеп йөри торган суфилар төсле үк; өсләрендә җилән, башларына кайсыберсе әллә ниткән чүпрәкләрдән чалма чорнап куйганнар, чүпрәк таба алмаганнары, чалма төсле булсын дип, бүрекләрен генә ак яулыкка төреп кигәннәр. Иң арттан бер төркем авыл балалары киләләр. Алар шулкадәр күп, әйтерсең бөтен авылдагы урыс малайлары белән марҗа кызлары җыелганнар.

Шулай итеп, без авылның бөтен урамын тутырып, сабан туеннан кайткан халык төсле, хәрабәләр карарга киттек.

Менә шул вакыттан башлап, минем бөтен шигъри хыялларым йомшак таштан салынган Болгар биналары төсле берсе артыннан берсе җимерелергә тотындылар. Имеш, Болгар хәрабәләрен карарга барабыз! Бичара романтизм, бичара шигърият, кая сез! Чын хакыйкать, урыс әйтмешли, күзләрне ачтыра торган хакыйкать минем алдыма килеп басты.

Менә беренче хәрабәгә килеп җиттек, һәммә хәрабәләр археология җәмгыяте тарафыннан төзәтелеп, ишекләр ясалып, тирәләре агач рәшәткәләр белән әйләндерелгән, һәркайсы йозакланып, ачкычлары әлеге елына утыз алты сум вазифа ала торган мөҗавир кулында тора икән. Бу мөҗавирның археология җәмгыяте тарафыннан шундый әһәмиятле хезмәт тапшырылып та, көлке дәрәҗәсендә аз вазифа алуын мин һичбер төрле аңлый алмадым. Гайре рәсми мөҗавир гына аның турысында:

— Чынлыкта хәрабәләр авылның попы карамагында. Мөҗавир аның кул астында хезмәтче шикелле генә... — дип куйды.

Хәбесханә дип аталган бинага кердек. Эчендә бернәрсә дә юк, караңгы.

Идәнендә җир астына казылган бер баз бар; тирәнлеге сажин [6] ярым бар, диделәр. Археология җәмгыяте тарафыннан түбәсе очлайтып ябылган, тәрәзәләренә кирпеч тутырылып, стена белән бертигез ителеп салынган. Тәрәзәләренең зурлыгына караганда, хәбесханә булмаска охшый.

Болгар биналары һәркайсы стеналары бик калын ителеп, Идел буенда чыга торган гади йомшак известь (известняк) ташыннан салынганнар. Болгардан калган биналарның тиз ватылып һәлак булуларында сәбәп шушы таштан салынулары булган. Бердән, йомшак булганга һава һәм су тәэсиренә бик тиз бирелгәннәр. Бу тәэсир биналарның ташларын каплаган шомартылган ташларда бик ачык күренеп тора. Кайчандыр тип-тигез булган бу ташлар, хәзер бөтенләй шадраланып, эчләре тишек-тишек булып ашалып беткән; тоткач, бармак арасында да уалып китәләр. Икенчедән, авыл урыслары бертуктаусыз ташларны ташып, үз кирәкләренә тотканнар: каралтылар салганнар, яндырып известь ясаганнар. Кеше күрмәгәндә алар әле дә ташларны урларга хәзер торалар икән.

Гарәп осталары шул начар ташларга да матурлык бирә алганнар. Гомуми һәлакәт вә җимерелүдән котылып калган кайбер әсәрләр (архитектурные детали) моңар шәһадәт (таныклык. — *Төз.*) бирәләр. Гомумән, бөтен хәрабәләрдә гарәп стиле хөкем сөргәнлеге күренә.

Хәбесханәдән чыккач, шунда якында гына булган мәсҗед урынын карадык. Ишеге ни өчендер ачылмаганга, киртә аркылы төштек. Мәсҗед төбенә чаклы диярлек җимерелеп, бары урыны гына калган. Ул дүртпочмаклы (мөрәббәгъ) шәкелдә; дүрт почмагында бик калын-калын баганалар булган. Бу баганалар гарәп ысулынча сигезпочмаклы итеп ясалып, тышлары тигезләнгән ташлар белән капланганлыгы күренеп тора. Мәсҗид хәзерге чиркәүнең күршесендәгенә. Мәсҗед урыныннан «Кызлар мәдрәсәсе» дип аталган бинага киттек. Юлда карт мөҗавирның хатыны белән гайре рәсми мөҗавир үзләренең мөҗавирлык хокуклары турысында бик каты ут ягып кычкырышырга тотындылар.

«Кызлар мәдрәсәсе» яки «Кара сарай» дип атала торган бина хәрабәләр арасында бик яхшы сакланганнарыннан берсе. Ул дүртпочмаклы; өсте түптүгәрәк гөмбәз белән капланган. Бу түгәрәк гөмбәз бинага чын гарәп рухы бирә. Ул нәкъ гарәп шәһәрләренең берсеннән алынып, ялгыш кына Идел буена китереп утыртылган кечкенә бер мәсҗед төсле. Тыштан караганда ул бик зур төсле түгел; ләкин эченнән шактый биек шикелле күренә. Электә өч катка бүленгәнлеге тәрәзә һәм кәрнизләреннән беленеп тора. Бинаның нәрсә өчен салынган булуын тәгаен әйтү читен. Бу бина эчендә шәһәр урынында табылган бик күп әйберләр җыелган. Бер якта иске су буе (водопровод) торбалары. Бу торбалар яндырылган балчыктан калын итеп эшләнеп, тишекле ташлар аркылы үткәрелгәннәр. Икенче якта бик күп кабер ташлары, күбесе ватык. Араларында дөрес куфи [7] язуы белән язылганнары бар. Кайберләре әллә нинди бозык язу белән язылганнар. Матур гына итеп төрле бизәкләр, чәчәкләр төшерелгәннәре дә бар. Бер кәрнизгә табылган адәм башлары тезелгән. Бу почмакта бер ящик кеше сөякләре, ташлар арасында таштан юнып ясалган бизәкләр (архитектурные детали) дә байтак бар. һәрберендә гарәп өслүбе күренеп тора. Ишелгән мәсҗедтән китерелгән капительле сигез почмаклы бер багана яхшы гына сакланган. Бу әйберләрнең һәрберсен бик кадерләп, өсләренә җәймәләр ябып кына тоталар икән.

Шушы әйберләрне зәгыйфь шәм яктысында тырышып-тырмашып караган арада, бер кызык эш күземә бәрелде. Безнең арттан бина эченә кереп тул-

ган баягы карчыклар пыштыр-пыштыр укып, куллары белән кабер ташларын сыпыралар да аннан соң битләрен сыпыралар. Килүче хатыннар арасында шул кабер ташлары, адәм башлары өстенә сөлгеләр, тастымаллар, намазлыклар, яулыклар ябып китүчеләр бик күп була икән. «Соң ул әйберләрне кая куялар?» — дип сораганга каршы әллә кем: «Мөҗавир җыеп алып кайтып сата», — дип җавап бирде. Татар-болгар балалары әле дә үзләренең моннан мең ел элеккеге диннәре фетишизмын (фетишизм — җансыз нәрсәләрне олуглау вә аларга гыйбадәт кылу) онытып бетермәгәннәр икән, дигән фикер башыма килде кинәт. Идәндә яткан, агачтан ясалган кечкенә генә кара «Аркылы» [8] дикъкатебезне җәлеп итте. Мөҗавирнең хатыны аны бик тиз алып, сындырып, тышка чыгарып ташлады.

Урыс малайлары бу тәреләрне, юри ясап, тәрәзәдән эчкә ыргыталар икән.

«Кызлар мәдрәсәсе»ннән чыккач, мәшһүр Болгар манарасын карарга киттек. Бу манараны мөҗавир «Җеназа манарасы» дип атады. Аның әйтүенчә, иске Болгарда җеназа булган чакларда шул манарага менеп халыкка игъләм (белдерү. – *Төз.*) кылганнар. Бу манараның электә каберстан булган урында булуын һәм хәзердә дә бәгъзе татар авылларында җеназа барлыгын мәсҗед манарасына менеп кычкыру гадәте булганлыгын хәтергә алсак, бу фикерне дөрес дип уйларга мөмкин.

Манара бик җуан таш багана формасында салынган. Башына менә торган бормалы баскыч шул таш багана эчендә тар коридор шикелле генә итеп калдырылган. Баскычның бөтен стеналары, югарыда такта түбә асты бөтенләй төрле язулар белән капланып беткәннәр. Манарага менгән кешеләр кайсы карандаш белән, кайсы кара белән, кайсы пәке белән казып, кайсы күмер белән генә үзләренең исемнәрен язып калдырганнар. Шиһап хәзрәтнең язып калдырган [9] тарихи язулары, манара төзәтелгән вакытта сыланып, балчык астында калганлыгын мөҗавир сөйләде.

Манараның өсте бик тар. Анда тәбәнәк кенә итеп кыеклап капланган такта түбә астында аркылы-торкылы салынган матчалар өстенә генә басып торасың. Сакланыбрак басмасаң, матча араларыннан түбәнгә егылып төшәргә мөмкин. Түбә тактасына кечкенәкечкенә генә тәрәзәләр тишелеп, тимер ятьмәләр белән капланган. Без манараның башына җиде-сигезләп кеше менгән идек, эсселектән җаныбыз чыгарга җитештек. Тиз-тиз генә бер җиргә исемнәребезне язып, түбәнгә төшәргә ашыктык. Манараның тышкы стенасында бер таш күрдем. Өстенә күпертелеп гарәп стилендә бик матур, бик вак һәм бик чуалчык бизәкләр төшерелгән. Әллә никадәр вакыт сокланып карап тордым. Әгәр дә бөтен манараның тышы шундый бизәкле ташлар белән капланган булса, вакытында бик матур булгандыр, дип уйладым. Шулвакыт колак төбемдә мыгырдаган бер тавыш ишетелде. Карасам, баягы хатыннар, карчыклар манара төбендә җиргә тезләнеп, кулларын дога кылгандагы күк күтәреп утырганнар. Әлеге мөҗавир хатыны тиз-тиз нидер сөйләнә.

— Нишлиләр алар? — дип сорадым.

— Монда бер кыз әүлиянең кабере бар. Шуның рухына укып, теләк телиләр, — диделәр.

Мөҗавир хатынының сүзләренә колак салдым:

— Йә, Ходаем, шушы газизләр хөрмәтенә бар теләкләремне кабул ит. Шушында күмелгән изге хатын хакына барча максудларыма ирештер... дип, «жрица»ның өйрәнеп беткән теле шундый теләкләрне бертуктаусыз такылдый иде.

Караңгылык төште. Авылга кайттык. Бүлмәдәге эсселек, кандалалар, озынборыннар безгә төнне тыныч йоклап уздырырга ирек бирмәделәр. Кояш чыккач та, торып, көн яктысында

хәрабәләрне тагын бер тапкыр карап кайтканнан соң, атларыбызга утырып, авылдан бераз читтәрәк хан сарае дип аталган җирне карарга киттек.

Тирә-ягы канау белән әйләндерелгән мөрәббәгъ (квадрат, дүртпочмаклы. — *Төз.*) шәкелдә бер мәйдан. Өсте мужиклар тарафыннан сукаланган. Ике ягында ике капка урыны бар. Бу хәрабәләрдә мәрмәр ташлары табыла икән. Без дә кечкенә генә мәрмәр таш кисәге таптык. Шул тирәдә икенче тирән бер канау әллә кая кадәр сузылып китә. Шәһәр коймасы булган урын булырга кирәк.

Аннан да киттек. Яр астына төшкәч, ике кое күрдек. Эчләрендә су тулып тора. Яр өстендә Габдеррахман сәхабә [10] кабере бар, диделәр. Мендек. Бөтен яр өсте тавык йоны, тавык сөяге белән тулган. Сораштыргач, моның ни икәнен белдек. Болгарга зыярәт кылырга килүчеләр әйткән нәзерләре буенча шул кабер өстенә кайсы сарык, кайсы әтәч алып килеп чалалар, шунда ук йолкып, шунда ук пешереп, итен җыелган суфиларга тараталар икән. Әтәч корбан итү! Бу миңа бик көлке тоелды. Уйлый торгач, борынгы мәҗүси төркиләрдә әтәчнең изге кош булганы хәтеремә төште. Бу гадәт белән шул мең елгы игътикад арасында бер мөнәсәбәт булырга кирәк, дип уйладым. Дин үзгәргән, ләкин культ (дини гадәт) үзгәрмәгән. Борынгы мәҗүси болгарлар әтәчне үзләренең мәҗүси мәгъбүдләренә корбан иткән булсалар, хәзер дә аларның варислары — мөселман татарлар шул ук әтәчне әллә нинди изгеләр, әүлиялар рухына атап, кычкыртып суялар, аерма шунда гына: борынгы мәгъбүдләр урынына исламият тәэсире астында әлеге әүлиялар менеп утырганнар.

Боларны карауны шуның белән тәмам иттек. Атлар безне килгән юлыбыздан кирегә, Иделгә таба чаптырып алып киттеләр.

Болгар хәрабәсе, сине бу шигъриятсезлек, бу проза арасында күргәнче, күрми тору артык иде. Синең хыялың, синең күләгәң үзеңнән матуррак, үзеңнән моңлырак иде. Юк шул дөньяда шигърият, юк романтизм! Юк моңлы матурлык, моңсыз, күңелсез бертөрле генә дөньяда! Әгәр сезгә шигърият, романтизм кирәк икән — сез аны үз эчегездән, үз күңелегездән эзләгез, башка җирдән таба алмассыз... Әнә атбашчы үзенең ат тоткан урынында акрын гына Коръән укый. Болгар баласы үзенен бабаларының рухына дога кыла, дисезме? Юк сүз, хыял! Ул да шул бары үзен баягы изгеләр, әүлиялар кабере янында дип ышанганга күрә генә укый» югыйсә укымас иде... Дөньяда шигърият юк! Юк!

Табигать тә минем күңелсез, кәефсез халәт руханиямне аклаган төсле күңелсезләнде. Күкне болытлар каплады. Каршыга ачы салкын җил исә башлады. Суык... Суык...

Искәрмәләр

1. Екатерина II — Россия патшабикәсе; 1767 елның маенда Казанга килгәч, Сембер шәһәренә китешли, Пётр I кебек үк, Болгар хәрабәләрен дә карый.
2. Г.Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре (1902-1903 елларда языла) күздә тотыла.
3. Романның төп герое Җәгъфәрне Болгар шәһәрендәге манара басып үтерә. Ул Болгар халкының соңгы вәкиле, шушы халыкның тарихын, инкыйразын язучы була.
4. Казан университеты каршында 1878 елны оешкан «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» күздә тотыла. ул өч юнәлештә эшли: археология, тарих һәм этнография. Уставында Россия дәүләте составындагы рус һәм элеккеге Болгар — Хәзәр, Казан — Әстерхан дәүләтләрендәге, шулай ук Себер һәм Урта Азиядә яшәүче халыкларның үткәнен өйрәнү максаты күрсәтелә.
5. Гомерләрен Аллага гыйбадәт кылып уздыра торган, сорашып тамак туйдыручы дәрвишләр.
6. Озынлык үлчәве; 2,134 метрга тигез.
7. Гарәп хәрефләренең каллиграфик бер төре.
8. Тәре күздә тотыла.
9. Философ, дин галиме, тарихчы һәм көнчыгышны өйрәнүче Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1898) күздә тотыла.
10. Мөхәммәт пәйгамбәрнең замандашы булып, аны күргән кеше.

Чыганак

Рәхим Г. Сайланма әсәрләр. — Казан: Татар. кит.нәшр., 2004. — Б.172-179. ■

КАЗАН АКСӨЯКЛӘРЕ СӘЯСИ КӨРӘШЕНЕҢ ИСТОРИОГРАФИЯДӘ ҺӘМ РУС ЧЫГАНАКЛАРЫНДА ЧАГЫЛЫШЫ

МАКСИМ МОИСЕЕВ,
тарих фәннәре кандидаты, М.А.Шолохов исемендәге Мәскәү дәүләт гуманитар университетының өлкән укытучысы



МӘСКӘҮ-КАЗАН МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕН ӨЙРӘНҮНЕҢ БАЙ ИСТОРИОГРАФИК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ БАР. БУ МӘСЬӘЛӘГӘ XVI-XVII ГАСЫРЛАРДА ЯШӘГӘН АВТОРЛАР ДА ҺӘМ АННАН СОҢГЫ ЧОРЛАРДА ЭЗЛӘНҮЛӘР АЛЫП БАРГАН ГАЛИМНӘР ДӘ ИГЪТИБАР ИТКӘН.

Тикшеренүчеләр үзләренең хезмәтләрендә Казан ханлыгы аксөякләренең әлеге, әйтергә кирәк, катлаулы төсмер алган мөнәсәбәтләргә катнашы барлыкны искәртәләр. Казан аксөякләренең позициясе каршылыклы хисләр уята, бу халәт барыннан да бигрәк ханбикә Нурсолтанның: «Казан җирләре — яман», — дигән сүзләрендә чагылыш таба. Мондый тискәре бәяләмәнең сәбәбе нәрсәдә? Казан аксөякләренең эшчәнлек үзенчәлекләре нидән гыйбарәт? Гомумән, болар турында нәрсәләр беләбез? Мәкаләбезне шушы һәм башка сорауларга багышладык.

ИСТОРИОГРАФИЯ

Күпчелек авторлар өчен рус-Казан мөнәсәбәтләре тарихы Казан аксөякләре арасындагы эчке көрәш барышы белән аерылгысыз бәйләнгән. Н.М.Карамзин: «Казан килешмәүчәнлек театрына һәм төрләр фетнәсе урынына әйләнде», — дип белдерә [Карамзин, 1989, стб.114]. «Казан фетнәсе» турында С.М.Соловьёв та яза, ул ханлыкның эчке тормышына катнашырга җөрьәт иткән җитди геополитик шартларны да күреп ала [Соловьёв, 1989, с.68]. Әмма бу хезмәтләрдә рус-Казан мөнәсәбәтләре Россия тарихының тоташ картинасында берничә элемент буларак кына күренә. Идел буе тарихына махсус мөрәҗәгать иткән азсанлы тикшеренүчеләрнең берсе Г.И.Перетяткович булды. Аның хезмәте үз заманы өчен, һичшиксез, яңалык булган, автор бер төркем чыганакларны анализлау белән чикләнеп калмый, аларның берсен — төп, ә кал-

ганнарын ярдәмче итеп тә калдырмый. Ул, киресенчә, үзенең тикшеренүләрен нарратив һәм рәсми язышу документлары комплексын өйрәнү нигезендә башкарырга омтылган. Нәтиҗәдә, Г.И.Перетяткович мордвалар, Нугай Урдасы, Әстерхан, Казан ханлыклары тарихы һәм көнкүреше турында бай эчтәлекле хезмәтләр язып калдырган. Рус тарихчыларыннан беренчеләрдән буларак, ул Алтын Урда таркалганнан соңгы чордагы элитаны, аеруча Казан аксөякләрен, өйрәнүне башлап җибәрә. Әлбәттә, аның кайбер аңлатмалары һәм фаразлары хәзер бары тик историографик яктан гына кызыклы, әмма алар аннан соңгы историографиягә сизелерлек йогынты ясаган. Мондый идеяләргә, һичшиксез, аның Казан аксөякләренең эчке көрәш үзенчәлекләре турындагы күзаллауларын кертергә мөмкин. Аерым алганда, авторның Казан ханы хакимияте «күпсанлы югары дворяннар тарафыннан нык чикләнгән булган» дигән күзәтүе аерым әһәмияткә ия [Перетяткович, 1877, с.126]. Нәкъ менә шуның өчен дә эчке көрәш гадәти, «түрәләрнең үзара килешмәүчәнлеге һәм фетнәләре» генә булмыйча, киңрәк мәгънә ала. Тарихчы элита вәкилләренең бәхәсләрендә башлангыч нокта итеп чиктәш илләрнең, аксөякләрнең «үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртуларына» этәргеч биреп, Казанның эчке эшләренә тыкшынуын саный [Перетяткович, 1877, с.129]. Әлеге концепциягә нигезләнеп, автор Казанда нугай, мәскәү, шәйбани һәм кырым фиркаләрен аерып чыгара. «Фиркаләр» XV гасыр азагында, Ибраһим хан уллары Илһам һәм Мөхәммәдәминнең үзара көрәше барышында оеша башлый. Илһамга — нугайлар, ә Мөхәммәдәмингә Мәскәү ярдәм күрсәтә — шулай итеп нугай һәм мәскәү «фиркаләре» барлыкка килә [Перетяткович, 1877, с.151]. Шәйбаниләр фиркасе оешуны автор 1490 нчы елларга нисбәтли [Перетяткович, 1877, с.153-154]. Күрәсең, мәскәү һәм кырым фиркаләре бергә

Русларның Казанны алулары. «Казан тарихы»ннан миниатюра. XVII гасыр

эш йөрткән, соңрак юллар аерылган — Г.И.Перетятковичның фикер сөрешен шулай аңларга мөмкин. Һәрхәлдә, автор түбәндәгеләрне яза: «Латыйф вафат булгач, Казанга мөнәсәбәтле Кырым һәм русларның гомуми мәнфәгатьләре чәлпәрәмә килә, һәрбер фирка үз мәнфәгатьләрен аерым кайгырта башлый» [Перетяткович, 1877, с.159]. Нәкъ менә шушы ике фирканең үзара көрәше күпчелек очракта ханлыкның сәяси тормышын хасил итә дә инде [Перетяткович, 1877, с.130]. Шунысы кызык: автор, тарихтагы бу ике фактордан кала, нугай фиркасенең ханлык яшәгән чорда үз куәтен саклавы турында да яза. Ул үзенең йогынтысын Казан ханнары һәм нугай аксөякләре арасында, мөгаен, бер никах белән генә чикләмәгәндер [Перетяткович, 1877, с.152-153, 166, 171, 172]. Асыл-

да Г.И.Перетяткович төрле фиркаләр арасында кырыс көрәш барган Казан ханлыгының «политология»сен иҗат итә. Әмма «фиркаләр» төшенчәсе астында галим нәрсәне аңлаган соң? Кызганыч ки, автор бу сорауга туры-дан-туры җавап бирми, әмма кайбер фикерләре буенча без түбәндәге фаразны әйтә алабыз. Беренчедән, фиркаләр нәсел-нәсәби көрәшләр белән бәйле булганнар. Әйтик, шәйбаниләр фиркасе — себер Чыңгызыйлары дәгъвасына ярдәм итүчеләр, кырым фиркасе исә — Гәрәйләргә [Перетяткович, 1877, с.130, 159 һ.б.]. Икенчедән, шунысы кызык: фирка куәтенә җәйләү урыннарының якынлыгы һәм күрше илләрдән кешеләр килүе кебек факторлар да тәэсир иткән. Г.И.Перетяткович «нугай фиркасе»нең куәтен Казанга нугайларның җәйләү урыннары якынлыгы [Перетяткович, 1877, с.171], ә «кырым фиркасе»нең көчәюе «килгән кырымлылар»га бәйле булу белән аңлата [Перетяткович, 1877, с.166]. Ягъни шунысы ачык күренә: галим «фиркаләр» төшенчәсе астында төрле аксөякләр төркемнәренең, әйтергә кирәк, казанлыларның гына түгел, ә килгәннәрнең дә ханга йогынты ясар өчен көрәшүләрен күз алдында тоткан. Нәкъ менә шуның өчен дә нугай фиркасенең кайгыртучанлыгы еш кына никах сәясәтеннән ары китмәгән. Әмма шунысын искәртергә кирәк: Г.И.Перетятковичның «фиркаләр хакимияте» турындагы фикерләре фәнни тәгълимат нигезендә оешкан, ул Казан аксөякләренең персональ составына кагылмый диярлек, эшчәнлекләренә дә анализ ясамый. Шуның өчен аның концепциясе саф теоретик һәм гипотетик төсмергә ия. Әмма, шуңа да карамастан, Казан ханлыгындагы сәяси көрәштә «фиркаләр концепциясе» аннан соңгы историографияләрдә шактый киң таралыш алган.

Г.И.Перетятковичның теориясе М.Г.Худяков тикшеренүләрендә үстерелә. Ул Казан ханлыгында фиркаләр барлыкка килүне, XV гасырның 60 нчы елларында ук башланды, дип, шактый элгәрге вакытка күчерә. Галим фикердәге аерымлыкларны шәхси каршылыкларда күрә [Худяков, 1991, с.37-38]. XV гасырның азагыннан башлап сәяси бүленеш тирәнәя һәм аның «үзәге» сәүдәдә икәнлеге ачык күренә. Шулай итеп «сәүдә капиталы»ның рус базары белән тыгыз бәйле булган өлеше — рус, ә Урта Азия базары белән бәйле булганы шәрык фиркасен тәшкил иткән [Худяков, 1991, с.45-46]. М.Г.Худяковның үзенә кадәр яшәгән тарихчының «фирка концепциясе»ндәге фиркаләр санын дүрттән икегә киметеп, аларның мәнфәгатьләрен сәүдә юнәлешләре белән аңлатып, М.Н.Покровский концепциясе рухында модернизацияләгәне ачык күренә. М.Г.Худяков хезмәтеннән соң Казанның тышкы сәясәтен өйрәнүче тарихчылар ике фиркане генә телгә алалар, әмма «фиркаләр аерымлыгының» сәүдәгә бәйлелеген танымыйлар [Смирнов, 1948, с.19]. И.И.Смирнов Василий III нең көнчыгыш сәясәте турында 1948 елда басылган хезмәтендә Казан аксөякләренең сәяси көрәшләрен тасвирлауга аеруча игътибар итә. Автор хикәяләвендә бу көрәш шактый каршылыклы тоела. Бер яктан, галим аны «феодаль ыругларның хакимият өчен көрәше, феодаль ызгыш-талашларның типик чагылышы», дип билгели [Смирнов, 1948, с.19], икенче яктан, «Рус дәүләте белән блок» төркемен һәм «Казанга Россия белән көрәштә, шулай ук Идел буенда сәяси гегемониягә омтылган Казан ханлыгына позициясен ныгытуда көчле ярдәм» күрсәтергә мөмкин булган Кырым һәм Төркиягә йөз тоткан төркемне аерып чыгара [Смирнов, 1948, с.18]. И.И.Смирнов бу «фиркаләрнең» социаль тамырларын да ачыкларга омтылып карый. Аныңча, башта алар ачыктан-ачык күренми, әмма 1540 елларның азагыннан алып «Казан сәяси төркемнәренең табигате үзгәрүне тоемларга мөмкин». Шунысы кызык: автор фикеренчә, бу вакытта «түбән казанлылар» — ул киң катлам шәһәр халкын

шулай атый — Мәскәү белән килешүне яклап чыкканнар [Смирнов, 1948, с.19]. И.И.Смирновның тагын бер кызыклы күзәтүе бу вакыйгаларда шириннәрнең роленә кагыла. Ул Мәскәүгә йөз тоткан бу затлы нәсел төркеме вәкилләренең Рус дәүләте, Казан һәм Кырым ханлыклары мөнәсәбәтләрендә аерым урыны турында яза [Смирнов, 1948, с.33-34]. Әйтергә кирәк, И.И.Смирновның күп кенә күзәтүләре документлар белән җитәрлек дәрәҗәдә ныгытылмаган һәм шул сәбәпле тәнкыйтькә урын калдыра. Шунысы мөһим: автор Казандагы сәяси көрәшнең катлаулылыгын аңлап яза, әмма мәкалә кысаларында аны җентекләп тикшереп бетерми.

1952 елда И.И.Смирновның кайбер карашларын К.В.Базилевич тәнкыйтьли. Галим Казанда 1496 елда Кырым ханлыгына һәм Төркиягә йөз тоткан төркем булу турындагы карашны чынбарлыкка туры килми дип бәяли. Аның фикеренчә, бу вакытта «төрле феодаль аксөякләр төркемнәре арасында берсе Мәскәүгә, икенчесе аңа дошмани булган татар урдасына йөз тоткан сәяси көрәш күзәтелми». Тикшеренүче 1496 елгы вакыйгаларны феодаль-династик характерда булган дип аңлата [Базилевич, 2001, с.352-353]. Әмма хакыйкать өчен шунысын да искәртергә кирәк: бу очракта тәнкыйть урынлы түгел, чөнки И.И.Смирнов, Мамыкның Казан хакимиятенә килү тарихын тикшергәндә, моны шулай ук сарай интригалары белән аңлата [Смирнов, 1948, с.20-21]. Әмма коллегасы белән бәхәсләшеп, К.В.Базилевич 1505 елда Казанда хакимият алышыну тарихына мөрәҗәгать итә, ул елларда модада булган Көнчыгыш Европадагы зур халыкара уен турындагы теориягә игътибар бирә, әлеге вакыйгаларда Нугай Урдасының гына түгел, ә Бөек Литва кенәзлеге, шулай ук Төркиянең дипломатик комбинациясен дә күрә [Базилевич, 2001, с.480-482].

Рус-Казан мөнәсәбәтләрен өйрәнүне С.О.Шмидт дәвам итә. Ул да «мәскәү» һәм «шәрык» фиркаләре (соңгысының синонимы буларак «кырым» сүзен куллана) турында яза [Шмидт, 1954, с.225, 235]. Галим, фиркаләр «аерымлануы нигезенә сәүдә мөнәсәбәтләрен түгел («Покровский мәктәбе» юкка чыгарылганнан соң, бу — табигый күренеш), ә сәяси принципны сала. С.О.Шмидт Россиянең Көнчыгыштагы дошманнары белән рәхимсез сугышлары турында яза, аныңча, Казан ханлыгы «...Рус дәүләтенә дошман булган көчләрне үзендә туплаган үзенчәлекле бер фокус булып торган» [Шмидт, 1954, с.216, 217, 255, 257].

С.Х.Алишев Казан феодалларының үзара хакимият өчен көрәше ике төркемнең («мәскәү» һәм «шәрык яны кырым») тышкы сәяси эшчәнлекләрендә дә чагылыш таба дип карый [Алишев, 1990, с.52-53]. Соңрак автор бу мәсьәләдә үзенең карашларын, Казан аксөякләренең ике кисәккә — «мәскәү» һәм «шәрык» фиркаләренә — бүленешен саклаган хәлдә, Казан ханлыгы сәясәтенә нугайларның көчле йогынтысы булуын күрсәтеп үстерә [Алишев, 1995, с.53]. Биредә шунысы кызык: шәркый фирка автор өчен — «Кырымнан килгән феодаллар һәм нугайлар фиркасе» [Алишев, 1995, с.59]. Шулай итеп, галим фиркаләрне килгән элемент белән өлешчә бәйли, бу, һичшиксез, Г.И.Перетяткович карашларына кире кайту була.

Казанда «фиркаләр көрәшен» өйрәнүдә тагын бер кызыклы момент — Казан аксөякләре сәяси симпатияләренең «Касыйм ханлыгында мөһим роль уйнаган туганнары» белән бәйләнеше турындагы Д.М.Исхаков фикере [Присоединение, 2003, с.60]. Әмма әлеге күзәтү Смирнов гипотезасы белән аваздаш [Смирнов, 1948, с.33-34].

Шул рәвешле, историографиядә, Казан ханлыгы сәяси тарихы кысаларында, «фирка» төшенчәсен билгеләүдә үсешүзгәреш күзәтелә. Г.И.Перетяткович өчен «фирка» сарайда барган көрәш кысаларында хакимияткә ирешер өчен

берләшкән аксөякләр төркемнәре булса, XX йөз башында инде (күп тарихчылар өчен) «фирка» — аксөякләрнең сәяси һәм икътисади идеяләр тирәсендә аермачык берләшүе. Шуның белән бергә, Казан ханлыгындагы сәяси көрәштә Г.И.Перетяткович тарафыннан тудырылган «фирка теориясе» бүгенгә кадәр үзенең йогынтысын саклаган, дип ышанып әйтергә мөмкин, әмма гипотезаның күзгә бәрелеп торган йомшак яклары да бар. Иң мөһиме шуннан гыйбарәт: бу теорияне тудыручы да, аңа иярүчеләр дә беркайчан да «фирка»ләрдә булганнарның исемлеген һәм эшчәнлекләрен анализламаганнар. Болар барысы да Г.И.Перетяткович теориясен тәнкыйтьләргә юл ача, фиркаләр чыннан да булганмы-юкмы икәнлеген ачыклау максатыннан, шулай ук сәяси көрәштә Казан элитасының роле нинди булганын аңлау өчен, чыганакларны яңадан анализлауны таләп итә.

ЧЫГАНАКЛАР

Рус-Казан мөнәсәбәтләре төрле чыганакларда — нарратив, рәсми эш кәгазьләре, рус һәм көнчыгыш чыганакларында, Европа дипломатлары һәм сәүдәгәрләренең язмаларында — чагылыш тапкан. Әмма чыганакларның сакланышы бик начар. Казан документлары тулысынча янып бетә, илчеләрнең Россия белән Казан ханлыгы бәйләнешләре турындагы китаплары югалган. Бу шартларда бердәнбер мәгълүмат чыганагы булып рус елъязмалары гына кала диярлек. Бердәнбер, әмма алар ышанычлымы соң? Шикшөбһә, табигый, нигезсез барлыкка килми, әмма тикшеренүчеләр алардан озак вакытлар актив файдалана килде. Күптән түгел генә елъязмаларның вакыйгаларны ни дәрәҗәдә дөрес чагылдыруы мәсьәләсен Б.Р.Рәхимҗанов кузгатты [Рахимзянов, 2005, с.248-251]. Авторның нәтиҗәләре шатландырырлык түгел: «Елъязмалар... татар ханлыклары белән мөнәсәбәтне еш кына бозып тасвирлыйлар, шуның өстенә алар конъюнктур характерда» һәм, аңлашыла ки, аларны бик сак файдаланырга кирәк [Рахимзянов, 2005, с.250-251]. Күзәтү күп яктан дөрес, тик ул елъязмалар чыганак буларак тулысынча файдасыз дигәнне аңлатамы? Нарратив чыганакларны өйрәнүчеләрнең «текстлар ялган», дип раслаулары күптәннән мәгълүм. Әйтергә кирәк, бу фикер нарратив чыгакларны өйрәнү өчен яңа методика һәм алымнар кирәклеген ассызыклый. Безнең очракта беренчел мәгълүматның бозып күрсәтелү характерын аңлау таләп ителә, башкача әйткәндә, «язманың» характерын аңлау, ә аннары аның «нуленче дәрәҗәсен», ягъни идеологик эчтәлектән азат булган өлешен ачыклау кирәк булып чыга. «Сәяси язма»ны бәяләгәндә, мөһим момент булып (ә XVI гасырның елъязмалары шушы типка карый) «...бер алымда фактлар чынбарлыгын максатлар идеальлеге белән берләштерү» кирәклеге тора [Барт, 2008, с.63]. Гади генә итеп әйткәндә, иң әүвәл елъязмачының нәрсәне нигезләргә теләгәнлеген, аның текстны ничек төзегәнлеген аңларга, ә аннары ул файдаланган фактларны аерып алырга кирәк. Шуннан соң гына алга таба файдаланырга мөмкин булган, чагыштырмача «чиста продукт» табыла.

Бу теоретик фикерләүләрдән соң (шактый бәхәсле дип уйлыйм), конкрет материалларга мөрәҗәгать итик. Елъязмачылар дәүләтнең Көнчыгыш сәясәте концепциясен «эшләгәндә», Мәскәүдә Алтын Урда таркалганнан соңгы дөньяны рус тарихына җиңү контекстында кертер өчен дәлилләр эзлиләр. Мөгаен, шул эзләнүләр сәбәпле, XV йөз — XVI гасыр башында «Всеволод ясагы» дигән теория барлыкка килә, аның буенча кенәз Всеволод Юрьевич «... татарлардан салым алган, һәм барлык Рус һәм Идел буйлап диңгезгә кадәр җирләр белән идарә иткән» [ПСРЛ, т.22, с.388; УЛС, с.44]. Рәсми елъязмалар Идел буе болгарларының Руська бәйлелеге вакытын (ясак түләп тора башлавын)

борынгырак вакытка күчереп тәкъдим итә, аны кенәз Владимир Святославич идарәсенә нисбәтли һәм хәтта легендар кенәз Кий белән бәйли. Өстәвенә, митрополит Даниил җыентыгында Идел буе болгарлары казанлылар белән тәңгәлләштерелә [Pelenski, 1974, p.97-103; Клосс, 1980, с.101; Ерусалимский, 2006, с.317]. Шулай да бу теория тәмамланган төсмер алмый, барыннан да бигрәк, аны дипломатик процессларда файдалану чикләнгән була.

1520 елдан рус сәяси нарратив чыганакларында Урта Идел буе баштан ук рус идарәчеләре кулында булган дигән фикер оеша. Бу фикер рәсми елъязмаларда да үткәрелә. Алай гына да түгел, әлеге концепция Нугай Урдасына карата да кулланыла башлый. Рәсми елъязмалар өчен гомуми чыганак булып 1541 елгы «Летописец» хезмәт иткән [Морозов, 2005, с.35]. Бу өлкәгә караган әсәрләр өчен («Воскресенская летопись», «Летописец начала царства», «Никоновская летопись», «Львовская летопись») Россия дәүләтенең көнчыгыш сәясәтенә бәйле мәгълүматларны тапшыруның билгеле бер структурасы хас. Әлеге структура рус-нугай мөнәсәбәтләренә багышланган текстларда ачык күренә. Аларны анализлаганда, безнең тарафтан шартлы рәвештә ике формуляр аерып чыгарылды. 1 нче формуляр (алга таба — 1 ф.) түбәндәгечә төзелгән кыска хәбәрләрдән тора: «(дата) бөек кенәзгә (исеме) Нугай илчеләре (кемнән, кемнәр), бөек кенәз ярлыкласын өчен (нәрсә белән) баш иеп, үтенеч белән килделәр». 2 нче формуляр тексты зурлыгы белән аерылып тора, өстәвенә ул 1 ф.ны саклый, ә аннары миссия турында җентекләбрәк сөйли. Рус-Казан мөнәсәбәтләре турындагы елъязма текстлары да якынча шундый ук схема буенча төзелгән.

Елъязма мәкаләләренең илче китапларыннан аермалы үзенчәлеге дип аларның махсус юнәлтелгән булуын танырга кирәк. Елъязмаларга рус-нугай мөнәсәбәтләрен вассал белән сюзерен (эре феодал) мөнәсәбәте рәвешендә бирү хас. Нугай илчеләре рус патшасына «бөек кенәз ярлыкасын һәм үз дәүләтендә сәүдә белән йөрергә рөхсәт итсен өчен» яки «бөек кенәз ярлыкасын, үзенең дуслыгын сакласын», дип баш ия. Шундый ук идеягә Рус дәүләте белән Казан ханлыгы мөнәсәбәтләрен бәян иткән елъязмалар да буйсындырылган.

Рус-Казан мөнәсәбәтләре турындагы елъязмаларның төзелешендә мөһим момент булып аларда, башлыча, түбәндәге очраклар сайлап алыну — казанлыларның үзләренә «патша» сораулары һ.б. тора. Нәтиҗәдә, мөхәррирнең төзәтүләре нәтиҗәсендә, Россия һәм Казан ханлыгының дипломатик контактлары тәхеткә варис сайлау мәсьәләсе белән чикләнә [Моисеев, 2010, с.395-397].

Бу күзәтүләр рәсми рус елъязмачыларының Казан белән мөнәсәбәтләр турындагы «сәяси язмалары» үзенчәлекләрен ышанычлы рәвештә ачыкларга мөмкинлек бирә. Әмма «идеал текст» төзегәндә, аны шактый тотрыклы нигезгә кору мөһим булган. Шуның өчен: «Фактлар кайдан алынды?» — дигән сорауны кую мөһим. Мондый чыганаклар булып фәкать дипломатик язышу материаллары гына тора алуы мәгълүм. Әйтик, Никон елъязмасы кебек компендиумнарны төзегәндә, елъязмачылар, беренче чиратта, дипломатик язышу документларыннан «Өземтәләр» тибындагы арадашчы чыганаклардан файдаланган. Бу төр чыганаклар өчен тасвирлауны унификацияләү, илчеләрнең, махсус җибәрелгән кешеләрнең, атчабарларның исемнәрен төгәл атау хас [Моисеев, 2010, с.397-398]. Бу безгә Казан аксөякләренең сәяси көрәшләрен өйрәнгәндә билгеле бер дәрәҗәдә ярдәм итә. Эш шунда ки, рус-Казан мөнәсәбәтләренең «идеал тарихын» тудырганда, рәсми елъязмалар Мәскәү белән дипломатик мөнәсәбәтләрдә Казан элитасы вәкилләре катнашу-

ын, тәхеттән төшерелгән һәм тәхеткә утыртылган ханнарны җентекләп теркәп калдырганнар. Болар барысы да безгә әлеге процессларга тартып кертелгән шәхесләр даирәсен ачыкларга мөмкинлек бирә. Елъязма текстларын анализлау 50ләп Казан аксөяге турында шактый ышанычлы итеп сүз алып барырга мөмкинлек ача. Табигый ки, бу — «диңгездәге тамчы» гына, әмма безнең очракта мәгълүматларның җитәрлек дәрәҗәдә ышанычлы булуы мөһим, нәкъ менә алар, югарыда язылганча, «язманың нуленче дәрәҗәсен» тәшкил итәләр дә инде. Болар — идеологик текстны төзү өчен чынбарлыкта булган кирәкле фактлар.

Елъязмалардагы мәгълүматларны тулыландыручы икенче тип чыганаклар булып дипломатик язышу китаплары тора. Казан ханлыгы белән элемтәләр турындагы китаплар сакланмаганын исәпкә алсаң, Казан белән бәйле берникадәр материаллар сакланган нугай илчеләре китаплары әһәмияткә ия булып чыга.

Рус чыганакларыннан кала, кайбер Казан материаллары да сакланган. Бу мәкаләдә, беренче чиратта, «Зафәрнамәи вилаяти Казан» әсәрендәге мәгълүматларны файдаланачакбыз, чөнки анда безнең эзләнүләребез өчен мөһим фактлар сакланган. Башка Казан чыганаклары (шәҗәрәләр, ярлыклар) аерым игътибар таләп итә, ләкин аларны анализлау безнең тар бер проблемага багышланган мәкалә кысаларыннан читтә тора.

КАЗАН АКСӨЯКЛӘРЕНЕҢ КӨРӘШЕ

Казан аксөякләре арасында каршылыклар XV гасырның 80 нче елларында Илһам ханның Мөхәммәдәмин белән көрәше вакытында аеруча ачык күренә. Билгеле булганча, соңгысы Мәскәүдән хәрби яклау таба һәм 1487 елда хан тәхетенә утыртыла. Илһам тарафдарларының бер өлеше репрессияләргә дучар ителә, әмма аларның кайберләре качып котыла. Рус-нугай дипломатик язышуларыннан безгә аларның исемнәре билгеле: Гали-Газый, Бигеш, Үтәш һәм Касыйм сәет. Алар нугай далаларына кача, Себер ханы Ибәк белән көченеп йөри. Рус хакимияте аларны үзенә хезмәткә чакыра һәм, әйтергә кирәк, болар Рус дәүләтенә күчеп китәргә каршы булмый. Әлбәттә, эшчәнлекләре турындагы мәгълүматлар бик аз, әмма Мәскәү белән аларның бер каршылыгын искәртергә була — бу үз ханнарына тугры вассаллар каршылыгы, әмма ниндидер күрше бер ханның сәяси агентлары уены түгел.

Историографиядә зур игътибар 1496 елгы вакыйгаларга бирелгән. Әйтик, С.М.Соловьёв әлеге түнтәрелешне Мөхәммәдәмин тарафыннан «...аларның [Казан феодалларының] хатыннарын көчләү һәм гыйффәтсезләү» белән бәйли [Соловьёв, 1989, с.69]. Г.И.Перетяткович монда «Урак җитәкчелегендәге шәйбани татарлар фиркасе» үз ролен уйнаган дип саный. Аның фикерен А.А.Зимин да хуплый [Перетяткович, 1877, с.130; Зимин, 1982, с.108]. М.Г.Худяков бу вакыйгаларда төп роль «шәхси мотивларга бәйле» дип саный [Худяков, 1991, с.54-55]. К.В.Базилевич Ибәк һәм Мамыкның нугайлар белән тыгыз мөнәсәбәте булганлыгын искәртә, әмма Казанда ул вакытта сәяси көрәш барганлыкны инкарь итә. Аның фикеренчә, «...Мөхәммәдәмин белән көрәш феодаль-династик төсмер алган» [Базилевич, с.353]. С.Х.Алишев һәм Х.Б.Салиева бу вакыйгаларда «нугай фиркасе» йогынтысын күрә [Алишев, 1995, с.45-46; Салиева, 2004, с.22]. В.В.Трепавлов Мамыкның Казанга явын, Төмән йортыннан мәхрүм ителгәч, Ямгырчы тарафыннан Казан ханлыгы тәхетенә лаеклы алмаш буларак тәкъдим ителүе белән бәйли. Тикшеренүче фикеренчә, Ибәк һәм Ямгырчы артына яшеренеп, Казан бәкләре дә тәхет чуалышларында шактый мөһим роль уйнаган [Трепавлов, 2002, с.118, 137]. Шулай итеп, Россия тарихчыла-

ры, бу сюжетны тикшереп, нинди дә булса бердәм фикергә килә алмады. Аларга шул чордагы бер минутлык вазгыятьне яки «шәйбаниләр фиркасе»нең ролен тасвирлау мөһимрәк булган. Болар барысы да мәсьәләне яңадан тикшерүне таләп итә. Беренчедән, шәйбани татарлары фиркасе билгеле бер сәяси максатларга ирешүне күздә тоткан нинидедер бердәмлек рәвешендә булмаган, ул вакытта, гомумән, бер фирка да оешып җитмәгән. 1495 елда Себер шәйбаниләре үзләренең төп йортларыннан мәхрүм калалар һәм, әлбәттә, Казан ханлыгында аларның мәнфәгатьләрен яклаучы фирка туа алмас иде. Казан бәкләренең Мамык шәхесенә карата кызыксынулары аның шәйбани түгел, ә Чыңгызый чыгышлы булуы белән аңлатыла. Моны, аларны Мөхәммәдәмин канәгатьләндермәвен игътибарга алсаң, җиңел кабул итәргә мөмкин. Казан тәхетенә икенче дәгъвачы — Габделлатыйф — Россиядә яши. Илһам һәм аның ир туганнары Карголомда тоткын итеп тотыла. Кырым ханы Миңлегәрәй үзенең хатыны Нурсолтанның балалары Мөхәммәдәмин һәм Габделлатыйфка ярдәм иткән. Шул рәвешле, Олуг Мөхәммәд угыллары теге яки бу сәбәпләр аркасында Казан аксөякләрен канәгатьләндермәгән. Шуңа күрә Казан тәхетенә кандидат булып Әхмәд хан угыллары һәм Себер шәйбаниләре генә кала. Дәште Кыпчактагы гомуми сәяси торышка нисбәтле, аларга Олы Урда ханы Әхмәд варислары да ошамый. Икенче яктан, Себер шәйбаниләре тәхеткә идеал кандидат була: йорттан мәхрүм ителү сәбәпле, аларның үз мәнфәгатьләрен яклавы шикле. Шул сәбәпле, Казан аксөякләренең Мамык шәхесе белән кызыксынуы аңлашыла. Аңа карата шундый ук кызыксыну, мөгаен, нугайларда һәм, аеруча, Ямгырчыда булгандыр. Мәгълүм ки, нугай аксөякләренә үз хакимиятен ныгыту өчен Чыңгызый хан кирәк, ә андый ханнар, гадәттә, «куллары» бәйле халәттә була [Трепавлов, 2002, с.101-103]. В.В.Трепавлов искәртүенчә, Ямгырчы Мамыкны «нугай тәхетенә» утырта. Моннан соң, үз хакимиятен ныгыткач (бу вакыйгаларга кадәр, 1491-1492 еллар чигендә, Урдада Муса һәм аның арасында көрәш бара), Нугай йорты ресурсларын «Казан проблемасын» хәл итүгә юнәлтергә мөмкинлек туа. 1496 елда Мамыкның Казанга явы нугайлар тарафыннан башкарылуы бернинди шик-шөбһә тудыра алмый. «Иоасафов елъязмасы»ның 1496 елдагы вакыйгалар турындагы мәкаләсендә Мамык «күп куәтле» шәйбаниләр патшасы буларак карала [ИЛ, с.131], әмма, мәгълүм булганча, бу вакытта Себер йорты аңа нисбәтле түгел, аңлашыла ки, чыганактагы «күп куәте» төшенчәсе башка чыганаклардан алынган булырга тиеш. В.Н.Татищев, елъязмалардагы хәбәрләргә таянып, бу мәгълүматны «нугай һәм Казан кенәзләренең күп куәте белән», дип шәрехли [Татищев, 1996, с.86]. 1475-1606 һәм 1493-1611 елгы разряд китаплары Мамыкны нугай патшасы дип атый [РГАДА, ф.181, оп.1, д.17, л.10 об.], әмма В.В.Трепавлов хаклы рәвештә әйткәнчә, Себер ханы «...Себер йорты халкы һәм ресурслары белән үзе теләгәнчә идарә итә алса», шәйбаниләргә номиналь буйсынган нугайлар белән хәл башкача булган: биләр үзләренең ханнарына сәяси стратегияләрен тәкрарлаганнар [Трепавлов, 1997, с.183]. Ибәк вакытында да шулай, Мамык чорында да, әле тагын да көчәймәгән булса, шулай калган. Шунысы ачык: гаскәр нугайларныкы булган һәм карарларны да нугай аксөякләре кабул иткән. Ямгырчы — бу вакытта Нугай Урдасының әйдаманы. Мөхәммәдәминне тәхеттән төшерүенең сәбәпләре дә бар, бу үзенең кияве Илһам ханны 1487 елда тәхеттән төшергәне өчен үч кайтару булыр иде. Ямгырчының 1496 ел вакыйгаларындагы роле турында ачыграк итеп 1497 елның мартында Мәскәүгә китерелгән Мусаның грамотасы нигезендә хөкем йөртергә мөмкин. Әлеге документта ва-

кыйгалар түбәндәге эзлеклелектә бәян ителә. Башта Муса «үзенең агаларына ачуланып, Төрекмәнгә китә», «агалары» кире кайтырга үтенәләр. Урдада аны җитди үзгәрешләр көтә: «Ямгырчы патша Казанга киткән», әмма Муса патшага «Иван кенәз өчен» баш ия һәм гаскәрне кире кайтарта. Моннан соң яу кабатлана, Муса язганча: «Һәм элекке кебек Казан кенәзләре белән кушылалар, патшаны алып Казанга һөҗүмгә китәләр». Муса, моңа җавап итеп, углын 2 мең кеше белән «йортны таларга» яуга җибәрә. Бу грамота, атчабарларның Нугай Урдасыннан уртача 3-4 ай килүләрен исәпкә алганда, 1496 елның ноябрь-декабрь айларыннан да иртәрәк язылмагандыр. Әлеге дата Мусаның Урта Азиядән Урдага кайту вакытын ачыкларга да мөмкинлек бирә. Тексттан күренгәнчә, вакыйга 1496 елның май аенда (апрель аеннан иртәрәк түгел) булган, нәкъ менә шушы вакытта Ямгырчы һәм Мамык Казанга һөҗүм башлый, бу яулар аларның казанлы фетнәчеләр илә Урдага кире кайтуы белән тәгәлләнә. Моннан тыш, һөҗүм 1496 елның сентябрендә яңадан оештырыла (вакыты грамотаның язылу датасына якын). Мусаның җавап гамәле башка чыганакларда яктыртылмый, гомумән, бу вакыттагы Казан ханлыгы тарихы документларда начар чагылыш тапкан. Шул рәвешле, Ямгырчы һәм Казан бәкләре әлеге вакыйгаларның үзәгендә торган, Мамык күпмедер дәрәҗәдә аларга бәйле фигура гына. Рус чыганаклары Мамык тарафдарлары булган Казан бәкләренең исемнәрен теркәп калдырган: Киләхмәт (Кәлимәт), Урак, Садыйр, Агыш (Агиш) [ПСРЛ, т.8, с.231].

Шунысы кызык: елъязмалар фетнә башлыгы итеп Киләхмәтне (Кәлимәт) күрәләр, әмма шулвакытта Уракның югары статуска ия булуы ачык. Шулай итеп, Воскресенская елъязмасындагы Мамыкның ир туганы Агалак солтанның уңышсыз һөҗүменә багышланган мәкаләдә Урак «Казан кенәзләренең кенәзе» буларак телгә алына [ПСРЛ, т.8, с.237], аңлашыла ки, бу — бәкләр бәге титулына калька. Гомумән алганда, 1496 елгы вакыйгаларны түбәндәге рәвештә кабат тергезергә мөмкин. Ханлыктагы югары даирәләрнең, Мөхәммәдәмингә каршы чыгып та, Мәскәүгә аның өстеннән шикаятьләр бирмичә һәм яңа хан җибәрүләрен үтенеп мөрәҗәгать итмичә, төньяк-көнбатыш күршесе химаясеннән котылырга омтылуы ачык күренә. Өстәвенә, Казан бәкләре ханлыгы булмаган ханны чакырып, аның өстеннән тулы буйсындыру-йогынты булдырырга һәм теләсә кайсы читтәш дәүләт ярдәмендә ханлыкның суверенитетын тәэмин итәргә өметләнгәннәр. Әмма, мәгълүм булганча, бу ният барып чыкмый, һәм Киләхмәт (Кәлимәт) үзе ярдәм иткән ханга каршы оппозицияне җитәкли. Шулай итеп, 1496 елда хан алыштыру «рус» һәм «шәйбаниләр» фиркасе арасындагы көрәш нәтиҗәсе түгел, ә Мөхәммәдәмин һәм Казан аксөякләренең эчке каршылыклары нәтиҗәсендә килеп чыккан. И.И.Смирнов белән К.В.Базилевич бу вакыйгаларда фиркаләр көрәше эзләрен тапмаулары белән хаклы [Смирнов, 1948, с.19; Базилевич, 2001, с.352-353], әмма шул ук вакытта аларның хан алыштыруны «феодаль-династик» дип тасвирлаулары белән килешергә ярамый. Бу карашны кабул итү мөмкин түгел, чөнки килеп туган вазгыятьнең үзенчәлеге шуннан гыйбарәт: төбәктә теләсә кайсы сәяси көрәш «династик төсмер» алырга мәҗбүр. Ямгырчы да, Казан бәкләре дә 1480 еллардан башлап вакыйгалар барышына нык кына тыкшына башлаган «рус факторын» исәпкә алмый калмаган. Барыннан да бигрәк Россиянең позициясе 1496 елның маенда ачык күренә. Хан сорап, Россиядән башка тарафларга (бередә тәхеткә дәгъвалаучы башкалар да, мәсәлән, Габделлатыйф була) мөрәҗәгать итү, Мөхәммәдәмингә Казанда каршы торучыларның позицияләре Россиягә дә каршы булганлыкны җитәрлек дәрәҗәдә ача. Фетнәчеләр башлыгы Киләхмәтне

(Кәлимәт) нугайлар белән союздан күңеле кайту һәм алар карамагындагы шәйбаниләрдән канәгатьсезлек кичерү Россия яклы позициягә китерә. Мамыкны куып җибәргәч, ул Иван IIIтән, фәкать Мөхәммәдәмин булмасын, дигән бердәнбер шарт куеп, хан сорый. Бу шарт үтәлә: Казанга яңа гына Кырымнан кайткан Габделлатыйф бине Ибраһимны җибәрәләр [ПСРЛ, т.12, с.235].

1505 елда Казан ханлыгына Мәскәү карамагыннан котылу насыйп була. Бу кискен үзгәрештә нугайлар актив катнаша. «Казан тарихы» авторының версиясе буенча, Мөхәммәдәминнең бөек кенәзгә хыянәтендә төп рольне хатыны Каракош уйнаган. Нәкъ менә ул ханны Иван IIIтән читләшергә котырта [КИ, с.280]. «Казан тарихы» авторы фикеренчә, моңа, турыдан-туры булмаса да, Ямгырчының үз кызы — Каракош — язмышы өчен борчылуы дәлил булып тора. Бу 1504 елның сентябрендә нугай илчелеге грамоталарында искәртелә [Посольская, 1984, с.52].

К.В.Базилевич, бу тарихи сюжетны тикшереп, Нугай Урдасы Казандагы кискен үзгәрешләрдә хәлиткеч роль уйнаган дигән төпле фикергә килә. Ул Каракошның бу вакыйгалардагы ролен киметә, гомумән алганда, нугайларның Мәскәүгә каршы торуларын Ямгырчы һәм аның нәсел-нәсәбе белән бәйли [Базилевич, 2001, с.480]. Тикшеренүче фикеренчә, нугайлар Мәскәү белән Олы Урда арасында көрәш барган елларда «Әхмәд балаларына» ярдәм иткәннәр. Бары тик Шәех Әхмәд җиңелгәннән соң гына нугайларның Россия белән арасы тынычлык сәясәтенә таба борыла. Гомумән, К.В.Базилевич 1505 елгы вакыйгаларда Нугай Урдасы белән электән барган дипломатик комбинациянең генә түгел, ә Бөек Литва кенәзлегенең һәм хәтта Төркиянең дә катнашы бар дип уйлаган [Базилевич, 2001, с.480-482]. Нугай Урдасының Россиягә дошманлыгы һәм нугайларның Олы Урдага ярдәм итүе турындагы тезис берничә сәбәп аркасында бернинди тәнкыйтьне күтәрми. Җаек буена көченеп киткәнче үк, нугайлар Олы Урда белән дошманнарча мөнәсәбәттә булганнар. 1420 елның азагыннан башлап 1430 елның азагына кадәрге дәвердә, Вәкъкас би вакытында, нугайлар Олы Урдалыларны Идел белән Җаек елгалары арасындагы җәйләүләрдән кысрыклап чыгара башлый [Трепавлов, 2002, с.127]. Олы Урданың мангытлары арасында (Нугай Урдасындагы төп этник төркемнең кардәшләре) нугайлар озак вакытка явызлык символына әверелә [Сикалиев, 1994, с.51]. 1481 елда нугайлар Әхмәд хан җәйләвенә һөҗүм итәләр һәм ханны үтерәләр. «Казан тарихы» авторы фикеренчә, бу вакыйгалар «Мәскәү гаскәре белән каршы торудан» соң булган [КИ, с.262], ягъни нугайлар 1480 елгы вакыйгалардан соң Олы урдалыларның авыр хәленнән файдаланганнар. Аннан соңгы вакыйгалар да нугайлар җитәкчелегендә «Әхмәд балаларына» карата ниндидер яхшы мөгамәлә булган дип уйларга урын калдырмый. Олы Урда белән көрәш рус дәүләте белән Нугай Урдасы арасында якынаю ноктасы булып, рус-нугай мөнәсәбәтләре урнаша башлауны тәэмин итә. Бары тик эчке сәяси көрәштә булган җитди өзлегү генә Мусаны урдалылар белән якынаю чарасын эзләүгә этәрә. Мәгълүм документлар буенча, Ямгырчы да Олы Урдага каршы булган. Гомумән алганда, нугайларны «Әхмәд балаларының» союзниклары дип санавы авыр. «Казан тарихы»ның авторы фикеренчә, нәкъ менә нугайларның һөҗүмнәре сәбәпле, Олы Урда бушап кала: аларны җәйләүләреннән кысрыклап чыгаралар һәм җирләрне яулап алалар [КИ, с.270].

Нугайлар белән Россиянең конфликтлары Казан ханлыгының киләчәгенә кагылышлы төрлечә күзаллаулар җирлегендә барлыкка килә. Биредә Ямгырчының роле аеруча нык сизелә. Ул 1487 елда тәхеттән төшерелгән Илһам ханга ярдәм итә, 1496 елда Казан тәхетенә Мамыкны утырта, 1500 елда

Муса белән бергәләп Казанны камый. Әмма болар артына тышкы сәясәтнең озак вакытка исәпләнгән фундаменталь программасы яшерелмәгән. Ямгырчының төп максаты Казанны билгеле бер күзәтү астына алуга ирешү була, шуңа күрә Мөхәммәдәмингә кызын кияүгә биреп, тынычсыз нугай һөҗүмнәрен туктата. Бу вакыйгаларда төрек факторы, гомумән, юк. Хәзерге заман белгечләренең күзәтүләренә караганда, XV йөз — XVI гасыр башында Россия һәм Госманлы дәүләте берберсен танып белү, мәгълүмат туплау дәверендә генә була, шунлыктан ике яклы мөнәсәбәтләрдә катнашучыларның кайсысына да булса каршы актив сәясәт алып барыр өчен, әлегә шартлар тумаган [Зайцев, 2002, с.74-78; Мейер, 2003, с.95, 107].

Гомумән алганда, 1505 елда Казандагы түнтәрелеш Россия, Нугай Урдасы һәм Казан ханлыгы катнашында Идел буе төбәгендәге халыкара мөнәсәбәтләр үсеше нәтиҗәсе булган. Түнтәрелешнең төп максаты — ханлыкның бәйсезлегенә ирешү. Ягъни монда да Казан аксөякләренең «фиркаләр»е көрәше турында сөйләргә нигез юк.

Гомумән, XVI гасырның 30 нчы елларына кадәр Казан «фиркаләре» турында сөйләве кыен. Бу вакытта, күрәсең, Казан аксөякләре төркемнәре геополитик мәнфәгатьләр буенча оешмаган. 1531 елгы Казан түнтәрелеше турындагы елъязма мәгълүматы тышкы сәяси аерымлануның характерын ача. Сафагәрәй бу елның язында, рус дипломатиясе вәкиле Иван Полевны үтерергә һәм тынычлык турындагы рус-Казан килешүләрен таркатырга омтыла. Моңа җавап итеп, Гәүһәршад ханәкә, Кече Гали морза һәм Ширин Булат бәк җитәкчелегендәге Казан аксөякләре илчене үтерүгә каршы чыга. Хан тәхеттән төшерелә һәм Казаннан куыла, ә аның берничә киңәшчесе (алар арасында Раст бәк, Гали Шөкер углы) үтерелә. Аларны үтерүнең сәбәбен рус елъязмалары түбәндәгечә хәбәр итә: «патшага явызлык кылырга уйладылар» [ПСРЛ, т.13, с.56-57; т.20, с.410]. Әлбәттә, Казан аксөякләрен Россия «кочагына», аңа симпатиядән бигрәк, озак сугыш алып барырга теләмәү этәргән. Ягъни без бу вакытта Мәскәү һәм Кырым тарафдарларыннан бигрәк, сугыш һәм тынычлык фиркаләрен («карчыгалар» һәм «күгәрченнәр») күзәтәбез.

Мәскәү тарафыннан куелган яңа хан Җангали хөкүмәтенә Булат бәк һәм Табай бәк керә [ПСРЛ, т.13, с. 69]. Табай бәк 1529 елның җәендә Мәскәүдә тынычлык турында килешергә һәм мөнәсәбәтләрне җайга салырга килгән Казан илчелеген җитәкли [ПСРЛ, т.13, с.46; т.20, с.406; т.8, с.272]. Ул 1530 елның июнендә, Казан камалышта булган авыр көннәрдә, каланы тупка тотуны туктату һәм килешү төзү турында сөйләшүләр алып баручы комиссиянең башында тора [ПСРЛ, т.13, с.47; т.20, с.406]. 1531 елда Табай Мәскәүгә тынычлык турында килешү өчен килгән илчелекне җитәкли, әмма Сафагәрәй килешү процессын токтарлый. Ханның үз-үзен тотышы бәкне тирән кайгыга сала һәм кыен хәлгә куя. Табай бәк белән дипломатик сөйләшүләр алып баручы русларга Сафагәрәй хан «безне (илчеләрне) онытты, безнең болай эшләвебезне теләмәде» («нас забыл, а того не похотел, на чём мы зделали»), дип белдерә. Табай бу хәлне ханны кырымлылар, нугайлар һәм «андагы явыз кешеләр» чолгап алган булу белән аңлата. Илче сүзен болай дип төгәлли: «...аңамы соң Казанда патша булырга яки патша Казанга башка ханны җибәрсен» («...тому ли быть царю на Казани или иного государь царя пожалует на Казань пошлёт») [ПСРЛ, т.13, с.55]. Шулай итеп, Табай бәкнең позициясе үтәкүренмәлегә әйләнә.

Сафагәрәй Казан аксөякләре тарафыннан Россия белән тынычлык килешүе төзүгә юнәлтелгән планны җимерә. Нәкъ менә шул Табайны һәм аның фикердәшләрен Сафагәрәйдән читләштерә. Табай бәкне без Рус

дәүләте белән килешү тарафдары буларак кабул итәбез, шуның өчен аның руслар билгеләп куйган Җангали хан хөкүмәтенә керүенә гаҗәпләнәсе юк. 1535 елның 25 сентябрендә булган түнтәрелештә Җангали үтерелгәннән соң, тәхеткә Сафәгәрәй утыртыла, Табай бәк Нугай Урдасына Сафагәрәйнең хатыны, Мамай кызы артыннан чыгып китә. Бәк, бу миссияне башкарганнан соң, Казанга кайтмый. Никон елъязмасында аның турында дипломатлар хисабыннын алынганга охшаган бер ремарка бар: «ә тегенең исендә дә юк, бу эш ничек була» [ПСРЛ, т.13, с.105, стб.1]. Соңрак рус-нугай дипломатик язышуларында Табай бәкнең 1548 елда Россиядә булганлыгы теркәлеп калган [ПКСРНО, с.320, 324].

Карачы Ширин Булат бәкнең эшчәнлеге дә игътибарга лаек. Ул 1519 елның башында ук Казан тәхетенә Шаһгалине бирүләрен сораган илчелек составында була [ПСРЛ, т.8, с.206]. Аннары елъязмалар аның исемен 1530 елга кадәр, ягъни ул Казанны тупка тотуны туктату һәм килешү төзү турындагы сөйләшүләр алып бару комиссиясенә кертелгәнче, телгә алмыйлар [ПСРЛ, т.13, с.47; т.20, с.406]. Ул 1531 елда Мәскәү белән Сафагәрәйне тәхеттән төшерү турында яшерен сөйләшүләр алып бара, нәтиҗәдә, түнтәрелешне җитәкли. Карачы Ширин Булат бәк 1533 елда Казан хөкүмәтенең башында тора [ПСРЛ, т.13, с.56-57, 69]. Беренче карашка, ул историографиядә күп язылган «рус фиркасе» тарафдары сыман. Әмма 1535 елда Карачы Ширин Булат бәк Җангалинең үлеменә китергән түнтәрелештә катнашып кына калмый [ПСРЛ, т.13, с.88], ул, Сафагәрәйне чакырып, грамота җибәрү инициаторы була һәм аны тирә-якка сиздерми генә Казанга китертә [ПКСРНО, с.293]. Әмма карачы бәкнең «кырым романы» озакка сузылмаган. Ул 1541 елдан Сафагәрәйне төшерү турында сөйләшүләр башлап, яңадан Мәскәү белән уен башлый [ПСРЛ, т.13, с.99], ә 1542 елның мартында Мәскәүгә тынычлык турында килешү төзү өчен илчеләр җибәрә [ПСРЛ, т.13, с.142].

Китерелгән мәгълүматлар безне 1530 елларда — 1540 еллар башында Казанда төгәл геополитик мәнфәгатьләрне берләштергән «фиркаләр» булган, дигән фикергә шикләнеп карарга мәҗбүр итә. Аларның соңрак барлыкка килмәгәнме икәнлеген ачыклар өчен, 1540 еллар вакыйгаларын һәм аксөякләрнең эшчәнлекләрен карыйк.

1542-1545 елгы вакыйгалар Казан ханлыгы эчендәге каршылыкларның тирәнәюенә китергән. Монда 1545 елның язында рус гаскәрләренең Казан җирләренә явы мөһим роль уйнаган. Ханлыкка җитди зыян салына, Сафагәрәй хан уңышсызлыкка кискен җавап кайтара. Хан бу вакыйгаларга җирле аксөякләр гаепле дип фаразлый: «Алар бөек кенәзнең гаскәриләрен алып килделәр», — ди һәм аларга каршы репрессияләр башлый. Шуның нәтиҗәсе буларак, аксөякләр Россиягә һәм башка күрше илләргә күченәләр [ПСРЛ, т.13, с.146-147]. Бу вазгыятьне рус елъязмачылары бертөрле генә бәяли: «Казан тормышында шуннан каршылыклар башланды» [ПСРЛ, т.13, с.147]. Бу шәрехләү, безнең фикеребезчә, Казан халкының төрле якка таркалуын күрсәтә. Нәкъ менә шушы вакыттан инде Казан аксөякләре «фиркаләр»ен ачык күрергә мөмкин.

Сафагәрәй ханның репрессияләре фетнәгә китерә, нәтиҗәдә, хан янәдән тәхетен югалта. Мәскәүгә ханны төшерү турында сөйләшер өчен, Боерган сәет, Кадыш бәк һәм Нарык улы Чурадан торган илчелек җибәрелә [ПСРЛ, т.13, с.148]. Алар, мөгаен, Сафагәрәйгә каршы фирка җитәкчеләре булганнардыр. Тәхеттән төшерелгән хан җиңелүе белән килешми. Тиздән аңа Йосыф мирза ярдәме белән яңадан хакимияткә кайту насыйп була. Нәкъ менә рус-нугай дипломатик язышулары безгә 1545 елның азагы — 1546 ел вакыйгалары турында өстәмә мәгълүмат бирә.

Әйтик, Йосыфның 1549 елның июлендә Мәскәүгә барып җиткән хаты Россиягә качкан казанлыларның исемлеген тулыландырырга мөмкинлек тудыра. Эмигрантлар арасыннан Кол-Чура, Борнаш, Тәңреколый, Ислам, Галикәй морза, Хөсәен бәк, Килде морза, Шаһ-Чура, Табай бәк, Азбирде (Хаҗи-Бирде) углан исемнәре атала [ПКСРНО, с.294, 320]. Болардан тыш казанлыларның бер өлеше Нугай Урдасына кача. Алар арасыннан Боерган сәед, Иләмән бәк, Габдулла бахшый, Хөсрәү бәк телгә алына [ПКСРНО, с.294, 297]. Өстәвенә Йосыф грамотасының тексты качакларның саны моның белән генә чикләнмәгән, дип гөманларга мөмкинлек бирә. Әйтик, Йосыф бергәләшеп Казанга һөҗүм итү планын тәкъдим иткәндә, санап кителгәннәрдән кала, тагын ниндидер «Казан кенәзләре» турында яза [ПКСРНО, с.294]. Дипломатик язмалар 1546-1549 еллар белән турыдантуры бәйле кызыклы мәгълүматларны саклаган. Иван IV нең грамотасында Хөсрәү бәккә түбәндәгеләр хәбәр ителә: Казанда булган кырымлылар аны шуның өчен үтерергә теләгәннәр, чөнки ул «безгә (бөек кенәзгә – *авт.*) хезмәт итәргә өйрәнде». Шуннан соң Хөсрәү шәһәрдән китә, кешеләрне җыя һәм Казанга һөҗүм итә, кырымлылар белән сугыша, аннары Нугай Урдасына юнәлә [ПКСРНО, с.301-302].

Тасвирланган вакыйга, мөгаен, Сафагәрәйнең вакытсыз үлеменнән соң булган. Бу үлем варис мәсьәләсе күтәрелүгә сәбәп тудыра. Кече яшьтәге Үтәмешгәрәй кандидатурасы башта Сафагәрәйнең якыннары тарафыннан каралмый. Йосыф язуынча, «...Казанда яшәүче бәкләр» Кырымга «патша сорап» илчеләр җибәрә һәм нугайлар тарафыннан кулга алына. Соңрак Казаннан тагын бер илчелек җибәрелә. Кыскасы, нугайлар ул вакытта Кырым белән элемтә юлларын өзәләр [ПКСРНО, с.295-296]. Кырым солтанын чакыру тәкъдиме белән Ширин Мамай бәк, Раст улы Җанбарыс мирза чыга [Зайцев, 2004, с.159, 165-166]. Күренә ки, Хөсрәү бәк шушы планга каршы килгән. Шул рәвешле, аның Казанны ташлап китүен без 1549 елның кыш-яз айларына нисбәтле, дип әйтә алабыз. Шул ук елның августында ул Нугай Урдасында була.

Гомумән алганда, түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә мөмкин: шул ук 1546 елда тәхетне кабат кулына төшергән Сафагәрәй Казан аксөякләренә каршы репрессияләр үткәрә. Эзәрлекләүләрнең угы Нарык улы Чурага һәм аның якыннарына юнәлтелә. Нарык улы Чура үзе, түнтәрелештә катнашучы Кадыш бәк кебек үк, җәзалап үтерелә. Болар барысы да Мәскәү белән тыныч мөнәсәбәтләр яклы булган «Чура төркеме»нең Казан сәясәтенә йогынтысы юкка чыгуга китерә. Нәкъ менә 1549 елда историография «кырым фиркасе» дип әйткән күренешнең инде тулысынча формалашуы турында сөйләргә мөмкин.

Сафагәрәй вафатыннан соң, Казан ханлыгында төп фигура булып калган Раст улы Җанбарыс мирза «кырым фиркасе»нең әйдаманы булган. Ул барлык идарәне үз кулына туплый. Шәрифи Хаҗитархани язганча, ул «... шәһәр бәге, Болгар вилаяте хакиме, ..., солтанның өлкәләр буенча эшләр идарәчесе, хан казнасын яулап алучы...» [Хаджитархани, 1995, с.90]. Ширин Булат бәк улы үзенең атасы хакимиятенә варис була һәм шулай ук «кырым фиркасе» идеалларын яклый. Алардан кала, бу вакытка Казанга килеп урнашкан кырымлылар да мөһим роль уйный. Араларында танылган Кузычак углан һәм Ак-Мөхәммәд углан булуы мәгълүм.

Нәкъ менә 1549 елда рус фиркасе дә актив формалаша башлый. Мәскәү дипломатлары Нугай Урдасына, казанлы эмигрантларны Россиягә чакырып, «хәтәр грамоталар» юллыйлар. Әлеге документларга нигезләнеп, без кайберәүләренең елъязмаларда чагылыш тапмаган эшчәнлекләрен берникадәр тергезә алабыз. Әйтик,

елъязмачыларның күзеннән югалган Табай бәк 1548 елда Россиядә була [ПКСРНО, с.320, 324], ахыр чиктә Гыйльман бәк белән Хөсрәү бәк тә шунда китә, Боерган сәет нугай даласыннан Бохарага юнәлә [ПКСРНО, с.323].

1545-1549 елда Казан аксөякләренең капма-каршы якка аерылулары «рус» һәм «кырым» фиркаләре формалашуга китерә. «Рус фиркасе» — шактый шартлы төшенчә. Асылда, бу — Мәскәүдә кулга алынган һәм кире кайту хокукы өчен көрәшкән «эмигрантлар клубы». Аларның идеяләре — Россия дәүләте белән килешү. Бу вакыттагы «кырым фиркасе»ндә читтән килгән элемент йогынтысы сизелә һәм әлеге факт берничә тапкыр историографияләрдә дә искәртелә. Бу аксөякләр төркеме Кырым ханлыгы яклы була һәм Мәскәү белән араны өзүгә йөз тота. «Кырымлылар»ның уңышы озакка сузылмый. 1549, 1550 еллардагы Мәскәүдән Казанга яу белән килгән гаскәрне җиңүдән соң, «кырым фиркасе»н юкка чыгуга китергән җиңелүләр башлана. 1552 елда Чапкын мирза тарафыннан оештырылган соңгы фетнә безгә фиркаләрнең берсе белән дә бәйләнмәгән булып күренә. Ул ватанпәрвәрлек һәм шәхси амбицияләрнең берләшүе нәтиҗәсе төсен ала.

Шул рәвешле, безнең тикшерүебез түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкинлек бирә. Казан аксөякләренең геополитик ориентацияләре турында сөйләве кыен. Безнең уебызча, әлеге көрәшнең нигезендә төрле аксөяк төркемнәренең ханга, аның тышкы сәясәтенә йогынты ясарга омтылышы яткан. 1530-1540 елларда Казанда өч көчле төркем оешуын билгеләп үтик. Беренчесенең башында аристократия башлыгы булган карачы Ширин бәк торган. Башка төркемнәр — «нарыклар» (җитәкчеләре Чура) һәм «растлар» (оештыручысы Раст бәк). Күрәсең, нәкъ менә шушы төркемнәр эченнән геополитик юнәлешне табарга мөмкин. Растлар Кырым ханлыгы белән ачыграк бәйләнгәннәр, ә нарыклар барлык очракларда да, һәрхәлдә 1545 елдан башлап, Россия белән бәйле. Сафагәрәй ханның репрессияләре нарыкларның, һәм, гомумән, Казан аксөякләренең ролен юкка чыгара. Казан ханлыгының соңгы елларына инде Шаһгали хан растларның йогынтысын бетерә [ПСРЛ, т.13, с.172].

Шунысын искәртергә кирәк: бу «партеногенез» процессы озакка сузылган. Әйтик, 1530 еллар — 1540 еллар башына нисбәтле тынычлык һәм сугыш яклы фиркаләр аерымланып күренә. Вакыйгалар ханлык эчендәге каршылыкларның тирәнәюенә китерә. 1545 елдан Казан элитасының үзара килешмәгән, дошманлашкан төркемнәргә аерылулары ачык билгеләнә. 1549 елга рус һәм кырым фиркаләре оешуын ышанычлы рәвештә дәлилләргә мөмкин.

Китерелгән күзәтүләр шуны күрсәтә: Г.И.Перетяткович тарафыннан нигез салынган фиркаләр турындагы концепция 1540 елга кадәр рус чыганаклары белән расланмый. Шул ук вакытта әлеге тәгълимат Казан ханлыгы һәм рус-Казан мөнәсәбәтләрен аңлату омтылышы булып бәяләнә ала. Әлеге гипотеза уңышлы булып чыга ки, аны алдагы еллар историографиясе бик теләп кабул итә.

Чыганаклар һәм әдәбият исемлеге

1. Азовцев, 2002 — Азовцев А.В. Личные имена Рязанского уезда конца XVI в. (По материалам писцовых книг) // Рязанская Старина. — №1. — М., 2003. — С.14-48.
2. Алишев, 1990 — Алишев С.Х. Исторические судьбы народов среднего Поволжья. XVI — начало XIX вв. — М., 1990.
3. Алишев, 1995 — Алишев С.Х. Казань и Москва: Межгосударственные отношения в XV-XVI вв. — Казань, 1995.
4. Базилевич, 2001 — Базилевич К.В. Внешняя политика Русского централизованного государства. Вторая половина XV века. — М., 2001.
5. Барт, 2008 — Барт Р. Нулевая степень письма. — М., 2008.
6. Ерусалимский, 2006 — Ерусалимский К.Ю. Исторические exempla Посольского приказа // Труды кафедры истории России с древнейших времён до XX века. — СПб., 2006. — С.307—328.

7. Зайцев, 2002 – Зайцев И.В. Мнимый протекторат: Казанское ханство и Османская империя в середине 20-х годов XVI в. // Восточная Европа в древности и средневековье: Мнимые реальности в античной и средневековой историографии. XIV Чтения памяти члена-корреспондента АН СССР Владимира Терентьевича Пашуто. – М., 2002. – С.74-78.
8. Зайцев, 2004 – Зайцев И.В. Астраханское ханство. – М., 2004.
9. Зимин, 1982 – Зимин А.А. Россия на рубеже XV-XVI веков. (Очерки социально-политической истории). – М., 1982.
10. ИЛ – Иоасафовская летопись. М., 1957.
11. Карамзин, 1989 – Карамзин Н.М. История государства Российского. Кн. II. Т.VI. – М., 1989.
12. КИ – Казанская история // Библиотека литературы Древней Руси. Т.10. – СПб., 2004.
13. Клосс, 1980 – Клосс Б.М. Никоновский свод и русские летописи XVI-XVII веков. – М., 1980.
14. Мейер, 2003 – Мейер М.С. Россия и Османская империя от начала XVI в. до 1569 г.: Формирование общих границ двух государств // От Стамбула до Москвы. Сборник статей в честь 100-летия профессора А.Ф.Миллера. – М., 2003. – С.91-116.
15. Моисеев, 2010 – Моисеев М.В. Обоснование прав на Казанское ханство в русском средневековом нарративе // Мининские чтения. – Нижний Новгород, 2010. – С.395-402.
16. Морозов, 2005 – Морозов В.В. Лицевой свод в контексте отечественного летописания XVI века. – М., 2005.
17. Перетяткович, 1877 – Перетяткович Г.[И]. Поволжье в XV и XVI веках (очерки из истории края и его колонизации). – М., 1877.
18. ПСРЛ, т.8 – Полное собрание русских летописей. – СПб., 1859. – Т.8.
19. ПСРЛ, т.12 – Полное собрание русских летописей. – М., 2000. – Т.12.
20. ПСРЛ, т.13 – Полное собрание русских летописей. – М., 2000. – Т.13.
21. ПСРЛ, т.20 – Полное собрание русских летописей. – М., 2005. – Т.20.
22. ПСРЛ, т.22 – Полное собрание русских летописей. – СПб., 1911. – Т.22.
23. Посольские, 1984 – Посольские книги по связям России с Ногайской Ордой 1489-1508 гг. – М., 1984.
24. ПКСРНО – Посольские книги по связям России с Ногайской Ордой 1489-1549 гг. – Махачкала, 1995.
25. Присоединение, 2003 – Присоединение Среднего Поволжья к Российскому государству. Взгляд из XXI века. – М., 2003.
26. Рахимзянов, 2005 – Рахимзянов Б.Р. Летописные известия о правлении касимовских ханов в Казани в первой половине XVI в. // Восточная Европа в древности и средневековье. Проблемы источниковедения. XVII Чтения памяти члена-корреспондента АН СССР Владимира Терентьевича Пашуто. IV Чтения памяти доктора исторических наук Александра Александровича Зимина. Тезисы докладов. – М., 2005. – Ч.I. – С.248-251.
27. Салиева, 2004 – Салиева Х.Б. Ногайская Орда во взаимоотношениях России с Казанским ханством в конце XV – середине XVI в.: Автореф. дисс. ... канд. ист. наук. – Махачкала, 2004.
28. Сикалиев, 1994 – Сикалиев А.И.-М. Ногайский героический эпос. – Черкесск, 1994.
29. Смирнов, 1948 – Смирнов И.И. Восточная политика Василия III // Исторические записки. – М., 1948. – Т.27. – С.18-66.
30. Соловьёв, 1989 – Соловьёв С.М. Сочинения. Кн.3. Т.5-6. – М., 1989.
31. Татищев, 1996 – Татищев В.Н. Собрание сочинений. – М., 1996.
32. Трепавлов, 1997 – Трепавлов В.В. Сибирско-ногайские отношения в XV-XVII вв. (основные этапы и закономерности) // Взаимоотношения народов России, Сибири и стран Востока: история и современность. Кн.2. – М.; Иркутск; Тэгу: Иркут. гос. пед. ун-т, 1997. – С.180-186.
33. Трепавлов, 2002 – Трепавлов В.В. История Ногайской Орды. – М., 2002.
34. УЛС – Устюжский летописный свод (Архангелогородский летописец). – М.-Л., 1950.
35. Шмидт, 1954 – Шмидт С.О. Предпосылки и первые годы «Казанской войны» (1545-1549) // Труды Московского государственного историко-архивного института. Т.6. – М., 1954. – С.187-256.
36. Хаджитархани, 1995 – Шерефи Хаджитархани. Зафер наме-и вилает-и Казан / пер. Ф.Хакимзянова // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 1995. – №1.
37. Худяков, 1991 – Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. –М., 1991.
38. Pelenski, 1974 – Pelenski J. Russia and Kazan: Conquest and Imperial Ideology. – Paris: The Hague Mouton, 1974.

Русчадан ***Ленар Гобәйдуллин***
тәрҗемәсе

ШАГЫЙРӘ

САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВА
(03.10.1926 — 10.05.1980)

КЕШЕ

Лачын диләр,
канат кагып горур очканга.
Лачын булсам, җирне сөймәс идем.
Мин — кеше.
Ут шикелле диләр,
кулы тисә — эш яна.
Ут булсам, соң әллә сүнмәс идем?
Мин — кеше.
Алтын диләр,
бик кирәгем чыкса, куштаннар,
алтын булсам, бер сатылыр идем.
Мин — кеше!
Ярага — тоз, арага ут сала
дошманнар,
корыч булсам да бер эрер идем.
Мин — кеше.

* Шагыйрә Саҗидә Сөләймановaның кайбер сүз энҗеләре белән журналның башка битләрендә таныша аласыз.

КӘШШАФ МОХТАРОВ – БЕРЕНЧЕ СУВЕРЕНИТЕТ «АТАСЫ»*

РӘМЗИ ВӘЛИЕВ,
тарих фәннәре докторы, профессор

ОКТЯБРЬ РЕВОЛЮЦИЯСЕ ҺӘМ ГРАЖДАННАР СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫНДА ТАТАРЛАРГА БАРЫН ДА БИРЕРГӘ ВӘГЪДӘ ИТКӘН ҮЗӘК, ТОРА-БАРА СӘЯСӘТЕН ҮЗГӘРТЕП, УРЫНДАГЫ МИЛЛИ ХӘРӘКӘТЛӘР БЕЛӘН КӨРӘШ БАШЛЫЙ. 1923 ЕЛНЫҢ ИЮНЬ АЕНДА МӘСКӘҮДӘ РКП(б)НЫҢ ЯШЕРЕН КИҢӘШМӘСЕ ҮТӘ. АНДА МИЛЛӘТЧЕЛЕККӘ-СОЛТАНГАЛИЕВЧЕЛЕККӘ КАРШЫ КӨРӘШ ИГЪЛАН ИТЕЛӘ.

Бу яшерен киңәшмәдә Казаннан С.Сәетгалиев, К.Мохтаров, Р.Сабиров чыгыш ясый. Киңәшмәнең икенче утырышында (10 июнь) «уңнар»ны тәнкыйть итеп, Фрунзе болай дип белдерә: «Минем өчен солтангалиевчелек коммунизм флагы астына яшерелгән вак буржуаз идеологиядән башка берни дә түгел» [1]. Фрунзедан соң Орджоникидзе, Скрыпник, Мануильский трибуна янына чыгалар һәм чын шовинистик рухта чыгыш ясыйлар. Ниһаять, ТАССР ХКСның рәисе К.Мохтаровка сөйләргә 10 минут вакыт бирелә. Оста оратор, тирән фикер иясе сынатмый. Аның чыгышын без тулы килеш бирергә булдык, чөнки бу документ укучыларга билгеле түгел.

«Иптәшләр, сездә кайбер иптәшләрнең нотыклары тәэсирендә берьяклы караш шәүләсе барлыкка килмәсен өчен, тикшерелә торган мәсьәләнең кайбер моментларына игътибар юнәлтәсем килә. Иптәш Каменев һәм иптәш Куйбышев билгеләп үткәнчә, киңәшмәнең максаты — үзара аңлашуга ирешү бит. Әгәр берьяклы гына карасак һәм бигрәк тә тема буенча сөйләмәсәк, моны аңлаудан читкә китәргә мөмкин.

М.Солтангалиев соңгы вакытка кадәр татарлар арасында революционер-большевик буларак танылды. Ул Кызыл Армиядә, башка күп пролетар оешмаларда, иң җаваплы урыннарда эшләде. Һәм иптәш Орджоникидзе уйлаганча, аның аерым гаскәри берәмлекләр оештыруда катнашуы да очраклы түгел иде. Ул күп эшләрдә катнашты һәм иң кискен минутларда да нindидер шикшөбһәләрдән азат булды. Аннан соңгы эшчәнлеге һәм Мәскәүдә зур постларга тәкъдим ителүе, Милләтләр эше буенча халык комиссариаты коллегиясе әгъзасы һәм Җир эшләре буенча федераль комитет рәисе кебек югары урыннарга күтәрелүе аның безнең партия эчендә булуы очраклы түгеллеген аңлата.

Әгәр дә шул рәвешле партиянең берничә мәртәбә аңа ышаныч белдер-

*Ахыры. Башы журналның 7 нче санында.

гәнен таныйбыз икән, килешәсездер, татар, башкорт һәм башка милләт Наркомнац хезмәткәрләренең аңа ышанычы булуы сәерме? Минемчә, монда гайре табигый бернәрсә дә юк. Әгәр дә без катгый рәвештә аның контрреволюцион гамәленнән читләшәбез икән, барыбер революцион эшчәнлеге дәверендә аның белән бергә баруыбызны һәм күпләребезгә революцион яктан үсәргә булышканлыгын инкарь итә алмыйбыз. Шәхсән мин, күпләр дәлилләргә тырышканча, табигатьтән аңа бирелгән милләтчелекнең мантыйкый йомгагы җинаять була ала дип санамыйм. Биредә бу хакта әйттеләр инде: мондый хәл теориядә һәм гамәлдә була алмый. Мин М.Солтангалиевнең әүвәлге эшчәнлегендә контрреволюцион чагылышлар күзәтелмәде дип уйлыйм, без аларны күрмәдек дип игълан итәм, моны ҮК та раслый ала. Димәк, җинаятьнең яралу вакыты соңгы чордагы вакыйгалар белән бәйле, һәм моңа мине Советларның X съездыннан башлап партиянең XII съездына кадәрге диярлек вакыт аралыгындагы мохит ышандыра. В.И.Ленин язганча, безнең өчен чит булган совет аппараты Советларның X съездында барлык халыкларның үзбилгеләнүләрен бетерү кебек карарларын кабул итте. Билгеле бер шартлар тәэсирендә бу «самодержавиячел» аппарат җитәкчелегенә И.Сталин килде.

Мондый ният дулкыны барлык төбәкләргә дә үтеп керде. Ә бу вакытта милли руспубликалар мәсьәләләрен үткәрү, тормышка ашыру катлауланды һәм кыенлашты. Моңа мисаллар хәтта Татреспубликадагы мөнәсәбәтләрдә дә күп.

Җир кодексын гамәлгә ашыруны искә төшерү дә җитә. Гадел таләпләрне канәгатьләндерүгә ирешер өчен, Политбюрога мөрәҗәгать итәргә туры килде. Һәм бу вакытта юкка гына Наркомземның һәрбер ишегенә партия программасыннан милли мәсьәләләр

К.Г.Мохтаров, ТАССР ХКС рәисе (1921-1924). Казан, 1922 ел. ТР ҮДТСДА фондыннан

турындагы өземтәне ябыштырып куярга кирәк дип әйтмәделәр. Шулай итеп бу дәвердә киеренке халәт тудырылды. М.Солтангалиев тә үзенең башкарган вазифасына бәйле рәвештә кискен басым астында калды. Мин моны М.Солтангалиев кылган гамәлнең меңнән берен аклар өчен генә булса да әйтмим. Тагын бер мәртәбә тәкрарлыйм, аның гамәлен без кискен һәм катгый хөкем итәбез.

Алга таба мин Татреспубликаны ялгыш бәяләүгә тукталырга тиеш, чөнки республикадагы милләтчелекнең булуын Солтангалиевнең җинаяте дип әйтәләр. Минемчә, бу дәлилсез. Бу гаепләү нәрсәгә нигезләнә? М.Солтангалиевнең татар хезмәткәрләренә хат язуынамы (ул безгә беркайчан да бер басмачы турында да язмады) яки Татарстан вәкиллегенең курьерларын тиешсез максатларда файдалануы, яки революцион хәрәкәтләр вакытында татар эшчеләре белән очрашуынамы? Ирексездән шундый тәэсир туа: гаепләү җиңел уйлап, җитди булмаган рәвештә ташланган. Ә гаеп бик катлаулы. Күп еллар партия сафында атлап барганда, иң авыр шартларда милли республи-

ТАССР Советының III съезды президиумы. Казан, 5 декабрь, 1922 ел. ТР ҮДТСДА фондыннан

кага гына түгел, ә рус иптәшләр белән дустанә мөнәсәбәт булдырып, өлешчә генә булса да, артта калган татар крестьяннарының Совет хакимиятенә аңлы рәвештә теләктәшлек күрсәтүенә ирешкәндә һәм, ниһаять, Татар командирлар хәзерләү курсларында тәрбияләнүчеләр Бохарада басмачыларга каршы сугышканда, югары хәрби җитәкчеләрнең бүләк һәм мактауларына лаек булганда — бу мизгелдә татар хезмәткәрләрен революциягә хыянәттә гаепләү, гафу итегез, мәгънәсезлек. Барыннан да бигрәк ҮК, аның секретарьлары (моны иптәш И.Сталин да раслый) гамәлләребезне һәм эшчәнлегебезне бер генә тапкыр хупламады. Шуның өчен мин иң әүвәле безнең эшчәнлекне якыннанрак тикшерергә, шуннан соң гына нәтиҗә ясарга кирәк булгандыр дип уйлыйм. Ә кайбер иптәшләр үзләренең каршылыклары белән бик тирәнгә керә һәм коралны кирәкмәгән урында кулллана. Алар барысын да бер күчкә өя — әйтик, мисал өчен биредә «суллар» һәм «уңнар»ның элеккеге көрәшен искә төшерделәр һәм аны тикшерелә торган мәсьәлә белән бутадылар».

Тавыш: «Безнең өчен борчылмагыз».

Мохтаров: «Мин сезнең өчен борчылмыйм, безнең территорияләр төрле».

И.Сталин: «Юл бер».

Мохтаров: «Әйе, юлыбыз бер, барыбыз теге дөньяга китәчәкбез... Миңа калса, моны болай эшләргә ярамый. Чөнки ике төркемнең дә элементлары партиядә кала бирә һәм аларның контрреволюция белән бернинди дә уртаклыклары юк. Иптәш Каменев инде бер иптәшне тема буенча гына сөйләвен үтенеп бүлдерде, кузгатылган мәсьәләләр буенча фикер алышу урынлы булыр дип уйлыйк, биредә «уңлык»ка һәм «суллык»ка инде кагылып үттеләр, шул сәбәпле мин ике-өч сүз әйтеп китәргә мәҗбүрмен.

Бухарин, соң булса да, XII съездда үзенең хатасын ахмаклык буларак танып, бик яхшы эшләде. Әмма Шамигулов кебекләрне туендырып торды. Алар үзләрен Ленин шәрехләгән милли мәсьәләләргә каршы куйды. Без Татреспубликада Ленин мәктәбе буенча эшләдек. Безнең Татреспублика шарт-

ларында каршылыкларыбыз партиянең X съездына кадәр үк тирәнәйде: «суллар» төрле милләтләрнең социаль-икътисади хәлләренең үзенчәлекләрен аермадылар. Без исә социаль-икътисади үсешнең төрле стадияләрен исәпкә алырга кирәклеген әйткән идек. Партиянең X съезды мондый карашның дөреслеген, революцияләштергәндә, мәсәлән, Төркестанның, атлы кавалерия һөҗүме системасының бернигә дә ярамаганлыгын аеруча төгәл ассызыклады. Һәм бары тик шуннан соң гына «суллар» тышкы яктан үзләренең хаталарын аңлады, идеалистик карашлардан читләшергә кирәклекне таныды.

Без бу моментларга җентекләбрәк, күрәсең, көн тәртибендәге алдагы мәсьәләләрне тикшергәндә тукталырбыз. Үзен 1921 елны төнге сәгать 12дә, Мәскәү тарафдары буларак, Татреспубликадан куып чыгардылар, дип белдергән С.Сәетгалиевнең гозеренә генә тукталып үтәм. Мондый белдерүне, әлбәттә, бары тик елмаеп кабул итәргә мөмкин. Без бит Керзон илендә яшәмибез. Мин чынбарлыкта эшнең ничек булганлыгы турында сөйләп үтәм һәм моны Татреспублика Өлкә комитеты архивы документлары нигезендә теләсә кайчан тикшерергә мөмкин. Эш шунда ки, Өлкә комитеты да, партконференция дә С.Сәетгалиев җитәкләгән хөкүмәтнең эшкә яраксызлыгын таныды, эшлекле ният белән аның составын яңартырга, кайбер әгъзаларын алыштырырга, дигән карар чыгарды. Моннан соң иптәш С.Сәетгалиев...»

С.Сәетгалиев: «Конференция ничә тавыш белән моны раслады?»

Мохтаров: «Күпчелек».

С.Сәетгалиев: «46 каршы булды, 52 яклады».

Мохтаров: «Саннарны җыйнау Сезнең эш. Әйтергә кирәк, иптәш Сәетгалиев Өлкә комитетының карарыннан соң икенче көнне ике төркем татар коммунистларын җыя («суллар» дип аталган үзенекен дә, «уңнар» дип аталганнарны да) һәм рус коммунистларына бергәләп каршы чыгу кирәклеге мәсьәләсен куя...»

С.Сәетгалиев: «Ялган».

Мохтаров: «Мин моны документлар белән дәлиллим. Алар русларга каршы төшәргә кирәк, дип сөйләде, чөнки тегеләр, татар хезмәткәрләрен даими рәвештә алыштырып, республика белән үзләре идарә итәргә тели. Килешәсездер, бер чиктән икенчесенә сикерү мөмкинме? «Уңнар» дип аталучылар моны партиягә каршы гамәл һәм милләтчелек дип игълан итә, бу мәсьәләдә катнашудан баш тарта. Алга таба вакыйгалар болай булды: С.Сәетгалиевнең бер хезмәттәше — иптәш Касыймов — съездның партиягә кермәгән делегатлары арасында Өлкә комитетының әлеге карарына каршы агитация ясады, шуның белән үзендә һәм аның кебекләрдә булган принципсызлык куркынычын күрсәтте. Шулвакытта Өлкә комитеты С.Сәетгалиевкә Татреспубликадан китәргә боерды. Кая монда, иптәшләр, Сәетгалиевне Мәскәү вәкиле буларак эшеннән алу?

Йомгаклап, иптәшләр, мин тагын бер мәртәбә тәкрарлыйм: Татреспубликада басмачылыкка урын юк; безнең бу мәсьәләдә катнашуыбыз һәрвакыт югары сыйфатлы һәм күпсанлы кызыл көч белән билгеләнәчәк» [2].

11 июньдә булган IV утырышта, Рәүф Сабиров та, статистик материалга нигезләнеп, мәгълүматлы һәм эчтәлекле чыгыш ясый. Ул ачлык елларындагы авырлыкларга басым ясап, бары тик 1922 елда гына «мәгариф-мәдәният оешмаларын 1920 ел дәрәҗәсенә күтәрү мөмкин булды... Без беренче баскычлы мәктәпләрне яңадан тергезә алдык. Хәзер ике авылга бер мәктәп һәм 20-25 авылга бер мәгариф-мәдәният оешмасы. Ирешкәннәр, әлбәттә, революциягә кадәрге иске чор белән чагыштырганда, зур... Хәзер безнең ике педагогика техникумы, бер татар театр техникумы һәм бер авыл хуҗалыгы техникумы бар. Моннан тыш рабфаклар аша без югары уку йортларына 1 мең 916 татарны үткәрә

алдык» [3], — ди. Алга таба Р.Сабиров татар театры эшләве, көнчыгыш музее оешуы, дәүләт нәшрияты тарафыннан ике ел эчендә татар телендә 156 исемдә китап, 4 татар газетасы нәшер ителүе хакында сөйли. Кыенлыклар турында да әйтә. Республика мәктәпләре өчен 15 мең мәгариф хезмәткәре кирәк булуын искәртә. Татар телен гамәлгә кую мәсьәләсенә килгәндә: «Бездә татарлар — 51%, руслар — 40%, калганнар — 8%… Күп кантоннарда татар халкы күпчелекне тәшкил итә һәм татар телен гамәлгә кую алай кыен булмас. Без инде моңа гамәлдә керештек һәм бу өлкәдә өлешчә уңышларыбыз да бар. 56 волостьта татар теле гамәлгә куела, ягъни бу төбәкләрдә барлык канцелярия эшләре дә татар телендә бара. Хәзер 4 кантонда тәҗрибә бара һәм аларның күп кенә бүлекләре язу эшләрен волостьлар белән татар телендә алып бара. Шулай итеп, бер ел дәвамында эшне хәзерге кебек эзлекле һәм ныклы дәвам итсәк, бер елдан соң татар телен һәр волостьларга, кантоннарга һәм Татреспубликаның барлык үзәк учреждениесенә дә кертү мөмкин булачак», [4] — дип белдерә. Гадел һәм намуслы коммунист буларак, Рәүф Сабиров әлеге һәм башка мәсьәләләрне тормышка ашыруда партиянең ҮК һәм Совет хакимияте ярдәм итәр дип ышана.

1921 елда кантон башкарма комитетларында татарлар 25% була, 1923 елга алар 48%ка җитә.

Шул ук елның июль аенда Казан шәһәрендә, «Мәскәү киңәшмәсе»нең дәвамы буларак, «Казан киңәшмәсе» дә уза. Өлкә комитеты секретаре Живов, җыелышны ачып, «Мәскәү киңәшмәсе» турында кыскача мәгълүмат бирә, М.Солтангалиевнең партиядән чыгарылуы, эшеннән куылуы, кулга алынуы хакында хәбәр итә. Нәтиҗәдә, 30лап чыгыштан соң, «Мәскәү киңәшмәсе»нең карарлары һәм М.Солтангалиевне фаш итү турындагы резолюциясе кабул ителә. Чыгыш ясаучылардан Гариф Енбаев, Николаев, Галл, Шәймәрданов, Рәүф Сабиров «Мәскәү киңәшмәсенең» «үзенчәлекле» булуы турында ачыктан-ачык әйтәләр. Ендаков киңәшмәнең «фәкать тикшерү рәвешендә» генә баруын ассызыклый. Буадан килгән вәкил Бәширов, М.Солтангалиев гаепле булса, шелтә бирергә генә кирәклеген, әмма Мохтаров, Енбаев, Сабировлар тарафыннан андый эшләр эшләнмәвен раслый. Рәүф Сабиров әйтүенә караганда, чынбарлыкта Татарстанда бернинди «солтангалиевчелек» юк, ә И.Сталинга, үзенең оппонентына һөҗүм ясар өчен, «контрреволюцион хәрәкәт»не уйлап чыгару кирәк була. Р.Сабировның хаклыгын башка төбәкләрдән килеп чыгыш ясаучылар да исбат итә. Мәсәлән, Тәтеш кантоны вәкиле Тёрский болай ди: «… миңа бу мәсьәләдә озак тукталырга туры килми, чөнки безнең Тәтеш кантонында милли мәсьәләнең бүгенге мохтәрәм җыелышта куелган кебек кискен торганы булмады» [5]. Балык Бистәсендә, Әгерҗедә, Болак арты Пләтән кантоннарында да шундый ук хәл күзәтелә. Авылларда татар телен яхшы беләләр, шуңа күрә дә эш кәгазьләре татар телендә алып барыла. Бу яңалык күпчелекнең теләге була. Киңәшмәдә, татар телен өйрәнү өчен, Татарстанда махсус төзелгән төркемнәрнең уңышлы эшләүләре турында әйтәләр. Бары тик Бөгелмә, Чистай кантоннарында гына бу эш авыр барган. Татарстан Республикасында суверенлык өчен көрәш барган чорда, милли проблемалар буенча бернинди дә аңлашылмаучанлык күзәтелми. К.Мохтаров бу турыда болай ди: «Барыннан да бигрәк һәм барыннан да алда партия оешмасының рус һәм татар өлешләре арасында үзара аңлашу барлыгын билгеләп үтәргә кирәк. Әлеге күренеш дөрес үткәрелгән милли сәясәтнең бөек державачылыкны кискен ачуын күрсәтә; үз чиратында, җирле милләтчелек күзәтелмәде диярлек. Төбәкләрдән килгән хисапларга игътибар итегез: бу документлар

Татарстан Республикасының 2 еллыгына багышланган митинг.
Казан, Театр мәйданы, 25 июнь, 1922 ел. ТР ҮДТСДА фондыннан

«Мәскәү киңәшмәсе» карарларының күбесе безнең тарафтан инде алдан ук тормышка ашырылганын дәлилли» [6].

К.Мохтаров, күпләрнең Мәскәү карарларын яклаячагын аңлап, үз чыгышында бу карарларны азрак йомшарту юлларын эзли. Менә шуңа күрә дә ул «шовинизм», «тузем милләтчелек», «солтангалиевчелекнең таралуы» кебек терминнарны куллана. Коллегаларын уйлап, акыл белән эш итәргә өнди. Ләкин Мәскәү карарлары «Казан киңәшмәсе» тарафыннан теләктәшлек таба.

Өлкә комитеты сәркатибе Живов И.Сталинның күрсәтмәләрен төгәл үти. Озак та үтми, Өлкә комитеты бюросы К.Мохтаровның Республикада үткәргән сәясәтен һәм аны М.Солтангалиев белән бәйләнештә булуда гаепли.

К.Мохтаров хакимиятен таркату һәм кулга алулар 1923 елның көзендә актив рәвештә тормышка ашырыла. «Мәскәү киңәшмәсе» «хакимиятне татарлаштыруны», татар телен дәүләт теле итүне бер ел эчендә тыя. 15 меңнән артык укытучы, дәүләт, партия органнары хезмәткәрләрен кулга алулар көтә, чөнки «Мәскәү киңәшмәсе» шуны таләп итә. Ә аның төп авторы И.Сталин урыннардагы партиянең Өлкә комитеты сәркатипләренең кыланышларын тикшереп тора. ТАССР коммунистларының җитәкчесе Живовның И.Сталин кушканнарны төгәл үтәгәнлеге архив документлары белән раслана.

1924 елның 18 мартында ТАССРда партиянең Өлкә комитетын И.Т.Морозов җитәкли башлый. К.Мохтаров, Г.Мансуров һәм А.Енбаев вазифаларыннан азат ителә. Кыска гына вакыт эчендә күренекле татар коммунист җитәкчеләрдән З.Булушов, Еникеев, Саттар, К.Хәйруллин, Үзәк башкарма комитеты рәисе Рәүф Сабиров, шәһәр башкарма комитеты рәисе Ратехин, аның урынбасары Ганиев эшсез кала. И.Сталин 1924 елда К.Мохтаров һәм аның кул астында эшләгән 15 кешене төрле төбәкләргә куып тарата. Имеш, бергә булып, үзләренең сәясәтләрен дәвам итә алмасыннар. Шуңа да карамастан, «уңнар» көрәшне туктатмыйлар. Сирәк булса да очрашып, аңлашып, хәлдән килгәнчә бер-берсенә булышып торалар.

Шул рәвешле «К.Мохтаров хакимияте» чорында зур активлык күрсәткән һәм татарларны хакимияткә тартуда (коренизациядә) зур уңышларга ирешкән татар зыялыларына ачыктан-ачык һөҗүм оештырыла.

Татарстан хезмәт ияләре, К.Мохтаровның эшеннән алыну хәбәрен ишеткәч, И.Сталинга махсус хат белән мөрәҗәгать итәләр [7]. Әмма «ил атасы» Казандагы завод-фабрика эшчеләренең моң-зарлары белән санлашмый. К.Мохтаров Мәскәүдә Сәламәтлек саклау халык комиссариаты коллегиясенең әгъзасы булып эшкә керешә. И.Сталин, Татарстан хезмәт иясләренә мөрәҗәгать итеп: «Без К.Мохтаровны Мәскәүдә җитәкчелек урынында файдаланырга телибез», — дип белдерә.

ГПУ «уңнар»ны 1929 елда кулга алганчы күзәтеп тора. 16 августта РСФСР Халык комиссариаты һәм РСФСР икътисади советларының берләштерелгән утырышында К.Мохтаровны эшеннән алу турында карар кабул ителә. Шул ук елны татар халкының күренекле җәмәгать эшлеклесе Соловки лагерена озатылып, 1937 елда атып үтерелә.

Тарихтан сабак алдыкмы?

Партия Үзәк комитеты урындагы милли үзенчәлекләрне истә тотып идарә иткән К.Мохтаров кебекләрне 1923-1924 еллардан соң акрын гына эшсез калдырып, аларга яла ягып, соңрак лагерьларга озату сәясәтен дәвам итә. Бу эштә И.Сталинга рус шовинистларыннан — Бажанов, Шварц, Жуков, Иванов, ә татарлардан Гафуров, Касыймов, Габидуллин, Гайнуллин һәм Гыймранов зур булышлык күрсәтә. Нәтиҗәдә, 1939 елның гыйнварына кадәр 25 меңгә якын татар лагерьларга озатыла.

Бу гамәлләр барысы да татарларга, башкортларга һәм башка төрки халыкларга карата самодержавие сәясәтенең дәвамы икәнлеге көн кебек ачык. Шунысын да әйтергә кирәк: К.Мохтаров ХКС рәисе булган чор республика өчен бик авыр елларга туры килә. Гражданнар сугышыннан соңгы авырлыклар, 1921 елгы корылык, ачлык... К.Мохтаров, шушы кыенлыкларга бирешмичә, икътисад, мәдәният өлкәсендә яңадан-яңа уңышларга ирешеп, дәүләтчелекне үстерде, ныгытты. 1921-1923 елларда Татар илендә аның тырышлыгы белән бөтен милләтләр арасында чын дуслык, тигезлек урнашты. 90-95% башка милләт вәкилләре татар телен өйрәнергә ризалык белдергәннәр икән, бу — К.Мохтаров һәм аның хезмәттәшләре булган «уңнар»ның зур уңышы. Авырлыкларны җиңеп, проблемаларны яхшы якка хәл итә башлау Үзәкне, бигрәк тә «ил атасын» бик борчый һәм аларны куып тарату, эшсез калдыру өчен барысын да эшли. Шушы елларда СССРның киләчәктә җимерелүенә нигез салына. Уйлап кына карагыз: әгәр дә «ил атасы», Политбюро, оппозиция «Кәшшаф Мохтаров хакимиятенә» юл биреп, аны үстерсә, ныгытса, СССРның абруе, киләчәге бөтенләй башка юл алган булыр иде... Кызганыч, сталинизмның шовинистик сәясәте нәтиҗәсендә илебездә күпме «Мохтаров»лар һәлак булды.

К.Мохтаров һәм аның хезмәттәшләре тарафыннан тормышка ашырыла башлаган идеяләр 1990 елларда күпмедер яңартылды. Бу еллардагы үзгәрешләр беренче суверенитетның дәвамы буларак каралырга тиеш. Кызганычка каршы, тарихчылар һәм сәясәтчеләр ул еллардагы К.Мохтаров хакимиятенең тәҗрибәсеннән тиешенчә файдалана алмадылар. Бу инде аерым тарих...

Чыганаклар

1. Тайны национальной политики ЦК РКП. Стенографический отчёт IV совещания ЦК РКП. 1923. Москва, 1992. — С.53.
2. Шунда ук. — Б.58-61.
3. Шунда ук. — Б.137-138.
4. Шунда ук. — Б.139.
5. ТР ҮД ТС ДА. ф.15, оп.1д. 858. — Л.21.
6. Шунда ук. — Б.199-200.
7. Вәлиев Р.К. Өзелгән дога. — Казан, 2007. — Б.128-129. ■

ӘКЪДӘС НИГЪМӘТ КУРАТНЫҢ ТӘРҖЕМӘИ ХӘЛЕ ҺӘМ ФӘННИ-ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕГЕ

ФАЗЫЛ ШӘРӘФЕТДИНЕВ,
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты соискателе

Әкъдәс Нигъмәт Курат (Әкъдәс Таһир улы Нигъмәтов) 1903 елның 9 апрелендә (яңа стиль белән 22 апрель) Уфа губернасы Минзәлә өязенең Бәркәтә авылында (хәзерге Татарстан Республикасының Чирмешән районы) туган [1]. Атасы — указлы мулла Таһир Шаһиморад [2] углы ибне мулла Нигъмәтулла — чыгышы белән Тау ягы морзалары Акхуҗа нәселеннән [3]. Анасы Бибишакирә остазбикә — Гыйрфан мулла кызы. Бибишакирәнең анасы Нәфисәҗиһан — Түбән Чыршылының (хәзерге Лениногорски районы) имам һәм мөдәррисе Габделфәттах бине Габделкаюм бине Гыйсмәтулла бине Габдеррәхманның (1829-1891) бертуганы. Ахун Габдеррахман бине Туймөхәммәд (1691-1764) Тайсуган (хәзерге Әлмәт районы) мәдрәсәсенең мөдәррисе була. Габделфәттах бине Габделкаюмда булачак казый һәм мөфти Ризаэддин бине Фәхреддин (1859-1936) унтугыз ел чамасы укыган вакытта 5-6 ел хәлфәлек тә итә [4]. Һади Атласи никахында Габделфәттах кызы Хөснекәмал тора.

Әкъдәс, әтисе Таһир Шаһиморад укыткан мәктәп-мәдрәсәдә белем алганнан соң, укуын Бөгелмә рус гимназиясендә дәвам итә [5]. 1920 елда гимназияне уңышлы тәмамлаган Әкъдәс Нигъмәт, югары белем алу теләге белән, башта — Ленинград, аннан Мәскәү уку йортларына барса да, укуын дәвам итә алмый. Егет бу вакытка гарәп, фарсы, төрки һәм рус телләреннән тыш, Һади Атласи китапханәсендәге алман классиклары И.В.Гётенең, Ф.Шиллерның күптомлык әсәрләрен укып, алман телен өйрәнгән була. 1920-1921 елларда Ригада урнашкан АРА — «Америка хәйрия-ярдәм оешмасы»нда [6] эшли.

1922 елда Әкъдәс Нигъмәт, инженер белгечлеген үзләштерү теләге белән, Литва чиген үтеп, Алманиягә юл тота, ләкин паспорты булмау сәбәпле, Польшада бер ел тоткарлана. 1924 елда, Төркия визасын алып, Истанбулга килеп төшә [7]. 1924 елның көзендә Истанбул университеты филология факультетының фәлсәфә бүлегенә укырга кереп, соңрак тарих бүлегенә күчә.

Профессор Фуад Көпреле 1925 елда Әкъдәс Нигъмәтне Төркият институтына ассистент итеп ала. Бер үк вакытта Әкъдәс Нигъмәт профессор Ә.Зәки Вәлидинең семинарларын һәм Төркия хөкүмәте чакыруы буенча уни-

верситетка лекцияләр укырга килгән В.В.Бартольдка лекция-семинарларын әзерләшә.

1928 елда тарих бүлеген тәмамлаган Әкъдәс Нигъмәт, Европа конкурс имтиханнарын үтеп, 1929 елда, докторантурага әзерләнер өчен, Алманиягә китә. Ике ел Бреслау, ике ел Һамбург университетларында семинарлар үтеп, 1933 елда, Византия тарихы өлкәсенә караган темага диссертацияне уңышлы яклап, фәлсәфә фәннәре докторы дәрәҗәсе ала.

Истанбул университетына кайткан Әкъдәс Нигъмәткә әдәбият факультетының тарих бүлегендә урта гасырлар тарихы кафедрасы доценты дәрәҗәсе бирелә. Ул университетта лекция һәм семинарлар алып бару белән бергә, тарих бүлегенең китапханәсен тәртипкә китерә һәм архивта фәнни-тикшеренү эшләрен башлый.

Ә.Н.Курат 1937 елның февралендә Швециягә китеп, ел ярым Упсаала университетында укыта, Стокгольмдагы Риксаркиветта (Дәүләт архивы), Берлин, Вена, Париж, Лахей һәм Лондондагы архивларда һәм китапханәләрдә эзләнүләр алып бара.

Ул, 1938 елның июль аенда Истанбулга кайтып, Денизли лицеенда укытучы булып эшкә урнаша. 1939 елның сентябрь аенда Гази тәрбия институтына (Анкара) тарих укытучысы итеп билгеләнә. 1941 елның сентябреннән Тел һәм тарих, география факультетында доцент, 1944 елда — рус теле һәм әдәбияты буенча профессор, соңрак — урта гасырлар тарихы кафедрасында профессор вазифасына сайлана. 1953-1955 елларда Тел һәм тарих, география факультеты деканы вазифасын башкара.

Ассистенты К.Я.Копраман профессор Куратның студентлар белән сәгатьләр буе семинарлар үткәрүе, аңлатыла торган темаларга караган чыганак һәм авторларга аеруча әһәмият бирүе, аннан Европа, рус һәм башка телләрдәге әдәбиятны, студентның белү-

Әкъдәс Нигъмәт Курат

белмәвенә карамастан, һичшиксез, укуы турында яза. Ә.Н.Курат шул ук вакытта күпсанлы мәкалә һәм китаплар бастыра. Төрки телләрдән башка русча, немецча, инглизчә, французча, полякча, шведча, гарәпчә, фарсыча, иске юнанча (грекча) белә һәм хезмәтләрендә шул телләрне файдалана. Аны иң кызыксындырган өлкә — Көнчыгыш Европа халыклары тарихы була.

Ә.Н.Курат тарафыннан оештырылган һәм ул 1953-1955 елларда җитәкләгән «Тарих коллоквиумнары» Анкараның гыйльми даирәләрендә югары бәя ала һәм күп галимнәрнең игътибарын үзенә җәлеп итә.

Ә.Н.Курат 1946-1947 елларда Инглиз культура комиссиясенең стипендиясенә Оксфордта, Бодлеан һәм Лондонда Британия музеенда эшли. Бу тикшеренү эшләре нәтиҗәсендә, «Türk-İngiliz munasebetleri» («Төрек-инглиз мөнәсәбәтләре») исемле китабын яза. 1948 елда «Rusya Tarihi, Başlangıçtan 1917’ye kadar» («Русия тарихы, башлангычтан 1917 елга кадәр») исемле хезмәтен бастырып чыгара.

1950-1951 елларда Рокфеллер фонды стипендиясенә Америкада тикшеренү

эшләре алып бару, 1961-1962 елларда Нью-Йорк, Принстон, Беркли, Гувер институтларында, Гарвард, Вале китапханәләре, Вашингтон, Лондон һәм Париж архивларында эшләве нәтиҗәсе буларак, 1970 елда «Türkiye ve Rusya. 1798-1919» («Төркия һәм Россия. 1798-1919 еллар») исемле хезмәте басылып чыга. Ә.Н.Куратның бу гыйльми сәфәрләре яңа хезмәт әзерләү һәм, беренче форсатта, җыйган материалларны эшкәртеп, китап яки мәкалә итеп бастыру максатында ясала. Галим халыкара гыйльми конгрессларда катнаша, конференцияләр үткәрә. 1971 елның гыйнвар аенда Австралиядәге Ориенталистлар конгрессына чакырылган Ә.Н.Курат, хөкүмәт йөкләгән программа буенча, Тәһран, Кабул, Канберра, Чили, Аргентина, Бразилия, Мексикада да Төркия белән таныштыруны максат итеп куйган гыйльми конференцияләр үткәрә.

Ә.Н.Куратның басылып чыккан 23 хезмәте һәм 80гә якын фәнни мәкаләсе билгеле [8]. Хезмәтләре Көнчыгыш Европа халыклары, төрки кавемнәр һәм дәүләтләр, Төркия дәүләте, Казан ханлыгы, Идел буе Болгар дәүләте, Россия тарихы, инглиз, алман-төрек мөнәсәбәтләренә карый. Мәкаләләренең күпчелеге төрек телендә булып, бер өлеше инглиз, алман телләрендә язылган. Галимнең мирасы татар яисә рус телләренә тәрҗемә ителмәгән диярлек. «Чака бәй» (1936), «Топкапы сарае музей архивындагы Алтын Урда, Кырым вә Төркестан ханнарына караган ярлык вә битекләр» (1940), «Русия тарихы: башлангычтан 1917 елга кадәр» (1948), «Күктөрк каганлыгы (1952), «IV-XVIII йөзьелларда Кара диңгезнең төньягындагы төрки кавемнәр вә дәүләтләр» (1972) исемле хезмәтләре 1997 елда [9] һәм «Урта гасырлар тарихы өчен кыскача библиография» (1934) дип аталганы 2011 елда Татарстанга кайтарылды.

Ә.Н.Куратның «Ислам Энциклопедиясе» сериясендә басылып чыккан «Болгар» [10], «Бәҗәнәкләр» [11] исемле мәкаләләре, «Китаплар арасында» [12], «1917 ел февраль ихтилялы вә Русия төркиләре» [13], «Казан төркиләренең танылган тарихчы вә милләтчеләреннән Һади Атлас (1875-1940 (?))» [14] исемле мәкаләләре кергән «Казан» журналы саннары да 1992 елда Татарстанга кайтарылды [15].

Ә.Н.Курат 1970 елда Төрки мәдәниятне тикшерү институтының (Türk Kültürünü araştırma Enstitüsü) хакыйкый әгъзасы итеп сайлана.

Галимнең гаилә хәле турында берничә сүз. Әкъдәс Нигъмәт 1928 елда Фуад Көпрүлүнең укучысы, әдәбият факультетын тәмамлаган Һәдия Мәхмәдкә өйләнә. Улы доктор Юлыгтәкин Курат (1931-1994) Урта Көнчыгыш техник университетының тарих кафедрасында доцент булып эшли. Юлыгтәкин Курат, атасының вафатыннан соң, аның төп хезмәтләреннән берсе булган «IV-XVIII йөзьелларда Кара диңгез төньягындагы төрки кавемнәр вә дәүләтләр» исемле хезмәтен басмага әзерләп нәшер итә.

Әкъдәс Нигъмәт Курат 1971 елның 8 сентябрендә вафат була.

1970-1980 елларда Төркиядә чыгып килгән «Казан» («Kazan») журналында, чит илләрдә яшәүче татар галимнәре, язучылар һәм җәмәгать эшлеклеләреннән Р.Аги, Н.Бинарк, Н.Дәүләт, Х.З.Кушай, М.Таһир, Ә.Тимер, С.Чагатай [16] һ.б. белән беррәттән, Ә.Н.Курат мәкаләләре дә басыла. Игътибарыгызга Ә.Н.Куратның «Казан» журналында дөнья күргән «Kitaplar arasında» [17], («Китаплар арасында») дип аталган мәкаләсен тәкъдим итәбез. Ул 1969 елда Казан университеты типографиясендә басылып чыккан җыентыкта Альфред Халиков [18] һәм Миркасыйм Госмановларның [19] археология, тарих фәннәре өлкәсенә караган язмаларына бәяләмә сыйфатында язылган. ■

КИТАПЛАР АРАСЫНДА*

ӘКЪДӘС НИГЪМӘТ КУРАТ

СОВЕТЛАР БЕРЛЕГЕ, ТАТАР АВТОНОМИЯЛЕ ҖӨМҺҮРИЯТЕ МӘРКӘЗЕНДӘГЕ «ДӘҮЛӘТ УНИВЕРСИТЕТЫ» БАСМАЛАРЫ АРАСЫНДА, АЗ БУЛСА ДА, КАЗАН ИЛЕ ТАРИХЫНА КАРАГАН МӨҺИМ ӘСӘРЛӘР ЧЫККАНЛЫГЫ КҮРЕНӘДЕР. СТАЛИН ДӘВЕРЕНДӘ КАЗАН ТӨРКИЛӘРЕНЕҢ «МИЛЛИ ТАРИХЛАРЫ» КЕБЕК «ШИК»ЛЕ ТЕМАЛАР ҺИЧ ТЕЛГӘ АЛЫНМАДЫ.

Сталин үлеменнән соң хасил булган «йомшару» нәтиҗәсендә, Казанда, Казан төркиләренең теле, әдәбияты, археологиясе вә мәдәниятләренә караган, вакытына күрә зур кыйммәткә ия материаллар басыла башлады. Бу яктан Казанда чыккан «Казан утлары» атлы әдәби журналда мөһим язмалар чыгуына игътибар иттек. Бу юлы, исеме югарыда күрсәтелгән вә шактый авторларның имзасы булган бу әсәрдә Казан төркиләренең археологиясе һәм якын тарихлары белән билгеле берничә язма басылган. Боларның беренчесе — яшь казанлы археолог вә тарихчы А.Халиковның 1961-1967 елларда Татарстанда башкарылган, казанлы археологларның эшчәнлегенә караган язмасыдыр. Халиков бу язмасында 1961 елдан бирле казанлы төрки археологларның (Халиков, Р.Г.Фәхретдинов, Казаков һ.б.) Урта Идел буенда палеологик дәвердән бирле төрле «культура дәверләре»нә караган меңнән артык археологик табылдыкларга юлыгуларын вә боларның әһәмиятен тасвирлый. Үзәктә — иң мөһим дәвер — Идел болгарлары эзләре (Болгар, Биләр, Сувар шәһәрләре), Кама, Идел, Чирмешән, Шушма, Зәй елгалары буендагы Болгар калдыклары вә алда әйтелгән бай материал; Алтын Урда вә Казан ханлыгы дәверенә караган кыйммәтле табылдыклар. Боларның бөтенесе ярдәмендә бүгенге Татарстанда гаять гүзәл археологик бер харита тәртипкә китерелмештер.

Бу очеркларның икенчесе — М.Г.Усманов (Госман) тарафыннан язылган, Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстафадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар» атлы әсәренең кайсы чыганакларга таянуына караган бер мәкаләдер (44-55 б.). Шиһабетдин Мәрҗанинең әлеге китабы — Казан илендә язылган беренче гыйльми тарих әсәредер. Казан төркиләре үзләренең милли тарихлары хакында беренче мәртәбә шул әсәр аша танышалар вә Мәрҗани, Казан төркиләренең «милли аңлары»ның формалашуында гаять бөек роль уйнамыштыр. 1885 елда Казанда беренче томы чыккан «Мөстафадел-әхбар...» ул дәвердәге

*Идел буе һәм Урал тирәсендәге җирләргә караган язмалар (Очерки истории Поволжья и Приуралья). — Казан: Казан университеты басмасы, 1969. — 292 б.

гыйльми мохиттә бөек уянышка илтә вә уңыш казана.

«Мөстафадел-әхбар…»ны язучы Шиһабетдин Мәрҗани үзе тикшерүләр алып барган Сәмәрканд китапханәләрендә күп кыйммәтле гарәпчә вә фарсыча чыганак материаллар күрә вә боларны бөтен бер җитдилек белән туплый, чагыштырулар ясап, язып ала. Болгар вә Казан иленә караган иң мөһим чыганаклардан бередә 922 елда Идел буена килгән ибн Фадланның мәшһүр «Рисалә»седер. «Рисалә» Йакутның «Мөгъҗәмел-бөлдан»ы аша билгеле булып, Мәрҗани әлеге әсәрне оригиналында өйрәнә вә күп кыйммәтле белем ала. Моннан башка кайбер оригинал чыганакларны да күрә. Шул күзлектән Мәрҗанинең бу әсәре — хакыйкатьтә бөек бер гыйльми кыйммәткә ия чыганак вә заманыбызга кадәр әһәмиятен югалтмаган. Мәрҗани каләменнән чыккан кайбер әсәрләрнең һәм басылып чыккан олы бер җыентыкның дөнья күрүен белдергән Усманов, бу рәвешле, бөек казанлы тарихчы, акыл иясе вә һәрьяктан бөек бер шәхес булган Шиһабетдин Мәрҗанине танытуда хакыйкый олы бер хезмәт башкарган. Мәрҗанинең тарихи вә башка әсәрләре Казанда янәдән басылуына өмет итәбез.

Әдәбият һәм чыганаклар

1. Әкъдәс Нигъмәтнең тууы хакында метрика дәфтәрендәге язманың копиясе // Шәрәфетдинов Ф. Һиҗрәттәге бөек милләттәшебез // Гасырлар авазы – Эхо веков . – 2002. – №3/4. – Б.169.
2. Kurat A.N. Kazan Türklerinin tanınmış Tarihçi ve Milliyetçilerinden Hadi Atlas (1875 -1940?) // Kazan. – 1975. – Sayı 16. – S.1-6; Казан төрекләренең танылган тарихчы һәм милләтчеләреннән Һади Атлас (1875-1940?) // Аргамак. – 1994. – №11. – Б.91-97.
3. «Нигъмәтулла бине Хәбибулла бине Габделмән бине Акхуҗа» // Ризаэддин Фәхреддин. Асар. – 1 том. – Казан: Рухият, 2006. – 166 б.
4. Ahmet Temir'in kendi Kaleminden Hayeti ve Eserleri. – Ankara Universitisi Basımevi, 1993. – 21, 32 s.; Ахмет Тимер: Возвращение / авт.-сост. Р.Абзалова-Сальманова. – Казань: Яз, 2012. – 44 с.; Габдрахман Туймөхәммәт улы Бикчурин шәҗәрәсе // Гарифуллин Д.Х. Мәшһүр исеме Тайсуган. – Әлмәт: «Тат АСУ нефть», 2001. – 158 б.; Фәхреддин Ризаэддин. Асар. – III һәм IV томнар. – Казан: Рухият, 2010. – 213 б.
5. Profesör Dr. Akdes Nimet Kurat (22.04.1903 – 8.09.1971) // Kazan. – 1971. – Sayı 5. – S.27.
6. АРА / Рахимов С.Т. «Голод особенно свирепствовал в деревнях...» // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 1997. – №3/4. – С.114; АРА (инглиз.: «ARA», «Amerikan Relief Administration» – «Америка хәйрия-ярдәм мөдирияте»), иҗтимагый хәйрия оешмасы // Татар энциклопедиясе: 6 томда / Баш мөхәррир М.Х.Хәсәнов, җаваплы мәхәррир Г.С.Сабирҗанов. – Казан: «ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты» дәүләт учреждениесе, 2008. – 1т.: А-В. – 720 б.
7. Корraman K.Y. Hocam Profesör Doktor Akdes Nimet Kurat // Türk Dünyası Aydınları Sempozyumu Bildirileri (23-26 Mayıs, 1996). – Kayseri, 1996. – 425 s.
8. Ahmed Vurgun, Muhammet Avarogulları. Akdes Nimet Kurat, Tarihçilik ve Tarih Ögretimi. Кара: эл.версияне: www. turkegitimindeksi.com/Articles.aspx ? I D = 1447) (дата обращения: 21.06.2013).
9. Зәки М.З. Күңел төп йортка тартыла // Әхмәтвәли Мәңгәр. Хатирәләр . – Казан: «Гасырлар авазы – Эхо веков» нәшр., 1997. – 99 б.; Надиров И.Н., Рәхимов С.Т. Мәшһүр төрек-татар тарихчысы // Казан утлары. – 2003. – №4. – Б.149.
10. Kurat A.N. Bulgar // İslam Ansiklopedisi. 2 cilt. – İst.: Maarif Matbaası, 1942.
11. Kurat A.N. Peçenekler // Islam Ansiklopedisi. 9 cilt. – Ist.: Milli Egitim Basımevi, 1964.
12. Kurat A.N. Kitaplar arasında // Kazan. – 1971-1972. – Sayı 6.
13. Kurat A.N. 1917 Şubat ihtilalı ve Rusya Türkleri // Kazan. – 1975. – Sayı 14 (I baskı: Türk Yurdu, 1960).
14. Kurat A.N. Kazan Türklerinin tanınmış... // Kazan. – 1975. – Sayı 16.
15. Миңнегулов Х.Й. Дөньяда сүземез бар... – Казан: Татар.кит.нәшр., 1999. – 231 б. ; Хатип Миннегулов . Обретёт душа, стремясь к тебе, свободу… // Казань. – 1993. – №1. – С.161.
16. Kazan. 1970-1975 yılları için fihrist (1- 16 sayılar) // Kazan. 1976. – Sayı 17. – S.56-64; Казан (Kazan) // Татарская энциклопедия: В 5т. / Гл.ред. М.Х.Хасанов, ответ. ред. Г.С.Сабирзянов. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2006. – Т.3: К-Л.
17. Kurat A.N. Kitaplar arasında // Kazan. – 1971-1972. – Sayı 6. – S.59-60.
18. Халиков А.Х. Исследования казанских археологов на территории Татарии в 1961-1967 гг. // Очерки истории Поволжья и Приуралья. Сборник статей. – Казань: Изд-во Казан. Ун-та, 1969. – С.3-14.
19. Усманов М.А. «Мустафад ал-ахбар фи ахвали Казан ва Булгар». Ч.1. – Казань, 1885 // Очерки истории Поволжья и Приуралья. Сборник статей... – С.144-154.

Төрекчәдән ***Фазыл Шәрәфетдинев***
тәрҗемәсе

БЕЗ – «БЕР АНА-ЙОРТНЫҢ БАЛАЛАРЫ»

(Татарстанда Әкъдәс Нигъмәт Куратның тормыш юлын һәм фәнни мирасын өйрәнүнең торышы)

ХАТЫЙП МИҢНЕГУЛОВ,
филология фәннәре докторы,
Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры

Татар мөһаҗирлек хәрәкәтенең иң көчәйгән чоры XIX гасырның ахырына — XX йөзнең беренче яртысына туры килә. Бер-бер артлы булып торган инкыйлаблар, Гражданнар һәм ике бөтендөнья сугышы, Россиядәге икътисади, социаль, иҗтимагый тетрәнешләр, үзгәрешләр, милли-азатлык көрәше, Сталин репрессияләре… — боларның һәммәсе татарны бөтереп ала, туздыра, миллионлаган милләттәшләребезне туган җирләреннән аера, чит-ят җирләргә күчеп, качып китәргә мәҗбүр итә.

Татар мөһаҗирләре Япониядән Америкагача, Скандинавиядән Австралиягәчә сибелсә дә, Ватаныннан читтә калган милләттәшләребезнең төп җыелу урыны элек-электән Госманлы дәүләте — Төркия булган. Моның, әлбәттә, тарихи, объектив сәбәпләре дә бар. Чөнки төрекләр һәм татарлар — кардәш, тугандаш халык [1]. Төркия безнең халык вәкилләрен, аның авыр хәлдә калган улларын һәм кызларын күп гасырлар буе ачык йөз белән каршы алды, үзенә сыендырды, яшәргә, эшләргә мөмкинлек бирде. Моның өчен без төрек кардәшләребезгә бик рәхмәтле.

Татарның шактый гына галим-әдипләре, күренекле затлары теге яки бу дәрәҗәдә Төркия белән бәйләнешле. Әкъдәс Нигъмәт Курат (Akdes Nimet Kurat) [9 (22).04.1903-08.09.1971] — гомеренең өчтән ике өлешен тарихи Ватаныннан читтә яшәгән күренекле татар галимнәренең берсе. Ул — дөньякүләм билгеле тарихчы. Әйтүләренә караганда, ул дистәләгән телдә укыган, аралашкан, лекция-докладлар сөйләгән. Ул — «Төрек энциклопедиясе»нең төп җитәкчеләреннән һәм авторларыннан берсе дә. Бу затлы галим төрле урыннарда яшәп алган. Әмма кайда гына торса да, мөхтәрәм инсан беренче асыл Ватаны итеп Идел-йортны, аннан кала Төркияне санаган. Беренчесендә туып үсүе, икенчесендә биниһая олуг хезмәтләр кылып, мәңгелеккә торып калуы да тирән мәгънәгә ия.

XX йөздә мөһаҗирлек язмышына дучар булган башка күп кенә милләттәшләребез кебек, Әкъдәс Нигъмәт тә безгә — Советлар Берлегендә яшәүчеләргә — юньләп билгеле бул-

мады. Акылга сыймаслык хәл: чит ил тарихчылары гына түгел, рус, совет галимнәре дә аның хезмәтләренә таяналар, фикер-күзәтүләрен сөземтә-цитата рәвешендә китерәләр; ә инде Әкъдәс Нигъмәтнең шәхесе, татарлыгы хакында мәгълүматлар юк дәрәҗәсендә. Бигрәк тә татар матбугатында.

Бары тик илдә үзгәртеп корулар дәверендә, ягъни узган гасырның ахырларында гына Әкъдәс Нигъмәт турында язмалар Татарстанда күренә башлады. Болар арасында аеруча археолог, тарихчы Альфред Халиковның «Галим... якташлар» («Социалистик Татарстан» газетасы. 15.01.1989) һәм академик Әбрар Кәримуллинның «Тарихтагы ак таплар» («Татарстан яшьләре» газетасы. 30.05 — 1.06.1991) исемле мәкаләләре игътибарга лаек. Һәр ике күренекле галим дә Әкъдәс Нигъмәт Куратның тормышы, эшчәнлеге хакында аерым мәгълүматлар бирә, милләттәшебезнең хезмәтләрен югары бәяли. Шунысы мөһим: А.Халиковка гыйльми командировка вакытында Төркиядәге милләттәшебез белән очрашып сөйләшергә дә туры килә. «Миндә, — ди ул, — бу зат, галим һәм кеше буларак, уңай тәэсир калдырды». 2002 елда «Гасырлар авазы...» журналы битләрендә (№3/4), Әкъдәс Нигъмәтнең тууына 100 ел тулу уңае белән, Алабугада яшәүче, үз авылдашын өйрәнү юнәлешендә игелекле гамәлләр кылучы Фазыл Шәрәфетдиновның «Һиҗрәттәге бөек милләттәшебез» исемле бай эчтәлекле язмасы дөнья күрде [3]. Анда Әкъдәс Нигъмәтнең тормыш юлы, эшчәнлеге кыскача бәян ителә, галимнең 1966 елда туганнарына язган бер хаты да китерелә; фотосурәтләр һәм булачак тарихчының тууы хакындагы метрикә кәгазенең күчермәсе һәм ике китабының титул копияләре дә бирелгән.

2003 елда, Әкъдәс Нигъмәтнең тууына 100 ел тулу уңае белән, Татарстанда, төгәлрәк әйткәндә, Чирмешән төбәгендә, Казанда төрле чаралар үткәрелде, аларда галим-әдипләр, җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты. Бигрәк тә Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты инициативасы белән уздырылган «түгәрәк өстәл» янында сөйләшүдә мөһим фикерләр яңгырады. Мирфатыйх Зәкиев, Миркасыйм Госманов, Илбарис Надиров, Ринат Закиров, Фазыл Шәрәфетдинев, Асия Рәхимова, шулай ук төрек зыялылары Исмәгыйль Төрекуглы, Фатыйх Кутлу... Әкъдәс Нигъмәт Курат эшчәнлегенең күпкырлы булуын, әһәмиятен, хезмәтләрен «җентекле» өйрәнергә, Татарстанда бастырырга кирәклегенә басым ясадылар. Юбилей чаралары көндәлек матбугатта да чагылыш тапты [Миләүшә Исмәгыйлова. Чирмешән горурлыгы // Ватаным Татарстан. — 11.04.2003; Асия Юнысова. Сөт калыр — ватан китәр... // Ватаным Татарстан. 11.11.2003. һ.б.].

Татарстаннан читтәге милләттәшләребезне өйрәнүдә Тәүфыйк Әйди традицияләрен уңышлы дәвам итүче, күп кенә шәхесләр хакында кызыклы очерклар авторы Хәмзә Бәдретдинов үзенең «Тану хакында таныту» исемле язмасында Әкъдәс Нигъмәт Курат турында шактый гына мәгълүматлар китерә, мөһим фикерләр әйтә. Бу очеркында ул Альфред Халиков, Әбрар Кәримуллин мәкаләләренең төп эчтәлеген бәян итә, «түгәрәк өстәл» барышында әйтелгән чыгышлардан аерым өзекләр дә китерә. Язмада галимнең фотосурәте дә урнаштырылган [4].

Мәшһүр милләттәшебезнең тууына 100 ел тулу уңае белән, аның хакында бик җылы, бик мәгънәле сүзләр әйтелде. Туган төбәгендә музеен булдыру, исемен мәңгеләштерү мәсьәләләре дә күтәрелде. Инде менә ул көннәрдән соң 10 ел вакыт узып китте. Быел Әкъдәс Нигъмәтнең тууына 110 ел. Әмма, кызганыч ки, соңгы дистә елда галимне өйрәнү юнәлешендә Татар-

станда алга китеш булмады диярлек. Дөрес, фәнни тикшеренүләрдә аның хезмәтләренә мөрәҗәгать итүләр бераз гына артты. Ильяс Мөстәкыймов, Римма Баязитова белән берлектә, Әкъдәс Нигъмәтнең Олуг Мөхәммәд хакындагы безнең өчен бик тә кыйммәтле булган язмасын рус теленә тәрҗемә итеп, тиешле шәрех-аңлатмалар, кереш мәкалә белән «Гасырлар авазы…» журналында (2005 ел) бастырып чыгарды [5]. Бу елның апрель аенда Ә.Куратның тууына 110 ел тулу уңаеннан, Анкара шәһәрендә Төрек тарихы җәмгыяте һәм ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты халыкара конференция уздырды. Анда сөйләнгән докладлар Ә.Курат шәхесен, аның хезмәтләрен бәяләүдә мөһим вакыйга булды [6]. Аерым китап-хезмәтләрдә галим турында теге яки бу күләмдә мәгълүматлар бирелде. Мәсәлән, андый белешмәләр Роза Афзалова-Сәлманованың Әхмәт Тимер турындагы җыентыгында бар [6]. Әмма болар гына гомуми картина тудыра алмый. Әкъдәс Нигъмәт турында махсус хезмәтләр язу, диссертацияләр яклау, китапларын татар, рус телләрендә бастырып чыгару һаман да көн тәртибендә кала килә.

Миңа XX гасыр ахырларында — XXI йөз башларында, Анкарага баргач, Әхмәт ага Тимер белән берничә мәртәбә очрашырга туры килде. 1997 елда булса кирәк, сөйләшүләрнең берсендә Әхмәт ага: «Без инде гомеребез буе үз Ватаныбызны сагынып яшәдек. Менә Әкъдәс Курат, җиһанның күп илләрендә булса да, туган ягын кабат күрә алмыйча, дөньядан китеп барды. Ә бит аның Чирмешән, Әлмәт якларын бик тә күрәсе килә иде», — диде.

Шунысын да искәртик: мөһаҗәрәттәге милләттәшләребез бер-берсе белән аралашып яшәгән. Нәсел тамырлары белән үзара бәйләнгән Әкъдәс Нигъмәт һәм Әхмәт Тимер дә очрашып, сөхбәтләшеп торганнар. Әхмәт ага үзенең истәлекләрендә, үзара әңгәмәләрдә якташын һәрчак хөрмәт, җылылык белән телгә ала. Шунысы кызыклы: боларның һәр икесе дә асыл Ватаннарында ук, татар, рус, гарәп, фарсы, төрек телләреннән тыш, алман телен дә ныклап үзләштерәләр. Монда, әлбәттә, үзе дә немец телен белгән Һади Атласиның (1876-1938) роле зур була. (Мәгълүм ки, аның хатыны Хөсникамал — Әхмәт Тимернең әнисе — Зәйнәб абыстайның бертуган апасы. Болар — Габделфәттах хәзрәтнең кызлары.) Ул үз өендә, мәктәптә балаларга алман телен дә өйрәтә, хәтта бу эшкә Идел буе немецларын да тарта. Гомумән, Һади Атласи үзенең шәхесе, энциклопедик белеме белән Әлмәт, Бөгелмә төбәге яшьләренә көчле йогынты ясый. Әкъдәснең тарихчы булып китүендә дә бу затның тәэсире бар. Төркиядә нәшер ителгән «Kazan» журналының 1975 елгы 16 нчы санында Әкъдәс Куратның бер мәкаләсе урнаштырылган [8]. Биредә ул Һади Атласиның тормышын, эшчәнлеген шактый тулы, белеп яктыртыла. Мәкалә авторының бу затка ихтирам-хөрмәте сизелеп тора, аны танылган тарихчы, «миллиятле» дип атый. Әкъдәс Нигъмәт Курат төрки-татар тарихына кагылышлы башка язмаларында да Һ.Атласи хезмәтләреннән файдалана, аларга сылтамалар ясый.

Әкъдәс Нигъмәт Курат күпкырлы гыйлем иясе, аның тел белеме, җәгърафия, сәясәт, фәлсәфә һәм кайбер башка тармаклар буенча язмалары бар. Әмма ул барыннан да элек төрле телләрдә басылган тарихи хезмәтләре белән мәгълүм. Алар ышанычлы чыганакларга, бай факт-мәгълүматларга корылган. Әкъдәс Нигъмәт күп телләрдәге фәнни язмалардан иркен файдалана, төрледән-төрле архив материалларын, кулъязмаларны фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә. Дәлиллелек, хакыйкатькә тугрылык, үтемлелек, гыйльми логика аның хезмәтләрен ярып бара.

Әкъдәс Нигъмәт тарихның да төрле

чорлары, төрле проблемалары белән эш итә. Аны Төркия һәм Россиянең үткәне һәм хәзергесе дә, төрки кавемнәрнең һәм дәүләтләрнең тарихы да, Шәрык һәм Гареб мөнәсәбәтләре дә, Евразиядәге күренекле затларның эшчәнлеге дә, иҗтимагый-мәдәни мәсьәләләр дә кызыксындыра. Мәсәлән, «Gaka bey» исемле монографиясендә «Измир бейлеге» белән 1081-1096 елларда идарә иткән хөкемдарның тормыш юлы, эшчәнлеге, Византия белән сугышлары бәян ителә [9]. «Göktürk Kağanlığı...» хезмәте 552-745 елларда яшәгән төрки кавемнәрнең тарихын яктыртуга багышланган. Төрле телләрдәге гаҗәеп бай библиография белән тәэмин ителгән бу язмада türk этнонимына да җентекле аңлатма бирелә.

Әкъдәс Нигъмәт озак еллар төрле югары уку йортларында тарих укыта. Аңа Россия тарихы, хәтта рус теле һәм әдәбияты буенча да дәресләр алып барырга туры килә. Педагогик ихтыяҗны күздә тотып, Әкъдәс Нигъмәт Курат «Rusya tarihı» исемле күләмле (538 битлек!) дәреслек тә язып, 1948 елда бастыра [10]. Ул Россия тарихының «башлангычыннан алып 1917 елга кадәрге» чорын яктырта. Бу дәреслек өч китаптан тора: 862-1462 еллар, ягъни «корылыш»ыннан Мәскәү кенәзлегенә кадәрге чор»; 1462-1689 еллар, ягъни Пётр Iгә кадәрге дәвер; «Рус императорлыгы» чоры (1689-1917 еллар). Дәреслек факт-мәгълүматларга байлыгы, фикри тыгызлыгы белән аерылып тора. Россия тарихының мөһим вакыйга-хәлләре, күренешләре, күренекле шәхесләренең эшчәнлекләре анда шактый тулы чагылыш тапкан. Һәр чорның фәне, мәгарифе, мәдәнияте һәм әдәбияты хакында да белешмәләр бирелә. Шунысы мөһим: автор Россия тарихы кысаларында төрки-татар, Болгар, Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Кырым ханлыкларының тарихын, урыс хакимияте белән мөнәсәбәтләрен дә яктырта. Дәреслекнең ахырында «Рус кенәзләре һәм патшалары»ның хронологиясе, Россия тарихының мөһим вакыйга-күренешләрен чагылдырган текстлар, шулай ук «шәхесләр» һәм «йир адлары» (географик һәм тарихи атамалар) исемлеге дә бирелгән. Болар дәреслек белән эш итүдә шактый җиңеллек тудыра. Авторның әлеге хезмәте кабат-кабат та басыла. (Бу дәреслекне эчтәлек, төзелеш ягыннан, төрки-татар тарихының яктыртылыш ноктасыннан тикшерү, бәяләү проблемасы көн тәртибендә тора.)

Әгәр дә Әкъдәс Нигъмәтнең «Россия тарихы», «Күктөрк каганлыгы» һәм кайбер башка хезмәтләрендә татар тематикасы «узып барышлый», бүтән мәсьәләләргә буйсынулы, ярдәмчел рәвештә генә каралса, аның аерым монографияләрендә милләтебез язмышы, аның дәүләтчелеге, халыкара багланышлары махсус яктыртыла. Бу яктан безнең өчен галимнең «Төпкапы сарае музее архивындагы Алтын Урда, Кырым вә Төркестан ханлыкларына мөнәсәбәтле ярлык вә бетекләр» китабы (Истанбул, 1940) аеруча кыйммәтле [11]. Автор бу хезмәтен «...этисе — Бәркәтәле Таһир Нигъмәт хатирәсенә багышлый».

Тарих фәне өчен беренчел чыганаклар, факт-мәгълүматлар сулаган һава, эчкән су кебек кирәк. Кызганыч ки, төрле сәбәпләр аркасында татар тарихына кагылышлы материаллар чагыштырмача аз сакланган. Булганнары арасында хан ярлыклары, бетекләр бәяләп бетергесез әһәмияткә ия. Шуңа күрә дә аларны барлауга, текстологик һәм фәнни яктан өйрәнүгә галимнәр элек-электән игътибар иткән. Әкъдәс Нигъмәт әнә шул күркәм традицияне уңышлы дәвам иттерә: Алтын Урда, төрки-татар мәмләкәтләренә мөнәсәбәтле бу төр чыганакларны бергә туплап, комплекслы һәм җентекле тикшереп, фәнни җәмәгатьчелеккә тәкъдим итә.

Китапта Туктамыш хан, Тимер

Котлуг, Олуг Мөхәммәд, Миңлегәрәй, Хаҗигәрәй һәм кайбер башка татар ханнарына, күренекле затларына мөнәсәбәтле ярлыклар һәм бетекләр карала. Бу кыйммәтле документларның фотокүчермәләре, транскрипциясе, хәзерге телгә тәрҗемәләре бирелә. Һәр ярлык һәм бетек текстологик, тарихи яктан анализлана. Шәрех-аңлатмалар үз чиратында күп төрле чыганакларга, фәнни әдәбиятка нигезләнеп башкарыла. Аеруча мөһиме шунда: Әкъдәс Нигъмәт ярлык-бетек ияләре, текстта телгә алынган шәхесләр, тарихи күренешләр хакында эчтәлекле язмаларны да бирә. Бу (Бу текст, тиешле шәрех-аңлатмалары белән русчага тәрҗемә ителеп, «Гасырлар авазы» журналында басылып та чыкты (11; 205-216)). Автор, Аксак Тимер, Туктамыш, Идегәй тарихларына мөнәсәбәттә, XV йөзнең башларындагы Алтын Урданың хәлен, Сарай тәхетенә Олуг Мөхәммәднең ничек килүен һәм аннан ничек китүен, рус кенәзе Василийны җиңүен, Казан ханлыгына нигез салуын шактый җентекле яктырта. Мәгълүм ки, узган гасырның 40 нчы елларында ул вакытта Төркиядә яшәгән Гаяз Исхакый үзенең атаклы «Олуг Мөхәммәд» исемле драмасын иҗат итә. Бу ике күренекле милләттәшебезнең бер үк елларда бер үк тарихи тематиканы әдәби һәм гыйльми яктан эшкәртүләре авторларның фикри якынлыгын, күкрәкләрендә милли дулкынга көйләнгән татар йөрәге тибүен дә күрсәтеп тора. Китапта кайбер башка хөкемдарлар хакында да белешмә-мәгълүматлар бирелгән. «Россия тарихы» дәреслеге кебек, Әкъдәс Нигъмәтнең бу хезмәте дә фәнни аппарат (бай библиография, исем-атамалар исемлеге...) белән тәэмин ителгән. Хәтта мөһим даталарның һиҗри-миладидә, төрки хайван циклында (куян, дуңгыз... еллары) төгәл вакытларын күрсәткән таблица да бар.

Бу китап белән инде минем узган гасырның 80-90 нчы елларында ук Ленинградта, Хельсинкидә гыйльми командировкаларда вакытта танышканым бар иде. Шактый еллар узгач, янә аны актарып утырам. Китап һаман да кызыклы, игътибарны җәлеп итәрлек. Бигрәк тә XIV-XV гасырларга мөнәсәбәтле Туктамыш хан, Тимер Котлуг, Олуг Мөхәммәд хан ярлыкларының тел-стиле. Сарай ханы Госманлы солтаны «Икенче ...Морадка» болай дип мөрәҗәгать итә: «Сәлам борынгы хан агаларымыз (берлә) сезнең Рум вилаятенең солтан аталарыгыз, агаларыгыз берлә илче... сәлам алышып» [12]. Бу бит бүгенге киң катлам татар укучысына да аңлаешлы татар теле. Шушы ук традиция Казан ханнары Ибраһим, Мөхәммәд Әмин, Сәхибгәрәй ханнарның ярлык-бетекләрендә дә дәвам итә.

Әкъдәс Нигъмәтнең әлеге китабы галим-голямалар тарафыннан да бик теләп файдаланыла. Олуг галимебез Миркасыйм Госманов та үзенең «Жалованные акты Джучиева улуса XIV-XVI вв.» исемле монографиясендә (Казан, 1979) милләттәше чыгарган Истанбул басмасына еш мөрәҗәгать итә.

Әкъдәс Нигъмәтнең «Төркия һәм Идел буе» (1966), «IV-XVIII гасырларда Кара диңгезнең төньягындагы төрки кавемнәр һәм дәүләтләр», «1917 елгы Февраль ихтилялы вә Русия төрекләре» [«Kazan» мәҗмугасы. — 1975. — №44. Бу мәкалә «Төрек йорты» журналының 1960 елгы беренче саныннан (13-16 б.) алып урнаштырылган.] [13] һәм кайбер башка язмаларында да татар тематикасы төп урынны били. Хәзергә галим мирасын бөтен тулылыгында туган Ватанына, Татарстанга кайтару, бәлкем, бик мөмкин дә түгелдер. Әмма аның Идел-йортка, татарга кагылышлы хезмәтләрен өйрәнү, татар, рус телләрендә бүгенге укучыларга җиткерү — күптән өлгергән, хәл ителергә тиешле мәсьәлә.

Гомер буе эш-гамәлне, хәрәкәтне,

сәфәрләрне сөйгән Әкъдәс Нигъмәт үзе рульдә утырып, машинада йөрергә яраткан. 1966 елгы бер хатында ул улы, хатыны белән үзенең дөньядагы иң яхшы «Mersedes 220S» маркалы машинасы белән Әдернә — София — Белград — Вена — Мюнхен — Брюссель аркылы Ла-Манш бугазына кадәр килүен, аннан, Лондонда булгач, кабат Төркиягә кайтырга җыенуын яза [14]. Кызганыч ки, 1971 елның 28 июнендә Измит шәһәрендә автомобиль катастрофасына юлыга. Шунда алган каты җәрәхәтләрдән ул шул ук елның 8 сентябрендә гомерлеккә күзләрен йома.

***

Язмыш җилләре, тарихның афәтле вакыйгалары халкыбызның шактый гына асыл улларын һәм кызларын, туган Ватаннарыннан аерып, камгак кеби, чит-ят җирләргә, илләргә илтеп ташлаган, мөһаҗирлек шулпасын эчәргә мәҗбүр иткән. Әмма аларның күпчелеге югалып калмаган: укыган, тырышкан, иҗади, гыйльми югарылыкларга ирешкән. Алар үзләре яшәгән ил тормышының алгарышына да, дөнья тәрәккыятенә дә сизелерлек өлеш керткән. Шуның белән бергә мөһаҗир татарлар гомер буе җирсеп, Ватаннарын сагынып яшәгән: булдыра алган кадәр үз халкына да хезмәт итәргә, ярдәм кылырга тырышкан. Әкъдәс Нигъмәт Курат — шуның күркәм бер мисалы.

Чит илләрдә яшәгән, эшләгән милләттәшләребезнең мирасын өйрәнү, рухи тормышыбызга кертү безнең күзаллауларны баета, үткәнне һәм бүгенгене тирәнрәк аңларга, киләчәкне ачыграк күрергә ярдәм итә. Мөһаҗирлектәге татарлар, гәрчә җисмани яктан асыл Ватаннарыннан аерылсалар да, рухани җәһәттән без барыбыз да, Гаяз Исхакый әйткәнчә, «бер Ана-йортның — Идел-йортның балалары».

Әдәбият

1. Бу хакта карагыз: «О татарско-турецких взаимосвязях» / Хатип Миннегулов. Записи разных лет (Татарская литература: история, поэтика и взаимосвязи). — Казань: Идел-Пресс, 2010. — С. 174-187.
2. Чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты. Программа / Төзүчесе — профессор Х.Й.Миңнегулов. — Казан: КДУ нәшр., 2009. — 16 б.
3. Шәрәфетдинев Фазыл. Һиҗрәттәге бөек милләттәшебез // Гасырлар авазы / Эхо веков. — 2002. — №3/4. — Б.167-171.
4. Бәдретдинов Хәмзә. Татарстаннан читтәге татар галимнәре (Икенче кисәк). — К.: Идел-Пресс, 2006. — Б.178-185.
5. Мустакимов Ильяс, Баязитова Римма. К политической истории Улуг-Мухаммад-хана // Гасырлар авазы / Эхо веков. — 2005. — №2. — С.205-216.
6. Шәрәфетдинев Ф.Х. Ә.Н.Курат хезмәтләрендә Алтын Урда тарихы (История Золотой Орды в трудах А.Н.Курата) // Золотоордынское наследие. Выпуск 2. Материалы второй Международной конференции «Политическая и социально-экономическая история Золотой Орды», посвященная памяти М.А.Усманова. — Казань, 29-30 марта 2011 г. / Отв.ред.И.М.Миргалеев. — Казань: Институт истории, 2011. — С.229-232.
7. Ахмет Тимер: Возвращение / Автор-составитель Роза Абзалова-Сальманова. — Казань: Изд-во «Яз», 2012. — 200 с.
8. Prof.Dr.Akdes Nimet Kurat. Kazan türklerinin tanınmış tarihçi ve milliyetçilerinden Hadi Atlas // Kazan. – 1975. – №16. – S.1-6.
9. Çaka bey… / Akdes Nimet Kurat (Üçünçü baskı. – Ankara, 1966. – 64 s.
10. Göktürk kağanlığı... / Prof. Dr Akdes Nimet Kurat // Ankara Üniversitesi Dil ve Tarih – Cografya Fakültesi Dergisi. Cilt X, Sayı 1-2, 1952. – 56 s.
11. Rusya tarihı. Başlangıçtan 1917 ye kadar / Dr.Akdes Nimet Kurat... – Ankara, 1948. – 538 s.
12. Akdes Nimet Kurat. Topkapı Sarayı Müzesi Arşivindeki Altun Ordu, Kırım ve Türkistan Hanlarina ait Yarlık ve bitikler. – Istanbul, 1940. – 212 s.
13. Миңнегулов Хатыйп. Дөньяда сүземез бар. — К.: Татар.кит.нәшр., 1999. — Б.222. Бу китаптагы «Фәнгә яңа сәхифәләр», «Чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты», «Казан» һәм «татар» — аерылмас төшенчәләр», «Истанбулны мин дә күрдем», «Татарга теләктәш төрек галимәсе (Фатма Өзкан турында)» (184-263 б.) мәкаләләре бу язмада куелган мәсьәләләр белән шактый бәйле.
14. Шәрәфетдинев Фазыл. Һиҗрәттәге бөек милләттәшебез // Гасырлар авазы / Эхо веков. — 2002. — №3/4. — Б.169. ■

ӘКЪДӘС НИГЪМӘТ КУРАТ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ АЛТЫН УРДА ТАРИХЫ

ИЛНУР МИРГАЛИЕВ,
тарих фәннәре кандидаты, Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институтының М.Госманов исемендәге Алтын Урданы өйрәнү үзәге җитәкчесе

ӘКЪДӘС НИГЪМӘТ КУРАТ – ТАРИХЧЫЛАР АРАСЫНДА БИЛГЕЛЕ ШӘХЕС. АНЫҢ ХЕЗМӘТЛӘРЕ, НИГЕЗДӘ, ТАТАР ХАЛКЫ ТАРИХЫНА БАГЫШЛАНГАН. ТАНЫЛГАН МИЛЛӘТТӘШЕБЕЗ ТӨРКИЯДӘ ЯШӘСӘ ДӘ, ТАТАР ТАРИХЫ БУЕНЧА КҮП ХЕЗМӘТЛӘР КАЛДЫРГАН. ӘЙТЕРГӘ КИРӘК, АНЫҢ ХЕЗМӘТЛӘРЕ ҺАМАН ДА ТӨРКИЯ УНИВЕРСИТЕТЛАРЫНДА УКЫТЫЛА, Ә ИҖАТЫ ГАЛИМНӘР ТАРАФЫННАН ТИКШЕРЕЛӘ. БЕЛГӘНЕМЧӘ, БҮГЕН ТӨРКИЯДӘ Ә.Н.КУРАТНЫҢ КҮПКЫРЛЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ БУЕНЧА БЕРНИЧӘ ДИССЕРТАЦИЯ ЯКЛАНГАН, ШУЛАЙ УК ЯКЫН КИЛӘЧӘКТӘ БӨТЕН ФӘННИ ХЕЗМӘТЛӘРЕН ТУПЛАП ЧЫГАРЫРГА ДА УЙЛЫЙЛАР.

Әкъдәс Куратның берничә хезмәте Алтын Урда тарихы белән бәйле мәсьәләләргә карый. Сүз түбәндәге әсәрләр турында бара: «Kazan Hanlığını kuran Uluğ Muhammet Hanın Yarlığı» (Казан ханлыгын корган Олуг Мөхәммәд ханның ярлыгы) [1], «Topkapı Sarayı Müzesi Arşivindeki Altın Ordu, Kırım ve Türkistan Hanlarına ait yarlik ve bitikler» (Топкапы Сарае музееның архивындагы Алтын Урда, Кырым һәм Төркстан ханнарының ярлык һәм битекләре) [2], «IV-XVIII yüzyıllarda karadeniz küzeyindeki Türk kavimleri ve devletleri» (IV-XVIII гасырларда Кара диңгезнең төньягында төрки кавемнәре һәм дәүләтләре) [3] һәм Казан ханлыгына багышланган мәкаләсе [4].

Ә.Курат Алтын Урда тарихын үзенең «IV-XVIII гасырларда Кара диңгезнең төньягында төрки кавемнәре һәм дәүләтләре» китабында киң яктырткан, чыганаклардан зур гына өзекләр дә китергән. Биредә Ә.Курат тарихи вакыйгаларны тасвирлау белән генә чикләнмәгән, ә аңлашылмаган, сорау тудырган мәсьәләләргә ачыклык кертергә тырышкан, җавап эзләгән. Аның фикеренчә, Чыңгыз-хан төзегән дәүләтне Монгол-Төрки каганлыгы дип атарга кирәк. Чөнки аның төп халкы төркиләр, бөтен дәүләт системасы элегрәк яшәгән төрки дәүләтләрнең

Сулдан уңга: Әхмәт Тимер, Һәдия Курат, Рана Тимер, Әкъдәс Нигъмәт Курат. Анкара. 1971

дәвамы. Борынгы татар кабиләләре турында язганда, Ә.Курат аларның чынлыкта төрки булганлыкларын яза, соңыннан татар исеме белән башка төрки кабиләләрнең дә берләшүен ассызыклый. Шулай ук Алтын Урда чорында Урта Азиядән Чыңгызыйлар явы белән килгән татарлар илә кыпчак һәм болгарларның берләшеп, яңа халык булып оешып китүе, татар исеме астында танылуы турында яза. Галим милли тарихыбызның бу шанлы чорын Алтын Урда сәяси тарихы, көнкүреше, шәһәрләре, һәм, әлбәттә, хан һәм бөек морзалары язмышлары аша ача. Автор Батый хан, Бәркә, Мөхәммәт, Үзбәк, Җанибәк, Туктамыш, Тимер Котлык, Шадибәк, Җәләлетдин, Кәрим-Бирде, Булат, Дәрвиш, Чөкрә, Мөхәммәт, Барак, Мәхмүд һәм Әхмәд ханнар, Миңлегәрәйләр һәм Хаҗигәрәйләр династиясе вәкилләре, Идегәй, Мансур һәм Гыясетдин морзалар хакында тәфсилләп бәян иткән.

Галимнең махсус игътибар биргән шәхесе — Алтын Урданың соңгы ханы һәм Казан ханлыгын нигезләүче Олуг Мөхәммәд хан. Курат урта гасырның бу бөек шәхесенә аерым китап-мәкаләләр багышлаган, гомумән, Олуг Мөхәммәд турында күп язган. Ул ханның шәҗәрәсен, тормышындагы төп вакыйгаларны, аңа нисбәтле ярлыкларны һәм башка чыганакларны тикшергән. Ә.Куратның Олуг Мөхәммәд турында язган хезмәтләре бүген дә фәнни әһәмиятен җуймаган.

Ә.Курат тарихи шәхесләрнең психологик сыйфатларын тәфсилләп тасвирлый, аларны төрле гамәлләргә этәргән холык үзенчәлекләренә игътибарны җәлеп итә. Мәсәлән, ул Олуг Мөхәммәдне төшенкелеккә бирелми торган холыклы шәхес буларак сурәтли. Безнең фикеребезчә, Ә.Курат бу мәсьәләдә бик хаклы. Олуг Мөхәммәд илдә сәяси вазгыять катлаулы елларда хан тәхетенә утыра, аннан соң, бөтен авырлыкларны җиңеп, Алтын Урдада тынычлык урнаштырдым, дигәндә генә, Сарайны калдырып китәргә мәҗбүр була. Соңыннан Кырымны да югалта, Олуг Мөхәммәд кыенлыклар алдында югалып калмый, бөтен көчен куеп, яңа баштан дәүләт төзү эшенә керешә. Гомеренең соңында татарның бөек дәүләте — Казан ханлыгын төзи.

Әмма Ә.Курат, белгеч буларак, Казан ханлыгын оештырудан тыш, Урта Иделне тулысынча контрольгә алу, дәүләтне яшәтеп җибәрү, шулай ук Касыйм ханлыгы оешуда Олуг Мөхәммәд улларының өлеше зур булуын ассызыклый. Ә.Курат Олуг Мөхәммәднең шәҗәрәсенә дә ачыклык кертә, аның Эчкеле Хәсән улы икәнлеген яза һәм кайбер язма чыганакларда киткән төгәлсезлекләрне (мәсәлән, госманлы мәшһүр тарихчы Әхмәд Дәдә һәм Морад

Рәмзи) ачыклый [5]. Куратның язган әсәрләре, вакытлар үтүгә карамастан, халыкка хезмәт итүен дәвам итә. Аның бигрәк тә ярлык һәм битекләргә багышланган эшләре зур фәнни кыйммәткә ия.

Ә.Курат татар тарихына караган Алтын Урда чоры документларын таба, өйрәнә һәм бастырып чыгара. Әйтергә кирәк, Ә.Курат — тарихи чыганакларны шәрехләп уку, җитди күзәтүләр ясау остасы. Ул документларны җентекләп өйрәнә, транскрипция ясый һәм төрекчәгә тәрҗемә итә, җөмләләрнең мәгънәсен югалтмыйча, дөрес тәрҗемә итү мәсьәләсен күтәрә һәм текстларга филологик анализ ясый. Монда шуны да әйтергә кирәк: урта гасыр татар документлары бөтенесе чагатай телендә язылган, дип әйтү әле һаман да дәвам итә. Югыйсә, бу ясалма термин чынбарлыкка туры килми. Ә бит «Идел буе төрки теле», «татар теле» (иске татар теле, урта гасыр татар теле) термин буларак күптән билгеләнгән. Ә.Курат, ярлык һәм битекләрнең телен фәндә чагатайча атап йөртелүгә карамастан, әлеге документларның чынлыкта Алтын Урда чоры әдәби теле ядкәре икәнлеген искәртә. Ә.Курат Алтын Урданы һәм төрки-татар халыкларының тарихын өйрәнүдә татар чыганакларының әйтеп бетергесез әһәмияткә ия икәнлеген ассызыклый.

Ә.Курат тарафыннан табылып, анализланып, фәнни әйләнешкә кертелгән Алтын Урда чыганаклары түбәндәгеләр:

— Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәднең Госманлы солтаны Морад II гә язган хаты (битеге) [6];

— Олуг Урда ханы Әхмәд-хан бин Мөхәммәд-хан бин Тимер-ханның Госманлы солтаны Фатих Солтан Мәхмәдкә язган хаты [8].

Галим шулай ук, Алтын Урда (Олуг Урда) ханы Мәхмүд-хан бин Мөхәммәд-хан бин Тимер-ханның Госманлы солтаны Фатих Солтан Мәхмәдкә язган хатын анализлап, беренче булып фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә [7].

Курат бу чыганакларны, әйткәнемчә, филологик һәм тарихи яктан тикшереп, күп кенә яңа мәгълүматлар алган. Мәсәлән, ул ярлыкның битектән нәрсә белән аерылганлыгы турында тәфсилләп яза. Кызганыч, аның әлеге анықламасына күп кенә галимнәр бүген дә игътибар итмиләр һәм, бутап, ялгыш нәтиҗәләргә киләләр. Югыйсә, ярлык үз эченә фәрманны ала, һәм хатларга ярлык дип әйтү дөреслеккә туры килми. Хатларга битек дигәннәр (борынгы төрки термины «битек» — «бителде», ягъни «язу» — «язылды» мәгънәсендә килә). Шулай ук Курат бу өч хатны чагыштырып, охшаш якларын билгеләде. Баштагы хатлар чын төрки-татар телендә язылса, соңракларында төрки терминнарның гарәп сүзләре белән алыштырылганлыгы күренә. Госманлы канцелярия алымнарының да тәэсире үзен сиздерә. Әлеге үзгәрешләр, тел үзенчәлекләреннән тыш, 12 циклы җәнлек календаре кулланылудан туктауда да күренә (Әхмәд-хан хатыннан башлап), хатның язылыш формасы да үзгәрә.

Ә.Курат, бу үзгәрешләрне ачыклаганда, башка язма чыганакларга да таянып эш итә. Галим, бүгенгә кадәр тарихчылар сирәк кулланган «Мөнәҗҗимбашы тарихы» һәм Габделгаффар Кырыми әсәрләрен оста файдаланган, башка мөһим чыганаклардан да өзекләр китергән. Болар арасында Әбделгазый, Ибн Баттута, Плано Карпини һәм рус елъязмаларын атап үтәргә була.

Ә.Курат Алтын Урдада идарә иткән Җучи династиясе вәкилләренең Чыңгыз хан заманыннан ук аерым дәүләт төзергә омтылганлыгын һәм тиз арада бәйсезлеккә ирешкәнлеге турында яза. Галим Алтын Урда халкының көнкүреше, шәһәрләре, хәрби көчләре мәсьәләләренә игътибар итә. Рус

Олысының Алтын Урда дәүләтендә тоткан урынын, статусын һәм ролен Курат бик дөрес ачыклый. «Татар игосы» темасына да кагыла һәм бу терминның СССР — Россиядә бер «модага» әйләнгәнлеген әйтә. Рус дәүләтенең алдынгы дәүләт була алмаганлыгында гел татар чорын гаепләргә тырышуның хакыйкатьтән бик ерак торганлыгын дәлилли. Чынлыкта Алтын Урда дәверендә рус кенәзлекләрендә дин иреге булуы, халыкара сәүдә өлкәсендә татарларның зур роль уйнаганлыгы һәм болар рус җирләренең үсеше өчен гаять зур мөмкинлекләр биргәнлеге турында онытмаска кирәк.

Гомумән алганда, Курат үз эшләре белән Олуг Мөхәммәд ханны һәм бигрәк тә XV гасырның беренче яртысындагы вакыйгаларны тирәнтен өйрәнеп сурәтли алган. Безнең фикеребезчә, бу дәвер буенча әле күп мәсьәләләр Курат дәрәҗәсендә өйрәнелмәгән, тикшеренүчеләр өчен галимнең әсәрләре ныклы нигез, яхшы этәргеч булып тора.

Куратның галим буларак тагын бер ягына игътибарны җәлеп итәсем килә. Ул, иске, калыплашкан фикер-карашларны узып, мәсьәләгә яңача караган. Бу аның методологик һәм методик яктан көчле белгеч, проблемаларны тоемлый белүче зур галим булуын раслый. Ә.Курат шәһәр культурасына, көнкүрешкә, күчмәнлеккә генә түгел, ә утрак тормышка, дини вазгыятькә, кануннарга, олыс системасына, социаль мәсьәләләргә анализ ясаган һәм, әйтергә кирәк, әлеге проблемаларны уңышлы чишкән дә.

Ә.Курат ни өчен Бөек Алтын Урда таркалган, дигән сорауга да җавап эзли. Бу мәсьәләне чишкәндә, темага киң, күпкырлы проблемалар комплексы аша карау хас. Җимерелү фаҗигасенең төп сәбәпләренең берсе, әлбәттә — Алтын Урда җирләренә Аксак Тимернең яулары. Ә.Курат болай дип язган: «Кем ни теләсә, шуны әйтсен, әмма Алтын Урданың җимерелүендә иң зур роль — Аксак Тимер яулары нәтиҗәсе» [9]. Шул сәбәпле Ә.Курат Аксак Тимергә бик тискәре бәя дә биргән.

Аның фикеренчә, Аксак Тимер факторы Алтын Урданы һәм Госманлы солтанлыгын бер-берсенә якынайткан. Алтын Урда һәм Госманлы дәүләте, мәмлүкләр Мисыры кебек, берничә дәүләт белән берләшеп, гаскәри берлек кора. Әмма бу ике дәүләт җитәкчеләре дә Аксак Тимерне үз көчләребез белән җиңә алабыз дип уйлаган. XV гасырның беренче яртысында Госманлы дәүләте яңадан көчәя башлый һәм Кара диңгез сәүдә юлын тулысынча үз кулына ала. Алтын Урда ханнары бу көчәюне борчылып күзәтсәләр дә, Госманлы солтаннары белән яхшы мөгамәләдә булалар, җиңүләре белән котлап, хатлар юллыйлар, илчеләр җибәрәләр. Ә Ә.Курат фәнни әйләнешкә керткән Алтын Урда ханнарының хатлары моны исбатлап тора.

Әдәбият һәм чыганаклар

1. Kurat A.N. Kazan Hanlığını kuran Uluğ Muhammet Hanın Yarlığı. – Istanbul: Burhaneddin Matbaası, 1937. – 36 s.
2. Kurat A.N. Topkapı Sarayi Müzesi Arşivindeki Altin Ordu, Kirim ve Türkistan Hanlarina ait yarlik ve bitikler. Dil ve Tarih – Coğrafya Fakültesi yayinlarindan. Tarih serisi. – Istanbul: Bürhaneddin matbaası, 1940. – 212 s.
3. Kurat A.N. IV-XVIII yüzyıllarda karadeniz küzeyindeki Türk kavimleri ve devletleri. – Ankara: Murat Kitabevi Yayınları, 1992. – 511 s. + 1 harita + 2 resim.
4. Kurat A.N. Kazan Hanliği (1437–1556) // Ankara Ün: Dil ve tarih coğrafya fakültesi dergisi, cilt 12, sayı 3-4. – Ankara: 1954. – S.227-247.
5. Исхаков Д.М. О родословной Улуг-Мухаммеда // Тюркологический сборник / 2001: Золотая Орда и её наследие / редкол. т.: С.Г.Кляшторный (пред.), В.В.Трепавлов, Д.М.Исхаков. – М.: Вост. лит., 2002. – С.63-74.
6. Kurat A.N. Topkapı Sarayi Müzesi Arşivindeki Altın Ordu, Kırım ve Türkistan Hanlarına ait yarlık ve bitikler. – S.6-36.
7. Kurat A.N. Topkapi Sarayi Müzesi Arşivindeki Altın Ordu, Kırım ve Türkistan Hanlarına ait yarlık ve bitikler. – S.37-45.
8. Шунда ук. – S.46-60.
9. Шунда ук. – S.17; Kurat A.N. IV-XVIII yuzyıllarında karadeniz kuzeyindeki türk kavimleri ve devletleri. – S.138. ■


ПОЧТА СССР



Әдәбият

Хәләл-хәрәмдерме
якыннардан
аерып алган сихри хөррият –
әсир итте сәер ул хөррият –
исеме аның –
иҗат. Шигърият.

Саҗидә Сөләйманова

ЙОСЫФ БАЛАСАГУНИНЫҢ «КОТАЙТКЫЧ БЕЛЕК» ӘСӘРЕ – ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ,
филология фәннәре докторы, профессор

1. «Кутадгу билик» — борынгы (монгол яуларына кадәрге) төрки әдәбиятының иң күренекле нәмүнәсе. Ул — күләме җәһәтеннән генә түгел, эчтәлегенең байлыгы, бигрәк тә тарихи мәгълүматлылыгы җәһәтеннән дә төрки телле әдәбиятта XV гасырга кадәр тиңе булмаган иҗат җимеше.

Әйтергә кирәк ки, «Кутадгу билик» — татарча «Котайткыч белек», «Бәхет китерә торган белем» — бүгенгә кадәр тиешенчә бәяләнмәгән әсәр. Рус һәм Европа филологлары бу әсәргә «традицион» рәвештә диярлек кимсетебрәк карыйлар. Атаклы тюрколог В.В.Радлов, үзе «Кутадгу билик» турында махсус тикшеренүче һәм нәшер итүчеләрнең беренчесе булса да, шулай ук атаклы төрки тарих белгече В.В.Бартольд та «Кутадгу билик»не «буш әсәр», «оригиналь түгел» дип бәяләгәннәр. Хәер, аларның кулында тулы текст булмаган. XX гасырның егерменче елларына кадәр «Кутадгу билик»нең тулы булмаган ике нөсхәсе генә билгеле була. Исемнәре алдан аталган галимнәрдән соңрак язган кайбер филологлар да бу әсәрне «өйрәтмәләр җыентыгы» дип кенә бәяләгән.

Башкорт-татар (атасы — башкорт, анасы — татар, үзе татар матбугатында актив эшләгән) тарихчысы З.Вәлиди 1913 елда «Кутадгу билик»нең тулырак бер нөсхәсен таба. Ләкин кулъязманың иясе аны галимнәргә бирергә ашыкмаган. Тик 20 нче елларда гына үзбәк филологлары ул кулъязманы кулга төшерә һәм күчермәләрен булдыра. Шуннан соң гына әсәрнең тулы дип әйтерлек текстын өйрәнергә мөмкинлек туа (әмма лакуналар — төшеп калган урыннар бар һәм аларны тутыру ихтималы күренми әле).

«Кутадгу билик»не өйрәнгән галимнәрнең иң күренеклесе — әлбәттә, Төркиядә эшләгән татар галиме Рәшит Рәхмәти-Арат. Ул «Кутадгу билик»нең факсимилесен, транскрипцияләнгән текстын, төрекчәгә тәрҗемәсен башкарып нәшер иттерә.

1970 елда Ленинградта «Кутадгу

билик»нең 900 еллыгына багышланган гыйльми конференция уздырыла. Шуннан соң гына «Кутадгу билик» фән дөньясында тиешле бәяне ала башлый (мәзкүр конференция материаллары «Советская тюркология» журналының 1970 елгы 4 нче санында басылган). 1981-1982 елларда Мәскәүдә нәшер ителгән «История всемирной литературы» («Бөтендөнья әдәбияты тарихы») басмасының II томында (201-202 б.) «Кутадгу билик»кә югары бәя бирелгән.

Кызганычка каршы, бүгенгәчә бу әсәрнең төрки телләргә сәнгатьчә адекват тәрҗемәсе юк кебек. Русчага шигъри тәрҗемәләр бар (бигрәк тә С.Иванов тәрҗемәсе билгеле). Әмма русча тәрҗемә, әлбәттә, төрки халыкларны канәгатьләндерә алмый.

Моннан унбиш еллар элек «Кутадгу билик»не бер татар шагыйрәсе тәрҗемә итә дигән хәбәр таралды. Тик ул шагыйрә оригиналда төрки булган әсәрне русчадан тәрҗемә итәргә теләгән бугай. Болай ярамый, әлбәттә. «Кутадгу билик» теленең лексикасы, фраземалары һәм грамматик формалары татар теленекенә еш кына бик якын ич!

«Кутадгу билик»нең авторы Йосыф хасс хаҗиб[1] Баласагуни (Баласагун шәһәреннән) борынгы уйгыр теленә якын телдә сөйләшкән һәм язган. Бу тел төп характеристикалары буенча татар теленә охшаш. Хәзерге үзбәк теле дә, төрек яисә азәрбайҗан телләре дә «Кутадгу билик» теленнән читтәрәк тора, борынгы төрки-татар теленең уртак нормаларыннан да тайпыла төшкән.

Әйткәннәрдән чыгып, «Кутадгу билик» теле — борынгы татар теле, дип күрсәтергә ярамас, әлбәттә. Тик шунысы бар: «Кутадгу билик»нең теле татар әдәби теле үсешенә йогынты ясамый калмаган. Элеккерәк заманнарда «Кутадгу билик» киң таралган булган. Бу хакта әсәрдән алынган аерым кушыклар, өзекләрнең төрле җирләрдәге борынгы ядкәрлекләрдә очравы сөйли. Әмма соңрак, «Кутадгу билик» яңа тарихи шартларда актуальлеген югалта төшкәч, аны күчерүчеләр сирәгәйгән.

«Татарский энциклопедический словарь»нең 1999 елгы басмасында «Котадгу билик» татарлар арасында электән киң таралган әсәр дип тә күрсәтелә. Хәлбуки, әлеге әсәрнең бүгенгә кадәр татарча нәшер ителгән яисә татар нәшриятында калган кулъязмасы билгеле түгел!

2. Без ошбу тәрҗемәбезне, нигездә, кириллик танскрипцияләр һәм үзбәкчәгә параллель прозаик тәрҗемәдә 1971 елда Ташкентта К.Кәримов тарафыннан хәзерләнеп нәшер ителгән басма буенча эшләдек. Эчтәлеге ягыннан хезмәтебез К.Кәримов тәрҗемәсен тулысынча кабатламаган хәлдә (кайбер очракларда без галимнең хаталарын да таптык), без, әлбәттә, аның тәэсиреннән читтә калмадык. Борынгы төрки сүзләрнең эквивалентларын еш кына К.Кәримовтан «күчердек».

Әйткәнебезчә, К.Кәримов тәрҗемәсе прозаик — чәчмә характерда. Оригинал текст гарәп шигъри үлчәме — мөтәкарип вәзенендә язылган, дөресрәге, язарга тырышылган. Гаруз бәхерләрен белүчеләр Йосыф Баласагуни бәхерләренең (стопаларының) бик үк эзлекле дә, еш кына дөрес тә түгеллеген билгеләгәннәр. Без, гомумән, гаруз вәзененнән баш тарттык: шигырь ритмикасы сәтыр (юл) башыннан алты иҗектән соң цезура саклау, унбер иҗекле рифмалы сәтыр һәм эчке рифмалар оригиналның ритмик чараларына адекват булыр дип уйладык.

«Кутадгу билик»нең теле безнең (татарча) карашка бик тигезсез: кайбер урыннар (без аларны курсив илә билгеләдек), фонетик үзенчәлекләрен искә алмаганда, нәкъ бүгенге татарча язылган кебек яңгырыйлар, икенче яктан, еш кына хәзер аңлавы кыен булган сүзләр вә җөмләләр дә очрый.

Шуны да әйтеп үтик: «Кутадгу би-

[1]Хасс хаҗиб — махсус кабул итүче, ханның киңәшчесе һәм церемониймейстер.

лик» шактый шомарган, эшкәртелгән әдәби-язма телдә иҗат ителгән. Димәк, XI гасырда инде шул даирә төрки теле илә язылган бүтән әсәрләр дә булган. Югыйсә, Й.Баласагуни шулкадәр күләмле шигъри әсәр язарга керешмәс иде.

3. «Кутадгу билик»нең геройлары күптөрле: автор үзе символик образлар дип характерлаган Көнтугды, Айтулды, Үгделмеш һәм Уйгырмыш һәм, аннары, эпизодик ике кеше — Күсәмеш һәм Ирсү, исеме билгесез хасс хаҗип, исеме әйтелмәгән углан. Ләкин төп геройлар индивидуаль характеристикага ия һәм алар чын әдәби сәнгатьчә минәзләр (образлар).

Көнтугды — зур булмаган төрки дәүләтнең илбиге (кайбер кулъязмаларында элик әлик дип язылган, без аны, З.Вәлидигә ияреп, илбик дип алдык), ягъни кенәз. Ул үзен һавалы гына тота, ләкин үзенең чамасын да белә, шактый акыллы вә инсафлы кеше. Тик аның сәләтләре һәм мөмкинлекләре зур түгел. Шуңа карамастан, Көнтугды илбик бөек эшләр турында хыяллана, үзен бөек итеп, киләчәк буыннар хәтерендә калырлык итеп күрсәтмәкче. Әсәрдә аның еш кына, үз «кабинетына» бикләнеп, көндәлек эшләр илә артык кызыксынмастан, хыялланып гомер уздыруы тасвирлана.

Айтулды — урта хәлле хаким сыйныфлар вәкиле. Ул үзенең сәләтләрен тормышка ашыру өчен, илбиккә хезмәткә кермәкче булып, авылдан «башкалага» килә. Төрле маҗаралардан соң максатына ирешә һәм тырышып эшли. Ул — үзенчә идеаль вәзир булып җитешә: күндәм һәм эшчән.

Аның углы Үгделмеш — әсәрдә төп герой, тулырак характеристика илә сурәтләнгән. Атасыннан яшьли ятим калса да, заманы өчен зур белем ала. Вәзир булып алгач, бик тиз ныгый, мактанчык илбиккә ярау-ярашу белән бергә, асылда аны үз кулында тота, хәтта акыл өйрәтә башлый. Илбик бу хәлдән риза түгел, ул вәзиренә җәза бирү белән яный. Ләкин, асылда, акыллы кеше буларак, Үгделмештән әйбәтрәк вәзир табалмаслыгын да аңлый. Әсәрнең азагына кадәр диярлек Айтулды белән Үгделмеш арасында «келәм асты көрәше» барганлыгы сизелә. Берара Үгделмеш ниндидер әләкбоһтанга дучар була һәм, хәтта кардәше Уйгырмыш кебек заһид булып, каладан чыгып китмәкче. Ләкин илбикнең аны җибәрәсе килми. Илбик тә, Үгделмеш тә үзара килешеп яшәргә мәҗбүрләр.

Уйгырмыш — психологик җәһәттән иң тәфсилләп характерланган персонаж. Яшьлегендә гайрәтле иргегет булып яшәгән. Ләкин ниндидер уңышсызлыктан соң заһидлыкка йөз тоткан, дингә мөкиббән киткән. Ул — рухи көчле, белемле-фикерле, ләкин экзальтациягә (шик-шөбһәгә) бирелүчән, еш кына икеләнүчән. Тик ахыр чиктә хак әхвәлне дөрес аңларга сәләтле. Илбик аны сараена чакыра, кат-кат үгетли, хәтта яный. Күрәсең, атаклы әүлия-заһид аңарга үз абруен күтәрү өчен кирәк. Ләкин Уйгырмыш, әхвәлътне белешеп һәм төрле яктан уйлап, сарай әһеле булудан баш тарта. Әгәр безнең заман кешесе шул чорга эләксә, ахыр чиктә нәкъ Уйгырмыш шикелле карарга килер иде. Ягъни: «Бу хәлемнән кинәт сарай әһеле булып китү — авантюра», — дияр иде.

Гомумән, безнеңчә, әсәрдәге Уйгырмыш — югары сәнгатьчә эшләнгән реалистик минәз-образ. Әсәрдә Уйгырмыш тиз арада үлеп китә. Әсәрне шуның белән тәмамлау, безнеңчә, авторның заһидлыкның мәгънәсезлеген сизенүеннән һәм шуны белдерергә теләвеннән килә.

4. Югарыда әйткәнебезчә, кайбер европача уйлаучан тикшеренүчеләр «Котайткыч белек» әсәренә түбәнсетепкимсетеп караганнар. Әмма бөтен дөньяда XI гасыр әдәбиятында «Котайткыч белек»кә тиң килерлек әсәрләр кайда бар икән? Безгә таныш борынгы рус әдәбиятында, мәсәлән, андыйлар юк.

Әлбәттә, сәнгатьчәлек ягыннан «Котайткыч белек» үзенә замандаш

һәм үзеннән элгәре язылган кайбер әсәрләрдән калыша: анда бер үк сүзләрне, фикерне кабатлаулар бик күп. Исемсез акылдарлар фикерен «ишеттерүче»ләрнең бик күплеге дә матур түгел. Кайбер троплар да зәвыксыз кебек.

Йосыф хасс хаҗиб, матди байлыкка һәм хәрби куәткә уңай караган хәлдә, һәрвакыт дөньяның фанилыгы турында сүз куерта. Моны авантюралардан сакланырга чакыру дип уйларга ярый. Ләкин аның сарайлар, ныгытмалар төземәгез, диюе белән килешеп булмый. Гомумән, бу хасс хаҗибның дәүләтчелек карашлары каршылыклы, тар вә таркау. Бу хәл XI гасырдагы төрки дөньяның таркаулыгына тәңгәл. Һәм менә шул хәл XIII гасыр башларында төркиләрнең тарихта иң зур фаҗигасенә — монгол яуларыннан җиңелүгә китергән дә.

Әсәрдә төп мотив — дөрес, идеаль дәүләтчелек идеясен алга сөрү. Шул ук вакытта дөньяның фанилыгын бәян итүгә күп урын бирелә һәм хәстәрсезлек мотивы — иҗаби [уңайлы, уңышлы] сыйфат булып чыга. Әйткәнебезчә, автор хөкемдарларны ныгытмалар, зур сарайлар төземәскә чакыра! Барыбер беркөн җир белән тигез булачак, ди.

Бер урында авторның гашыйкмәгъшуклык поэтик фәлсәфәсен яхшы белүе дә чагылып китә. Шул ук вакытта Йосыф хасс хаҗиб — хатын-кызларның хокукларын чикләү, аларны тезгенләп тоту тарафдары.

Әйе, әсәр мәгълүмати ягы белән бик тә кыйммәтле: ул үзенчә — «XI гасыр төрки дәүләтләре энциклопедиясе» һәм, ахыр чиктә, хасыйле-кәлям, тирән гуманистик әсәр. Анда һәрдаим фән-белем мактала, сәвәтсез (укый-яза белмәгән) кеше чын кеше түгел дигән фикер әйтелә, «кеше һәр җәһәттән матур булырга тиеш» дигән караш үткәрелә. Шәфкатьсезлек кире кагыла һ.б.

Барча борынгы һәм иске төрки әдәбияты әсәрләрендәге шикелле, «Котайткыч белек»тә кешеләрне мөселман һәм кяферләргә бүлү-аеру бар, әмма төрки һәм төрки түгелләргә аеру юк. Дөрес, төрки тел турында, төрки телдә әдәби-бәдигый әсәрләр юклыгы турында һ.б. әйтелә. Ләкин бу гаяләр тирәнгә бармый. Төрки горурлык хисе уятылмый, үстерелми диярлек. Авторның патриотизмы сүлпән, формасыз. Дәүләтне төркиләштерү һәм төрки дәүләтләрне берләштерү идеяләре телгә алынмый һ.б. Әсәрнең бу үзенчәлеген «интернационализм» дип булмый, чөнки әсәрдә халыклар дуслыгы һ.б. турында (яки шуңа охшаш) сүзләр дә юк. Шулай ук сугыш һәм солых мәсьәләләрендә дә авторның ачык-анык карашлары сизелми, позициясе томанлы. Хәлбуки, мөхтәрәм хасс хаҗиб кирәгендә сүз-хөкем аешын белә! Әнә гыйбадәт мәсьәләсендә никадәр ачык вә тормышчан әйтелгән: коры гыйбадәт, намаз-ниаз тәңре дәргяһында кабул ителәме әле — билгесез, ә менә игелекле эш-гамәлләр, һичшиксез, кабул ителә, бу хакта сүз дә булырга мөмкин түгел, ди Үгделмеш.

Йосыф Баласагуниның, дөньяви мәсьәләләр турында күп сүз йөртеп тә, иң кирәкле моментларда кайвакыт аксап китүе кайбер тикшеренүчеләрнең әсәргә түбәнсетеп каравына сәбәп булган. Гомумән исә, ошбу әсәрнең бөтен дөнья масштабында иң күренекле әсәрләрнең берсе булуына беркем дә шикләнми. Бигрәк тә төрки халыклар өчен бүген дә актуаль, кыйммәтле комарткы (чыганак) ул. «Кутадгу билик», мәсәлән, югары фәлсәфи фикернең төрки халыкларга элек-электән таныш булганлыгын күрсәтә. Тарих өчен мәгълүмат чыганагы буларак, «Кутадгу билик» бәяләп бетергесез.

5. Борынгы әдәби ядкәрләрне фәнчә тәрҗемә иткәндә һәм бастырганда, түбәндәге эшләр күрелергә тиеш: 1) факсимиле пичәтләнә; 2) текстның транскрипциясе һәм шәрехләр бирелә; 3) әсәрнең критик тексты төзелә һәм шуның сүзгә-сүз тәрҗемәсе бирелә; 4) оригиналның сүзлеге төзелә, шунда ук сүзләрнең хәзерге телгә тәрҗемәләре

бирелә; 5) шул эшләрдән соң гына хәзерге киңкатлам укучы өчен сәнгатьчә шигъри тәрҗемә ясала.

Бу эшләрнең 1-4 пунктлары төркләр өчен Р.Рәхмәти-Арат тарафыннан эшләнгән. Ләкин татарлар өчен түгел. Бездә андый эшләр финансланмый һәм, иң мөһиме, квалификацияле кадрлар юк.

Рус филологлары, «Кутадгу билик»-нең русча шигъри тәрҗемәсе булгач, еш кына безгә — төркиләргә: «Сезгә шул җитмимени?» — дип баралар. Гаҗәп хәл. Төрки классик әдәбият теле белән хәзерге рус теле арасында аерма — җир белән күк арасы. Иске төрки әсәрләрне русчага хәтта принципта да тәрҗемәләү — мөшкил эш.

Руслар бөек Пушкин шигырьләренең Көнбатыш Европа телләрендә сәнгатьчә адекват тәрҗемәләре юклыгыннан зарлана. Монда гаҗәпләнәсе юк: бер-берсеннән ерак булган телләрнең шигъри лексика, фразеология, шигъри грамматикалары «чагышмый». Ритмика тудыру чаралары да, һ.б. да туры килми бит, нишлисең?!

Инде төрки телле әсәрне русчадагы тәрҗемәсе буенча татарча тәрҗемәләү бигрәк аяныч нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Менә, мәсәлән, төп текстта «Аллаһу әкбәр» дип язылган, ди. Русчага, гадәттә, «Аллах велик!» дип тәрҗемәлиләр. Русчадан татарчага тәрҗемә итүче моны «Алла бөек» дип язып куячак. Уйлап карагыз инде: бу операциядән соң нәрсә генә торып кала соң? Монда шундый бер афоризм бик урынлы: әгәр төп шигъри текст бер сылу чыршы булса, аның икенче телгә тәрҗемәсе шул чыршыдан ясалган коры телеграмм баганасы, ди. Әгәр ул телеграмм баганасын да тәрҗемәләсәк, бары төпчек кенә торып калачак. Конкретлаштырып күрсәткәндә, әлеге мисалда «Аллаһу әкбәр» сүзенең «кире» тәрҗемәсендә:

1). эмоциональ-экспрессив аһәңе;
2). семантик күләме (мәгънә структурасы);
3). стилистик системадагы урыны;
4). шигъри исәпкә алынган яңгырашы һ.б. юкка чыга.

Һәм бу югалтулар бөтен текст буенча барачак. Бер-берсенә аңлаешлы якын кардәш телләрдән алып тәрҗемәләгәндә, әлеге югалтулар минималь дәрәҗәдә кала. Әлбәттә, расламадан чигентеләр дә булгалый. Мәсәлән, татарча дәртле — «страстный», ә якын кардәш Казахстан һәм Урта Азия төрки телләрендә дәртле — «чирле, авыру» дигән сүз. Монда сүзмә-сүз тәрҗемәләп булмый. Ләкин мондый очраклар — йөз дә бер генә.

Әйтелгәннәрдән чыгып, без төрки телдәге әсәрләрне рус теле аша тәрҗемә итүне мәдәниятсезлек дип бәялибез.

Әйткәнебезчә, без бу тәрҗемәне «Котайткыч белек»нең К.Кәримов башкарган кириллик транскрипциясе буенча эшләдек. Шуннан соң әсәрнең Төркиядә эшләгән татар галиме Рәшит Рәхмәти-Арат башкарган тәрҗемәсе буенча да бер карап чыктык. Арат тәрҗемәсендә икеюллыклар саны ике йөз кырыкка артык. Шулкадәр зур әсәр өчен бу күп түгел. Гомумән, һәр ике текст үзара тәңгәл, дияргә мөмкин. Текстның төп өлешендә аермалар күләме 5-6 проценттан артмый.

Тәрҗемәләрнең сыйфатына килгәндә, үзбәкчәгә тәрҗемә төрекчәсеннән яхшырак яки киресенчә дип әйтеп булмый. Үзбәкчә тәрҗемәдә борынгы төрки сүзләр күбрәк сакланылган. Рәхмәти-Арат, күрәсең, тәрҗемәсен хәзерге төрек әдәби теленә якынрак итеп башкарырга тырышкан.

Кайбер текстка җанлылык керткән очракларда без Рәхмәти-Арат текстыннан кайбер икеюллыкларны К.Кәримов язганнарга өстәп кертеп җибәрдек. Андый очраклар йолдызчык белән күрсәтелде. Сирәкләп, аермалы урыннарны да күрсәттек.

Ноксаннарыбыз өчен гафу итегез.

КУТАДГУ БИЛИК
(Котайткыч белем)

ЙОСЫФ БАЛАСАГУНИ
(ЙОСЫФ ХАСС ХАҖИБ)

Бисмилләһиррахманиррахим.

Тәбрик һәм данлау, шөкерана вә мактау Тәңре газзә вә җәллага[2], кайсы кем олуглык иясе һәм Тамм-төгәл (абсолют) кодрәтле падишаһтыр — ул җирне-күкне яралткан, барча җан ияләренә ризык биргән. Ул ни теләсә, шуны кылган һәм ни теләсә, шуңа ирешәдер — яфгалүл лаһү ма йәтагъвә вә яхкүкү ма йүрид[3]. Шулай ук кешеләр арасында иң олугы — тәңре илчесе булмыш рәсүлебезгә сансыз сәламнәр булсын һәм кылмышлары бөек газиз сәхабәләргә ризван Аллаһи галәйһим әҗмәгыйн[4]. Бу китапны бик тә абруйлы дип белегез — ул хәкимнәрнең (логик) нәтиҗәләренә нигезләнгән, Мачин хәкимнәрнең шигырьләре белән бизәлгән. Һәм бу китапны укып, аны бүтәннәргә мәгълүм итүче китапның үзеннән дә абруйлы булыр. Мачин галимнәре вә хәкимнәре шундый бердәм фикергә килделәр — барча Көнчыгыш өлкәләрендә, Төркестан илләрендә Богра-хан телендә бу китаптан да яхшырак китапны әле беркем дә язмаган. Бу китап каю патшага вә каю икълимгә барып житсә дә, гаять акылдарлыгыннан, ниһаять дәрәҗәдә сәнгатьчәлегеннән, ул илләрнең хәкимнәре-галимнәре барсы да бердәй кабуллап, төрле шәрәфле атамалар бирделәр: чыйнлылар әдәбел-мөлек[5], Мачин хөкемдарының нәдимнәре гаенүл-мәмләкәт[6], мәшрикъ кешеләре зийнәтел-гомәрә[7], дип атадылар. Иранлылар Шаһнәмәи төрки[8], диделәр, ә кайберләре патшаларга нәсыйхәт дип бәяләделәр, ә туранлылар Котайткыч белем дип исемләделәр. Бу китапны төзүче Баласагун тумасы — тыйнак, тәүфыйклы ирдер. Бу китапны Кашгарда төгәлләп, мәшрикъ мәлиге Табгачхан дәргяһына кереп тәкъдим итте. Мәлик, аны хөрмәтләп, Хасс хаҗиб[9] чинын бирде, шунлыктан Йосыф олуг хасс хаҗиб дигән аты-чабы[10] таралды.

Китапның кыймәте шуңа нигезләнә: анда, беренчедән, гаделлек, икенчедән, дәүләт, өченчедән, акыл, дүртенчедән, канәгатьлек алга сөрелә. Һәм бу сыйфатларның һәрберенә минәз-кеше исеме бирелде: 1) гаделлек — Көнтуды илбик[11], патша мисалы; 2) дәүләт — Айтулды, вәзир мисалы, 3) акыл — Үгделмеш,

[2] Алланың иң югары эпитеты, «газиз нурлы ялкын» кебегрәк аңлатыла.

[3] «Ни теләсә, шуны эшли ала һәм һәрнәрсәгә Үзе хөкем йөртә» мәгънәсендә.

[4] «Аларның җәмгысенә Аллаһның ризалыгы насыйп булсын».

[5] «Илнең әдәбе».

[6] «Дәүләтчелек көзгесе».

[7] «Яшәүнең зиннәтләнеше».

[8] «Төркиләрнең шаһнамәсе». «Шаһнамә» — бөек шагыйрь Фирдәүсинең ирани-фарсы халыкларның тарихи тәҗрибәсен гомумиләштергән күптомлы поэмасы.

[9] Хасс хаҗиб — махсус киңәшче, «тайный советник».

[10] Чап — «дан» — ошбу әсәрдә уңай мәгънәдәрәк кулланыла.

[11] Ошбу әсәрдә монарх, кенәз «элиг» дип атала. Бу сүз кайбер бүтән борынгы төрки ядкәрлекләрдә дә очрый (ДТС: 170), тик хәзерге төрки телләрдә кулланылмый. Без бу сүзне үзенә тамырдаш һәм татар халык телендә дә очрый торган «илбик» сүзе белән алмаштырдык.

вәзирнең углы; 4) канәгатьлек — Уйгырмыш, Үгделмешнең карындашы мисалы. (Әсәрдә) шулар арасында әңгәмәләр кичә, ягъни сораулар-җаваплар әйтелә. Укучымның күңеле ачылып, язучыны изге дога илә искә алсын иде, дип, я, Аллаһы Тәгаләгә (бер дога).

КЕРЕШ

Уган — изге Тәңре, бер һәммәбезгә,
Вә мактауга лаек зат та юктыр үзгә.

Олы зат ул Уган, нурлы вә якты,
Адәмне ул камил итеп яралтты.

Бу җир — күккә, тереклеккә ия ул,
Ризык бирә, «көлеп яшә», дия ул.

Халыкларга ризык бирә ки сансыз
— Аша гына, үзе яши тәгамсыз.

Ни бар җан иясе ач калмый бер дә,
Һәркайсын ашата ул, эчертә.

Теләде — дөньяны бөтен, бар итте.
Теләгән шәхесенә игътибар итте.

Сәлам Хәкъ сайлаган Рәсүлгә мең-мең,
Сәлам дусларына, янә Рәсүлнең.

Халыкларга баштыр Мөхәммәт нәби.
Камуг — барчаларга күзгә каш кеби.

Бу безнең китап та изгегә тиңдер,
Гыйлем тирәнлеге диңгезгә тиңдер.

Бу китап кыйммәтле белемгә илтә,
Шөкер итсәң әгәр — кәнәгатьлектә.

Шигырьләрем галим, хәким сүзеннән
Кадерле энҗеләр кебек тезелгән.

Шәрекъ хөкемдары Кытайның бийе[12]
(Җиһанда акылы илә билгеле)

Бу китапны укып, аңлап алды да,
Хәзинәханәгә кушты салырга.

Серле корал бу дип безнең токымга,
Бүтәннәргә бирми хәтта укырга.

Бу китап чыннан да бөек, үлемсез.
Кадерен белми тик төрки-белексез.

Бу китап хакында ишетсәләр дә,
Укымый күп сәвәтле кемсәләр дә.

Китап сүзе — күңел күзе, җан көче;
Һәр ике дөньяда юл күрсәткече.

Чыйн-Кытай шаһы һәм
Мачин халкы да*,
Гади кешесе дә, асыл заты да,

Кытайы-төркие барсы бер сүздән:
«Моның кебек китап юк, — диде, —
бүтән».

Китапның кадерен белекле белер,
Укымышсызлардан ни мәгънә килер?

Кирәк дуска, кирәк кардәш-якынга
Китабыңны биреп барма һәркемгә.

Чөнки белексезләр белмәс кадерен,
Укымышлы гына абайлар серен.

Моны яздым Бугра хан дәверендә,
Тырышып бу ханның туган телендә.

Йә, кем язган мондый китапны бездә
Вә кем язар икән үз телебездә?

Мондый китап язса берәү, кем дә кем,
Мин мактарга әзер шундый кемсәне.

Һәр авыл, калада, җирле җирендә
Бу китап аталды төрле-төрлечә.

[12] Без, титул мәгънәсендә булганда, бий һәм бәк шәкелендә, нәсел-нәсәп термины мәгънәсендә «би» дип язу яклы.
*Бу урында һәм алга таба икеюллык буларак аңлау кирәк.

Һәр галим һәм хәким үз аңлавынча
Һәр илдә атады аны якынча.

Чыйнда, әйткәнемчә, «патша әдәбе»,
Мачинда — «ил иминлеге — сәбәбе».

Бу мәшрикъ илендә исеме дөрес:
«Яшәү матурлыгы фәненә кереш».

Иранда «Шаһнамә» кебек билгеле,
Ә Туранда инде — «Котайткыч белек».

Акыллырак булса, безнең телдәге
Барча сүзләр бу китапка теркәлде.

Шәрекънең, бак, мәдәни илләрендә
Ни төрле ат бирелмеш телләрендә.

Олуг кеше исем бирде китапка.
Аллаһның рәхмәте төшсен ул затка.

Шундый сүзләрне без китапка
жыйдык,
Алар төркичә, бел, яңа һәм кызык.

Һәммәгә мәсәл һәм гаммәгә мисал,
Патшаларга исә гамәли корал.

Монда идарәче булган хакимнәр
Өчен зур галимнәр әйткән фикерләр.

Ничек эш итәргә идарәчегә,
Ниләр кирәк илнең идарәсенә,

Илнең алгарышы һәм арткарышы,
Мөлкәт тупланышы һәм таркалышы,

Һәм чирү-гаскәрне ничек җайларга,
Җыелу урынын кайдан сайларга —

Менә бу барчасы ошбу китапта
Аңлатыла бәйнә-бәйнә һәрьяктан.

Хөкемдар ныклы кул икән, янында
Булдыклы ирәннәр урын алырлар.

Бийгә гайрәтле бер дус-иш кирәктер,
Бу дус аңар гүя бер шәмчырактыр.

Патшаның хөкеме булса ил-көнгә,
Ил-көн дә патшаны тарта хөкемгә.

Рәгыять күзәтә холкын патшаның,
Ә патша күзәтә аның тән-җанын.

Бу китапта — ничек итеп сугышчан
Патша хәйлә кылыр, булса сугыш —
жәң.

Җәң алдыннан ничек гаскәр тезергә,
Дошман теземнәрен ничек өзәргә.

Патшаларга нинди холык килешә,
Халкын күндерергә ничек ирешә.

Акыллы патшаны сөя халкы да
Һәм, хәтта, күрергә һәркем ашкына.

Котлырак күренгән юньчелне сайлап,
Ил чигенә җибәр, юньсезне җайлап,

Сине якын күргән затны илләштер,
Явыз ниятлене ерак читләштер.

Рәхимсез бул — хөкем кыл башкисәргә,
Рәхим белән саф хислеләргә.

Акыллы, белемле алпар ил башы
Казнаны тутырыр, казнага ташыр.

Халыкка карата нык һәм түземле,
Ни кылса да, имин сизәр үзен гел.

Берничә сүз әйтсәм сезгә нәсыйхәт,
Мин үлгәч, кылырсыз дога,
димен, шәт.

Бу китапны төзегән кешене күрсәң —
Кешеләргә башлык булырлык инсан.

Шундый фазыйләтле булу өстенә
Шат күңелле булып йөри гел генә.

Тыйнаклыктан рухи бөтенлек килә,
囗штә җыйнаклыктан килә нәтиҗә.

Аның туган җире тоташ гөл иде,
Ә үзенең гөле — туган тел инде.

Чит илләрне күреп йөрде ничаклы,
Һәм ахырда язды ошбу китапны.

Моны язгач йөреп төрле якларда
Ахырында тәмам итте Кашгарда.

Патша дәргяһында укыды аны.
Тыңлап, табгач Кара бугра Каганым

Гадәттән тыш хөрмәт итте, хилгатен
Бүләк итте, бирде каләм-хат хакын.

Аннары, багышлап хасс хаҗиблыкны[13],
Үзенең бер якын-яраны итте.

Йосыф хасс хаҗиб дип шуннан аталам,
Һәр инсаннан хөрмәт күрәмен тәмам.

Бу китапның инде әйтим бәянын,
Дүрт изге хакыйкать ни һәм каянын.

Бере — тугрылыктан килгән гаделлек,
Икенчесе — дәүләт, кот һәм хәзерлек.

Өченчесе — җитди, сабыр эшчәнлек.
Соңгысы — тыйнаклык һәм гафучәнлек.

Бу фазыйләтләргә исем куелды
Һәм сәбәпләре дә бәян кылынды.

Гаделлек — Көнтугды илбик дип әйтик.
Маликләр рәтенә аны нисбәтлик.

Дәүләтне Айтулды дисәк әгәр дә,
Вәзирлек урынын тотар әсәрдә.

Сабырлык исеме булыр Үгделмеш.
Вәзирнең иң олы углы ул, имеш.

Уйгырмыш дип атыйк тыйнак
булганны,
Шул инде вәзирнең якын туганы.

Бу дүрт хикмәтле зат бергә тезелде,
Шулар ярдәмендә китап төзелде.

[13] Хасс-хаҗиб — махсус киңәшче.

Гарәпчә, фарсыча китап, гыйлем күп,
Телебездә шушы — барча гыйлемлек.

Белеклеләр моның кадрен белерләр,
Зирәкләр кыйммәтен дәхи күрерләр.

Кушык тездем сиңа төрки телендә —
Доганң булсын миңа хөкем көнендә.

Үтәр гомер, ишет, синнән вә миннән,
Күзең ач, гыйбрәт ал дөнья хәленнән.

Илаһым, ярлыкар зат бер син инде,
Барча мөэминнәргә ризык бир инде.

КИТАПНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

1 нче баб. Китапның башланышы. Җиде планета. Унике бөреҗ
2 нче баб. Кешенең кадер-кыйммәте
3 нче баб. Телнең сыйфатлары, файдасы һәм зарары
4 нче баб. Китап авторы үз гозерен әйтә
5 нче баб. Үгет-нәсихәт сүзләре
6 нчы баб. Белеп, уку фазыйләтләре турында
7 нче баб. Китап язылу сәбәпләре, авторның картайганлыгы турында
8 нче баб. Әдәб-хаянең бозылганлыгы хакында
9 нчы баб. Китапның башланышы. Көнтугды — гаделлек хакында
10 нчы баб. Айтулдының Көнтугды хозурына килүе
11 нче баб. Айтулдының Көнтугды илбиккә күренүе
13 нче баб. Айтулды илбиккә аның дәүләт икәнлеген әйтә
14 нче баб. Һәм дәүләтнең сыйфатларын вә фазыйләтләрен әйтә
15 нче баб. Һәм дәүләтнең вафасызлыгын сөйли
16 нчы баб. Көнтугды илбик Айтугдыга үзенең кем икәнлеген белдерә
17 нче баб. Көнтугды гаделлек сыйфатын аңдыра
18 нче баб. Айтулдының илбиккә биргән соравы

19 нчы баб. Илбикнең җавабы
20 нче баб. Сөйләп һәм сүзсез торулар бәяны
21 нче баб. Котның узучанлыгы, дәүләтнең вазифасызлыгы турында
22 нче баб. Айтулдының углына нәсыйхәте
23 нче баб. Айтулдының илбиккә нәсыйхәте
24 нче баб. Илбикнең Үгделмешне үз хозурына чакыруы
25 нче баб. Илбикнең Үгделмешкә биргән соравы
26 нчы баб. Үгделмешнең илбиккә биргән җавабы
27 нче баб. Уку рәвеше турында
28 нче баб. Бийләр нинди булырга тиешлеге хакында
29 нчы баб. Вәзирләр нинди булырга тиеш
30 нчы баб. Гаскәр башлыклары нинди булырга тиеш
31 нче баб. Хаҗилар нинди булырга тиеш
32 нче баб. Музыкантлар нинди булырга тиеш
33 нче баб. Илчеләр нинди булырга тиеш
40 нчы баб. Сәркатип нинди булырга тиеш
41 нче баб. Хәзинәче нинди булырга тиеш
42 нче баб. Дәстерханчы нинди булырга тиеш
43 нче баб. Шәрамдар нинди булырга тиеш
44 нче баб. Бийләрнең хезмәткәрләргә мөнәсәбәте вә бурычы хакында
45 нче баб. Илбикнең Үгделмешкә соравы
46 нчы баб. Көнтугдының Уйгырмышка (Узгырмышка) хат җибәрүе
47 нче баб. Үгделмешнең Уйгырмыш янына баруы
48 нче баб. Үгделмешнең Уйгырмыш белән әңгәмәсе
49 нчы баб. Дөньяның фазыйләтләре. Файдасы, зарары хакында
50 нче баб. Дөньяның кимчелекләре, гаепләре
51 нче баб. Фани дөньядан бакыйлыкка ирешү хакында
52 нче баб. Илбик мәктүбенә җавап
53 нче баб. Илбик Үгделмешне икенче тапкыр җибәрүе
54 нче баб. Икенче моназира
55 нче баб. Бийләргә хезмәт итүнең канун, кагыйдәләре
56 нчы баб. Сарайдагы хезмәткәрләр белән мөгамәлә хакында
57 нче баб. Ничек өйләнү һәм угылкыз тәрбиясе хакында
58 нче баб. Рәгыять белән мөгамәлә хакында
59 нчы баб. Мәрәккәгә (түгәрәккә) бару-бармау турында
60 нчы баб. Дәстерхан әдәп кагыйдәләре
61 нче баб. Җыенга чакыру тәртибе
62 нче баб. Фани дөньядан йөз чөереп, бакый дөньяга омтылу хакында
63 нче баб. Гафиллектә яну турында
64 нче баб. Илбик Үгделмешне зыярәт өчен җибәрүе
65 нче баб. Уздырмышның ниһаять Илбик янына килүе
66 нчы баб. Узгырмышның Илбәккә нәсыйхәте
67 нче баб. Ил төзелешенең файдалары хакында
68 нче баб. Үгделмешнең үкенеп тәүбәгә килүе
69 нчы баб. Яхшылыкка яхшылык турында
70 нче баб. Узгырмышның авырып Үгделмешне чакыруы
71 нчы баб. Узгырмышның төше һәм аны юравы
72 нче баб. Үгделмешнең Узгырмышны соңгы тапкыр күрүе
73 нче баб. Фани дөньяга бирелеп гомерне гыйбадәтсез уздыру бәянында
74 нче баб. Гомернең узуы, дусларның җәфасы турында
75 нче баб. Соңгы сүз. Авторның үзүзенә нәсыйхәте*

* Рәхмәти Арат тәрҗемәсендә 82 баб күрсәтелә. Ләкин алар бездәге бабларны бүлгәләүдән килеп чыккан.

БЕРЕНЧЕ БАБ

Бисмилләәһиррахмәәниррахиим.
Тәңре газзә вә җәлләгә мактау.

Илаһ аты илән башлыйм сүземне,
Яралткан ул, кеше иткән үземне.

Төмән мең дан белән мәдхия сансыз
Яралтмыш Тәңрегә, кайсы ки соңсыз.

Ул айны, кояшны, көнне вә төнне
Яралткан, кешене, заман, гомерне.

Теләде — бар итте ул барчасын да,
«Бул!» — дип, булдырды һәрбер
нәрсәсен дә.

Ни булса дөньяда, һәммәсе моңлы,
Моңсыз һәм шәриксез бары тик улдыр.

И, Аллам, Ходаем, Илаһым, Тәңрем!
Синнән үзгәне һич белмәмен мәңге.

Бары синдә — бөек Зат, һәм олуглык,
Үзеңнән үзгә һичкем сиңа тиң юк.

Янәшмәс башка зат синең яныңда,
Вә һәрнәрсәгә баш та син, ахыр да.

Уйлап уйга сыймастыр берлегеңне,
Вә һәр шәйдән олуг өстенлегеңне.

Вә зат булып яшәү мәңгелек синең,
Кем аңлатыр — хөкемсездер хөкемең.

Барын да беләсең, һәр шәйдә хак син,
Күңелемә якын, күзгә ерак син[14].

Вөҗүдең билгеле — ай, көн кебексең,
Ләкин төсең, анык түгел, дәлилсез.

Үзең бернигә дә баглы түгелсең,
Бөтен барлыкны бар иткән үзең син.

Яралтучы син инде һәммә шәйне,
Һәр шәй була-бетә, син генә мәңге.

Яралганнар белә — яралтучы бар,
Ике шаһит берәү-бүтәнне раслар.

Аның охшашы һәм минәзе дә юк,
Аның ниндилеген беләсе дә юк[15].

Йөрми, тормый, белми хәтта йокыны
Охшашы-тиңе юк һәм юк буй-сыны.

Алда-артта, уңда-сулда да түгел,
Аст-өсттә, җир уртасында да түгел.

Фәзаны ул үзе бар иткән, ләкин
«Аның үз урыны юк», дисәң, мөмкин.

Ул серле, әмма ул күңел түрендә.
Аны һәр бизәктә була күрергә.

Яралттың тереклек мең-мең төрлесен:
Дала-тау, диңгез-күл, барча җир өстен.

Зәңгәр күкне бизәп мең-мең йолдызга,
Кара төн ярыр нур бирдең көндезгә.

Очар, йөрер, йөзәр мең җан иясе,
Ризык табып, синең һиммәттә яши,

Идез гарештән та кат-кат җиргәчә
Бар да сиңа мохтаҗ, көндез вә кичә.

И, бәндә, белемгә син ышан, инан,
Вәләкин күңелеңдә булсын чын иман.

Ходай ниндилеген күп тикшеренмә.
Канәгать бул Ходайхак берлегенә.

Аллаһ кайдалыгын да күп сорашма,
«Нигә, ничек», дип тә сүзне озайтма.

И, кодрәтле Иям, моңлы колыңны
Кызган-кичер барча гөнаһлыгымны.

---

[14] Курсив илә язылган юллар нәкъ оригиналдагыча, тик сүзләрнең фонетик йөзе генә борынгыча булган, әлбәттә.
[15] Автор кинәт өченче затка күчә, бераздан тагын беренче затка кайта.

Сыгынам тик сиңа бар өметем дә,
Ярдәм кулыңны суз моңлы көнемдә.

Газиз пәйгамбәрем белән кубаргыл,
Кыямәттә миңа сузсын кулын ул.

Аның дүрт дустына сәламем сансыз,
Барып җитсен алар тиз вә тоткарсыз.

Олы көндә күрсәт йөзен аларның,
Миңа фатиха кыл сүзен аларның.

Вөҗүдеңә лаек сүзләр табалмам,
Үзең генә барсын беләсең, Аллам.

ПӘЙГАМБӘР ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ ТУРЫНДА

Сөекле сәүчене рәхимле Тәңре
Халыкта абруйлы итеп җибәрде.

Кара төндә гүя булды юла ул[16],
Таң аттырып, нурын сипте сиңа ул.

Аның аша хәбәр жибәрде Аллаһ,
Затың шуннан туры юлдадыр, алпар[17].

Туры юл тапты ул ятим калып та,
Фида кылды үзен өммәт-халыкка.

Көнен ашсыз калып, йокламый төнне,
Бүтәннәрне куеп, теләде сине.

Шул азапта төн-көн сине теләде,
Син аны макта һәм сөендер әле.

Тырышты, кайгырды өммәт өчен дип,
Котылсын өммәт һәм рәхәт күрсен дип.

Ата-анадан да нык сөйде илне,
Аллаһның рәхмәтен гел сорар иде.

Ул үзе Аллаһның идезе иде,
Кыланышы гүзәл, холкы төз иде.

Мөгамәләсе гел яхшы күңелдин:
Оят-әдәп белә, юмарт — кулы киң.

Кара җир, зәңгәр күк аны үз итте,
Ходай үзе аңар ярдәмче иде.

Тәүдә башчыларга баш була белде,
Соңра сәүчеләрнең өлкәне булды.

Мин инде багладым күңел аңарга,
Ул әйткәнчә керәм ихлас гамәлгә.

Илаһым, күңлемне яктырт нур белән,
Һәм кубар сөекле пәйгамбәр белән.

Кыямәттә күримче ай йөзен мин,
Вә кул бирүче кыл аның үзен, дим.

ПӘЙГАМБӘРНЕҢ СӘХАБӘЛӘРЕ ТУРЫНДА

Аның дүрт дустына сокланырлык та:
Алар дүрт киңәшче булды берлектә.

Ике кияү аңар, ике каената.
Болар сайланмышлар иде халыктан,

Иң өлкәне Гатикъ[18] исемле иде,
Илаһка чын гашыйк күңелен бирде.

Фида кылды малын, җан-тәнен, көчен
Пәйгамбәребез шатлыгы өчен ул.

Икенчесе — Фарук[19], инсан асылы,
Теле-күңле белән халык-ил колы.

Сәүчегә киңәшче, дин күреклесе,
Шәригатькә ишек ачкан шул үзе.

Аннан ары Госман, әдәпле, ипле,
Кешеләрнең иң-иң юмарты иде.

Фида кылды барча әйберен, үзен,
Сәүче аңар бирде ике яшь кызын.

[16] Юла — факел (бу сүз оригиналда да бар һәм татар сөйләшләрендә дә очрый).
[17] Мондый көтелмәгән эшдәш сүзләр текстта күп тапкырлар очрый. Алпар — рыцарь, батыр егет.
[18] Әбү Бәкер хәлифәнең кушаматы. Бу кушамат Рәхмәти Аратта юк.
[19] Гомәр хәлифәнең кушаматы. Бу кушамат Рәхмәти Аратта юк.

Бу рәттә хәзрәти Гали ахырда.
Беренче ул, ләкин җан һәм акылда.

Вөҗданлы һәм данлы, олы йөрәкле,
Белекле — эшләде ул иң кирәкне.

Болар булды дин һәм сәүче терәге,
Кяфер, монафикъка каршы көрәште.

Бу дүрт минем өчен рухи үрнәктер,
Аларның минәзе җанга терәктер.

Бу затларга миннән сәламнәр сансыз,
Илаһым җиткерсен иде ноксансыз.

Мин аларга шатлык китерсәм иде,
Кыямәт көнендә кул бирсәм иде.

ТАБГАЧ ОЛУГ БУГРА КАРАХАН ӘБА[20] ГАЛИ ХӘСӘН БИНЕ АРЫСЛАНХАНГА БАГЫШЛАУ

Көнчыгыштан исте саба җилләре,
Ачылды дөньяда оҗмах юллары.

Кара җирдә җофар, камфара сипте.
Җирбикә бизәним дип карар итте.

Җиләткән бу кышны сөрде язгы җил,
Якты яз, гүяки, төзде яңа ил.

Кояш та кереште яңа гамәлгә,
Хут ае бетте һәм кердек хәмәлгә[21].

Корыган агачлар яшел төс алды,
Аннары ал, сары, күккә бизәлде.

Яшел ефәк өртте кара җирләрне.
Табгач хан Кытайга аргыш җибәрде[22].

Язы-тау, яр-чокыр җәйрәп җәелде,
Ясатып каш, киенеп аллы-гөлле.

Төмән төрле чәчәк көлеп ачылды,
Җофар җир камфара исенә тулды.

Канәфер исләре саба җилендә,
Далага бөркелә җофар да, кен[23] дә.

Каз-үрдәк[24], кылкойрык, аккошлар инде
Көтүләре белән һаваны иңли.

Тиземдә кайткач кәрвандай ерактан
Горур торна матур җыр яңгырата.

Мөлаем чакыра ишен Улар кош
Күңел бирмешенә дәшә сылу кыз.

Кәкилекләр көлеп сала авазлар,
Бары да каракаш, кызыл авызлар.

Кара чумга борын күтәреп чурлый,
Тавышы — гүяки япь-яшь кыз
җырлый.

Сала сандугач мең өн гөлзарында
Укый гыйбри сүрә көн, төннәрен дә.

Илек, күлмез уйный чәчәкле җирдә,
Сыгун, муйгак чаба-болынны гизә.

Кашын җимерде күк-яше түгелде,
Чәчәкләр көлеште — булды күңелле.

Мине шелтәләде дөнья, бу сүзен
Әйтте: Күрмәдеңме хаканның йөзен?

Әгәр йокласаң, тор һәм ач күзеңне,
Ишет миннән ишетмәгән сүзеңне.

Төмән елдан бирле мескен тол идем,
Тол тунын салдым да, матур киендем.

---

[20] Әба — җәтләре, ата-бабалары (шулар ки).
[21] Хут — 23 февраль — 23 март, хәмәл — 24 март — 23 апрель.
[22] Табгач хан монда — «җирле зур хөкемдар», агыш — «сәүдә кәрваны».
[23] Кен — хуш исле матдә.
[24] Бу сүздән соң күп кенә сүзләр —төрле кош-корт хайван атамалары очрый.
[25] Нәүбәт барабаны — набат (тревога, сигнал) барабаны.

Бизәндем зур хакан булды ханым, дип,
Аның өчен корбан булсын җаным,
дип».

Нәүбәт барабанын[25] болытлар какты,
Яшен яшьни — хакан кылыч уйнатты.

Бу күкрәү — илебезнең даны авазы.
Яшен — көч-кодрәте хаканыбызның.

Дан ул Табгачка, олы Бугра ханга.
Ия булсын ул һәр ике җиһанга[26].

И, дәүләтнең аягы, якчысы илнең,
И, милләтнең таҗы, сакчысы диннең,

Теләгеңне белгән бер Тәңре Хода,
Терәк булсын сиңа моннан соңын да.

И, дөньяның яме, матур олуглык,
Үзең бәхет фәрештәсе булырлык.

Фәләк сайлап сине тәхет җибәрде,
Тәхетле бәхетне сакласын Тәңре.

Галәм бу ханга килеп тукталды,
Бүләк бирде аңар — дөнья таң калды.

Эфирдән[27] киләләр бәхет кошлары —
Йә Һинд раджасы, йә Урум кайсары[28],

Хакан исмен мактап он сала алар,
Шатлык илә фырлап очалар алар.

Бу җирнең мең төрле чәчәк-гөлләре,
Ялан, тау, кырларның яшел келәме

Аңар табынарак хушбуй чәчүдә,
Кайсы шат йөз белән капка ачуда[29],

Кайсы тота аңар хуш ис челемен,
Кайсы пуф-пуф өрә юлларына кен.

Кайсы көнчыгыштан — бүләк китергән,
Кайсы көнбатыштан — хезмәт итәргә.

Бәхет кошы үзе — капу сакчысы,
Аның тәпиендә — бәхет ачкычы.

Дөнья аның өчен эшкә тотынды,
Дошман башын иде, муенын сонды,

Галәмгә таралды хаканның даны,
Вә йокысыз калды барча дошманы.

Иминлеккә илтте төзегән заны,
Шул канун-зан тагын күтәрде данын.

Юмартлык минәзен күрим дигән зат
Күрер — хакан йөзен ипләп караса:

Җафасыз вафалы, котлы бер кеше,
Бары гүзәл — йөзе, йөреш-торышы.

Хәвефсез файдалы хезмәт теләсәң,
Аңар кил — табырсың, сөеп эшләсәң,

Холыклы һәм алчак, рәхимле хуҗа.
Күрим дисәң, кил дә торып кал шунда.

И, холыклы, идез, изгеләргә тиң!
Бу дөньябыз сезсез калмасын ятим.

И, дәүләт иясе, төркиләр коты!
Мең шөкерләр әйтеп, яңрасын атың.

Борынгыдан бирле бер мәкаль килә:
Атаның урыны углына кала.

Дәвамы алдагы саннарда

---

[26] Ягъни дөньялык һәм ахирәт.

[27] Оригиналда — «асир» — турыдан-туры грекчадан гарәп теленә кергән вариант, без бу сүзнең татарча-русча яңгырашын кулландык.

[28] Бу юллар Урта Азия хөкемдарына Һиндстан патшаларыннан һәм Урум-Византия кайсарыннан — императорыннан илчеләр килүен гәүдәләндерсә кирәк.

[29] Капка дип киная белән хәремне әйткәннәр.

ӘДИПЛӘРЕБЕЗ МИРАСЫННАН

КЫЛДАН НӘЗЕК, КЫЛЫЧТАН ҮТКЕН*

Роман

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ

5

Килә бер көн, килеп җитә бер мизгел — синең моңарчы яшәгәнең, шул яшәүдән алган акылың, өйрәнелгән гадәтләрең, күнегелгән арадашларың — һәммәсе кирәксез була да кала! Дөрес, мондый мизгелне кичермичә дә дөньядан кичкән кешеләр байтак, мондый мизгелне аермачык кичереп тә аны сиздермичә генә үткәреп җибәргәннәр дә күп, алар, сүз арасында гына әйткәндәй, «әллә нигә эч пошып тора әле», дип куялар да сүзне кыскарталар. Эч пошуның сәбәбе әллә ниләр булуы мөмкин! Һич көтмәгән кешеләрнең, бер дә уйламаганда җинаять ясап ташлаулары, бик якын кешеләре белән талашып, соң чиккә җитеп, ир белән хатынның аерылышуы, бала белән атаның кан дошманга әйләнүе берчакта да юкка гына булмый. Нindидер күзгә күренмәгән яки күренгән сәбәпләр аркасында кеше үз яшәешендә борылыш ясарга мәҗбүр була. Кискен борылыш, йөз сиксән градуска һәм ныклы борылыш, кеше моннан соң кичәге җан белән яши алмый инде, ул үзгәрә, үзгәләнә — танымаслык хәлгә килә. Мондый чакта адашып калганнар да бар, акыллы гына кешеләрдән әллә нинди ахмак эшләр дә көтәргә мөмкин, чөнки мондый борылыш кешедә тирән рухи үзгәреш тудыра. Без бит үз тирәбездәге кешеләрне аз беләбез, аз кызыксынабыз. Без кешеләрдә үзебез күрергә теләгән, безгә кулай мөнәсәбәтләрне генә күрәбез, асылда без кешенең үзе белән түгел, нәкъ менә безнең өчен кулай булган мөнәсәбәтләре белән генә таныш булабыз. Кешеләр берчакта да ни уйлаганнарын, дөньяга, кешеләргә карата мөнәсәбәтләрен тулаем ачып салмыйлар. Тел фикерен яшерер өчен дипломатларга гына түгел, һәммә кешегә ярдәмгә килә. Без уйларыбызны тышка чыгару түгел, күпвакыт һәм хаклы рәвештә тел ярдәмендә тырышып-тырышып яшерәбез. Әгәр без бер-беребезнең тулаем ни уйлаганын белсәкме?! Яшәүнең бер дә кызыгы һәм мәгънәсе калмас иде. Юлда, трамвай вагонында иң арткы урындыкка утырып Мирзанурның уйлаганы бар: «Менә никадәрле кеше башы... Һәммәсе нидер уйлап бара бит... Уйсыз күңел юк... Уйлар, уйлар... Баш формалары, колак бөтеркәләре, чәчләр, ялган чокырлары бер-берсенә охшамаган... Ә уйлар, бу башлар янәшә утырсалар да, бер-берсеннән бик еракта ич! Кемдер диңгездә, кемдер күктә, кемдер уе белән җир астында...»

Әтисенең үлеме Мирзанур өчен әнә шундый борылыш минуты булды. Тормышның әтиле чактагы өлеше һәм әтисез өлеше булуын ул беренче мәртәбә шунда аңлады. Моңа кадәр дә бу турыда китапларда, караган кинофильмнарда фикерләр чагылып-чагы-

* Ахыры. Башы журналның 7-9 нчы саннарында

лып китә иде, әмма ул аларны бер колактан кертеп, икенчесеннән чыгарып җибәрә дә барган.

Әнисе вафатын ул болай авыр кичермәгән иде әле.

Димәк, ул вакытта тулаем ятим булмаган әле. Дөньяда әтисе калган. Аң белән төшенеп җитмәсә дә, хис, күңел, йөрәк, ниһаять, җан, Мирзанурны тынычландырырлык төп сәбәпне алга куйган: әйе, әниең вафат — зур кайгы!.. Әмма син түгәрәк ятим түгел — әтиең бар. Хак, син аңа мохтаҗ түгел, син үзең семья башы, үзең ата, үз тормышың белән яшисең, алда да атаның кирәклеге сизеләчәк түгел, мәгәр җирдә әтисез һәм әнисез калгач, ул үзендә көтелмәгән, кискен үзгәреш сизде…

Дөнья әлифбасының бөтен хәрефләрен үзләштердем дип йөргәндә генә, тормыш аны яңа киңлекләргә алып чыкты, яңа сукмакларга кертеп җибәрде, яңа мөнәсәбәтләр тудырды. Бу яңа киңлекләрдә, яңа мөнәсәбәтләрдә иске кеше булып калып булмый иде, үзгәрергә, карашларыңны үзгәртергә, яңача яшәү формалары уйлап табарга кирәк иде.

Мең сорауга бер җавабы да әзер булмаган килеш Янык авылына кайтып керде Мирзанур. Урамда очраган беренче кешедән Шәүкәтләрнең өен сорады һәм ачык капка аша өйалдының ачык ишеге янына килеп басты.

Җәй эссе һәм коры булгач, көзе ямьсез, явымлы килер дип юраганнар иде, сентябрь шундый матур, җылы, рәхәт ай булып торды ки, бик күпне күргән аксакаллар да гаҗәпләнде: «Һай бу табигатьне! Күрсәтсә, мәрхәмәте дә киң шул аның!» Октябрь дә уңай килде, коры ел булгач, терлек азыгын такы-токырак әзерләгән хуҗалыклар да куандылар, көннәр коры һәм җылы торды, терлек һаман болында, урман авызларында йөрде. Терлек абзарга кермәгән һәркөн хуҗалыкларга да, колхоз-совхозларга да бәрәкәт китерә иде. Дөрес, авыл хәлләреннән, хуҗалык хәбәрләреннән шактый күптән аерылган Мирзанур мондый нечкәлекләрне аңламый иде, әмма ул самолёт көткәндә күргән авыл кешеләренең дә, районга кайтышлый автобуста очраткан кешеләрнең дә телендә бер куаныч булуын күрде: озак бәхеткә килсен мондый көз! Яман җәйнең эшен рәтләп китә, мал азыгы янга кала, дип сөйләштеләр алар. Сөргән җир өстендә тезелеп утырган ыспай салам эскертләре, ферма тирәләренә китереп өйгән эскерт-кибәннәр аңа да ниндидер бер җиңелчә куаныч, ниндидер билгесез бер сөенеч уяттылар.

Өйалды ишеге ачык булса да, ул шакылдатырга кирәк санады, өйдән кулына чалгы бритва тотып, ярты сакалы кырылган Шәүкәт килеп чыкты.

— Мин сине көтә идем, — диде ул, буш сул кулын сузып. — Саумы?

— Кайттым менә, — диде Мирзанур, ни әйтергә аптырабрак. Ничә сәгатьләр шушы кайту турында уйласа да, аның бер акыллы сүзе дә әзерләнмәгән, уйлары буталчык, күңеле боек иде. Кеше белән очрашуга, мәҗлесләргә Мирзанур берчакта да әзерлексез бармый торган иде. Бүген ул, юаш кына булып, Шәүкәтнең һәр хәрәкәтенә буйсынып, өйгә узды, бәләкәй саквояжын бик күп мендәрләр өелгән карават янына идәнгә куйды һәм хуҗа күрсәткән урынга, дәү гөл чүлмәге янындагы венский урындыкка барып утырды. Шәүкәт кулын тиз-тиз йөртеп кырынды, самовар борыныннан тастымалга шау кайнар су агызып, битен, ияген каплап торды. Тастымал өстеннән аның күзләре күренеп калды һәм Мирзанур аның күз тирәсенә сибелгән җыерчыкларның шактый мул, шактый куе икәненә игътибар итте. Казанда чакта җыерчыклар сизелмәгән иде.

— Утыр, — Шәүкәтнең тавышында өстенлек, боеру яңгырады. — Чәй эчәсеңдер? — Мирзанур, иңбашларын кыймылдатып, хуҗага карады. —

Әллә башта ук үз йортыңны карап киләсеңме?

«Үз йортыңны» мыскыллау булып ишетелде.

— Карыйк булмаса.

Шәүкәт чолан ишегеннән үрелеп бәләкәй балта алды, Мирзанурның сораулы карашына «тәрәзәләр кадакланган ич!» дип аңлатып бирде.

Әтисе өйне яңа нигезгә салган икән, ул Шәүкәтләрдән ерак та булмады, әһ дигәнче барып җиттеләр. Җил капка, такта башлы дүртпочмаклы өй, такта өйалды һәм вак-төяк сарай-сорайдан башка ихатада күз төшәрлек нәрсә юк иде. Шәүкәт аны-моны ачыклап көтеп тормады, күптән хәл ителгән нәрсә кебек, барган шәпкә үк урам як тәрәзәгә кадакланган такталарны каера да башлады. Тавышка күрше йорттан капка шыгырдады, кемдер ачык тәрәзәдән кычкырды: «Кем маташа анда, балачагамы әллә?» Шәүкәт җавап биреп тормастан, икенче тәрәзәгә барып тотынды, балтасы кадакка эләкте, кулына шырпы керде, кан күренде.

— Шулар җитәр, — диде Мирзанур, каерылган такталарны бер урынгарак өеп. — Нишләтәбез инде бу өйне хәзер?

— Теләсәң нишләт, — диде канлы бармагын кулъяулыгы белән төреп Шәүкәт. Кирәк дисәң — сатасың, хуҗа — син.

Башта күңелгә шайтани уй иңде: моннан берәр нәрсә алып китеп булыр микән, дип уйлады Мирзанур. Кызарынып, мондый подлый уйларны түгәргә теләгәндәй, нык итеп башын чайкады. Хуҗа! Һәм, һич көтмәгәндә, Дубровский операсыннан Владимир ариясе искә төште: «Итак, всё кончено, судьбою неумолимой, ты обречён быть сиротою!» Ятим-хуҗа! Йорт та ятим. Хуҗасы да ятим.

Шәүкәт өйгә кереп тормады, ишек катында бераз таптанды да балтасын селки-селки кайтып китте, онытмады — Мирзанурга хәерле төн теләде. Мирзанур аптырап калды: ничек шулай булды әле бу? Аның ашарына да юк, суы да юк, чәй эчәсе килә, тамагы яна. Соңыннан гына аңлады: Шәүкәт аны ялгызын калдырып дөрес эшләгән, уйлап эшләгән. Максаты башта ук шундый булган: калсын берүзе! Уйлансын! Сөйләшәсе дә килмәгәндер. Ни сөйләшергә? Ачулансаң — соң. Үпкәләп, кешене төзәтеп булмый. Берни дә булмаган кебек кыланыр идең, йорт ялгыз, төп хуҗасы әнә генә — кашлактагы борынгы зиратта. Мирзанур Шәүкәтнең ташлап китүен шулай дип аңлады, рәнҗемәде. Унөч-ундүрт яшьлек үсмер кыз йөгерә-йөгерә ике чиләк су кертте:

— Чишмә суы, абый. Курыкмыйча эчегез.

Шул ук кыз бераздан тастымалга төреп ризыклар алып килде. Кыз чыгып киткәч тә, Мирзанур төенне ачарга ашыкмады, бераздан күз күнегә, күңел утыра төшкәч кенә тастымалны чишеп җибәрде. Монда барысы да бар иде: салкын ит тә, коймак та, башланмаган сәйлүн чәе, учы белән шикәр, өчдүрт телем икмәк белән каймак та бар иде. Карыны бик ачса да, ул ашарга ашыкмады, рәттән ике чүмеч су эчте дә ишегалдына чыкты... Әле күз мондагы хәлләрне күңелгә уткәреп җибәрә алырлык түгел, тирә-яктагы бернәрсә дә үз төсендә күренми, күз карашы бер почмактан икенче якка чаба, йөгерә, кабалана. Маңгай чәчен тотып караган иде, Мирзанур куркып китте, манма су, йөрәк ашыгып тибәме әллә?!.

Ул бу көнне беркем янына бармады, берәү дә аның янына кереп карамады, ут та яндырмады, шулай ярым караңгыда ашады, эчте. Дөм караңгыда урынга ятты. Мендәрдән коры тузан исе килә иде, аңа да игътибар итеп тормады. Караңгы бик иртә һәм бик кинәт төште...

Ел коры килгәч, каеннар июль ахырында ук яфракларын, кутәреп торырга күпсенгән сыман, коя башлаганнар иде. Сентябрь яңгырларында аларның тәртибе бөтенләй үзгәреп китте: каен-

нар ямь-яшел килеш ай ахырына кадәр утырдылар диярлек. Октябрь башында каен яфракларына тут төште, алар тоташ саргайдылар, анда да җиргә очарга ашыкмадылар, Мирзанур ай актыгына кайтып керде, юкәләр шәп-шәрә утырсалар да, каеннар әле һаман да сары бөркәнчек ябынган килеш, гаҗәеп матур хәлдә иделәр. Машинада тау астыннан уздылар, кашлак җирләрдә, алданрак яфрак ярып, алданрак шәрәләнә торган каенсарлар да ут капкан төсле җемелдәп-саргаеп утыралар иде. Төнлә җил кузгалды, ул таң алдыннан гына аз-маз черем итеп алды. Йокы тынгысыз, авыр иде, йокыга китүгә төш күреп, бимазаланып, әллә ничә кат бастырылып ятты. Иртән торып тышка чыкса, кичә күзгә сеңеп калган каеннар булды. Алардан ашлык суыргандагы кибәк кебек булып тоташ яфрак агыла иде. Каеннар, көз җиткәнен сизеп, үзләренең һаман яфраклы килеш утыруларыннан оялган төсле, яфракларын җиргә учлап-учлап сибәләр иде. Җил җиргә төшкән яфракларга да тик кенә ятарга ирек бирми, аларны кузгата, биетә, өерләп алып китеп, тәгәрмәч эзләренә, канауларга, чокыр-чакырларга тутыра иде.

Көне буе ишегалдындагы яфраклар белән мәшгуль булды Мирзанур.

Көне буе аның янына беркем дә кереп карамады. Хәзер моның сәбәбе көн кебек ачык, бу, мөгаен, Шәүкәт эше. Ул башкаларга кушкан булырга тиеш. Төшкә кадәр Шәүкәткә ачуы килеп торган иде, төштән соң Мирзанур ялгызлыгына куанды. Әле ярый беркем дә керми аның янына! Чөнки кергән һәрбер кеше сорау... Кергән һәрбер кеше — тикшерү иде. Кичәге кыз шундый ук кызыл тастымалга төреп ризык китерде, бу юлы тастымалда өресе өстен тоташ каплаган шулпа, аерым тәлинкәдә калҗалы ит белән бәрәңге, башка нәрсәләр бар иде. Кыз ризыкларны өстәлгә ашыкмыйча, тәртибен белеп һәм ничектер Мирзанурны олылап тезеп чыкты да:

— Сез фәлән абыйның улымы инде? — дип сорады.

— Син аны беләидеңме?

— Белмичә... Шуның улымы инде сез?

— Әллә охшамаганмы?

Кыз җавап биреп тормады, кызарынды һәм, салмаклыгын онытып, ашыгып-кабаланып чыгып китте. «Менә шундый булсын иде киленең! Ә бит юньсез малай шәһәрнең бер этен алып кайтачак. Килгәнче үк картларны өнәми торган, һәр адымда, һәрнәрсәдә үзен хаклы дип санаучы әнчекне ияртеп керәчәк!»

Алай уйларга әле Мирзанурның сәбәпләре булмаса да, аның яшьтәшләренең күбесе бабай булдылар, очрашсалар, электәгедәй үзләре турында түгел, киленнәр, малайлар, кодалар һәм оныклар турында күбрәк сөйләшәләр. Бабай булуны танып өлгергән чордашлары фикереннән чыгып, Мирзанур да үз улы турында шулайрак фикер йөртә ала иде...

Кыз Мирзанур күңелендә якты эз, шуңа өстәп шөбһәле сорау да калдырып чыгып китте: «Улымы?» — ди... Димәк, фәлән кеше турында аларның төпле, бердәм кабул иткән үз фикерләре бар. Алар фәлән кешенең уллары да, балалары да фәләнчә булырга тиеш дип сүз беркетеп куйганнар инде. Кызга чак кына үпкәлисе килсә дә, торган саен Мирзанур күңелендә ул җылырак урын ала барды. Җылырак урын алган саен килеш-килбәте дә килешле, матур булып тоелды. Ул тагын бер мәртәбә: «Менә шундый килен алып кайтсын иде теге юньсез малай!» — дип кабатлады. Шушы чын теләккә ияреп, тагын шикле уй кабарды: «Чыгармы әле ул синең салам сыйрак малаеңа? «Фәлән кешенең улымы сез?» — дип тора. Ә фәлән кешенең онытымы сез дип сорый алмыймы ул?!»

Фәлән кешенең улларын ничегрәк дип күз алдына китерә икән алар?!

Аңлыйлармы?

Дөрес кабул итәләрме?

Фәлән кешенең оныгы ничек булырга тиеш дип беләләр икән алар?!

Кыз тагын килә калса, бу турыда ныклап сорашырга булып, җае чыкса, улы барлыгын да искәртеп куярга җыенып, Мирзанур кичне җиткерде. Өй эченә күз күнекте, әйберләр дә ничектер үз булып, якын булып тоелдылар. Үзендә тагын бер үзгәрешне сизде Мирзанур. Хатыны моннан өч-дүрт ай элек кенә, кибеттә туры китереп, румыннардан кергән шакмаклы фланель күлмәкләр алып кайткан иде. Өчесе өч төстә, әмма өчесе дә шакмаклы. Ничектер кыенсынып кына кия иде күлмәкләрен Мирзанур Казанда. Монда исә шакмаклы фланель күлмәге үзенә дә ошый башлады. Хәзерге хәлдә, Яныкта, ялгыз ятканда, шушы кер күтәрә торган җылы күлмәктән дә кулай кием юктыр кебек тоелды.

Беренче көнне сары яфрак яуды.

Икенче көнне иртәдән кичкә кадәр күк белән җирне тегәрҗепләр — яңгыр җепләре тоташтырып торды. Нык яуды, сеңдереп яуды. Мирзанур эшенә һәм өенә телеграмма сукты: «Әле генә кайта алмыйм!»

Теләсә ни уйласыннар, теләсә ни әйтсеннәр, соңыннан ничек тә аңлатыр, төшендерә алыр, әлегә Мирзанур бу урыннан аерылырлык хәлдә түгел иде. Теге кыз көнгә өч тапкыр ашарга китереп йөрде, тик яңадан сорау белән Мирзанурның күңеленә кадалмады...

Өченче көн яңгыр тамчылары кар белән аралашып актылар...

Көтү чыкмады.

Дүртенче көн салкын җил исте, суытты, Мирзанур мичкә ягарга мәҗбүр булды. Утынны әтисе якында, өйалдында гына тоткан икән. Коры каен пүләннәренең дөрләп януын карап, ул урындыкта бик озак утырды.

Бишенче көн җир катып, бөтен җиргә тигез генә кырпак төште. Төсләрнең шулай тиз алышына алуына ышанырлык та түгел иде. Башта сары иде авыл, аннары кап-кара булды. Бүген менә ап-ак! Ул болдыр такталарында үзеннән калган чуар эзләрне гаҗәпсенеп карап торды.

Һәм дөнья гаҗәп үзгәреп, бөтенләй танымаслык хәлгә килеп җиткәч кенә, ниһаять, зиратка китте.

Янык зираты авылның көнбатышында, калын кәүсәле тупыллары, дәү-дәү, төп ягын колачларлык каеннары белән әллә кайлардан күренеп тора. Малай чагында Мирзанурның ул зиратка кергәләгәне дә бар, дәү абыйларына кунакка килгәндә, малайлар белән шыпырт кына кереп, киртә янында мәмрәп пешкән җир җиләге ашап чыкканнары да бар... Әй йөгергәннәр иде аннары алар!..

Зират... Әйе, монда аның нәсел-нәсәбе, ул белмәгән, белсә дә онытып бетергән ерак туганнары күмелгән. Монда аның авылдашлары... Монда бик яшьли үлгән аның яшьтәшләре... Менә хәзер ул зиратка бөтенләй башка кеше булып, ятим, үксез булып атасы катына бара. Юлда аңа кемнәрдер очрады, мәктәпкә баручы балалар яныннан узды. Балалар чыр-чу тавышланып киләләр иде, аның белән тигезләшкәч, шым булдылар, адымнарын кызулаттылар, узып киткәч тә борылып-борылып карадылар. «Шулкадәрле куркыныч мыни минем кыяфәт?!» — дип сызланды аның күңеле.

Зират капкасын ачкач, ул бераз тынлыкка колак салып торды. Керде. «Кергәч тә сул кул якка каер, койма буйлап бар. Шунда күрерсең... Биш каен булыр... Шунда атаң».

Шунда...

Аяк астындагы яфраклар келәменә йомшак кар түшәлгән. Ул артына борылып карады, эзе тирән булып ярылып-ярылып ята. Моңарчы игътибар иткәне юк иде: Яныкта беркемнең дә фамилиясен кабер ташына язып куймаганнар икән. «Сабир кызы Фәүзия». Туган елы һәм вафатының вакыты. «Мөхәммәт улы Кәбир». «Мәүҗидә

Сәлмән кызы»... Нигә алай икән? Нигә фамилияләр куелмаган... Димәк, Мирзанур үлсә, «Мирзанур фәлән угылы» дип кенә куячаклар. Ничә еллар аралашмаган кеше — ата исеме белән аның исеме генә янәшә торачак... Кызык... Ул, коймадан читкә китмәскә тырышып, чардуганнарны урап узаузa, зиратның уртасынарак җитте. Бик күп каберләрнең коймалары, агач һәйкәлләре әллә кайчан череп ауган, кабер өстенә утырткан агачлар гына иркенләп колач җәя-җәя үскәннәр...

Ниһаять, койма буендагы биш яшь каен да күренде. Алардан аз гына арырак яңарак кына куелган тимер чардуган һәм эчендә әле ныклап каралып өлгермәгән агач һәйкәл дә күренде. Аның йөрәге кысып куйды... Шушы тәбәнәк кенә таучык астында аңа җан биргән, аны дөньяга чакырып китергән кеше ята. Ата... Әти... Әткәй... Ул әтисенең тимер рәшәткәсенә ике куллап чытырдап ябышты һәм аның күзләреннән кылыч белән кисеп, көчләп чыгарган шикелле кайнар яшьләр тәгәрәп чыкты... Нигәдер ул әтисенең үлеме турында түгел, үзенә дә киләчәк әҗәл турында уйлады. Үзен үлем түшәгендә, ак кәфен эчендә дип күз алдына китерде. Күз яшьләре ныграк актылар, әллә үзен жәлләп, әллә әтисен кызганып, бу минутта аның халәтен аңлап бетерерлек түгел иде.

Озак тормады Мирзанур зиратта.

Әтисенең чардуганын ике мәртәбә урап чыкты. «Һәйбәт таш куйдырырга кирәк булыр! Күренеп торырлык булсын. «Улыңнан соңгы истәлек», дип яздырырга кирәк булыр...»

Истәлекнең соңгысы...

Ә алдагысы кайда?

Бәхет китердеме ул әтисенә? Сөенечен арттырдымы?!

Балаларның һәммәсе дә шулай буладыр инде. Мирзанурның үз улы нинди куаныч китерер икән? Юньләп сөйләшкәннәре дә юк ич аларның. «Синдә нихәлләр?» «Нормально». «Уку ничек бара?» «Нормально». Көненә ничә сорау бирсәң дә, улы бер үк сүз пичәт-факсимиле белән «нормально» дип кенә котылачак бит...

«Юк, болай ярамый! Моңа чик куярга кирәк! Малайны авылга алып кайтырга, көчләп бирәр ай тотарга. Үзең дә аның тирәсендә булырга кирәк. Ничек яши ул? Ни өчен яши?! Мин ясаган хаталарны ул кабатламасын, ичмасам. Мин үлгәч, үкенү газаплары кичермәсен!.. Тик кичерерме ул?.. Кичерер өчен кеше булырга кирәк. Аның улы кешеме? Әгәр шулай икән, аның кешелеге нидән гыйбарәт? Уртак нәрсәбез бармы безнең?»

Авылга кергәнче, кергәч тә, Мирзанур улы турында гына уйлады. Әтисенең кабере аны улы турында уйларга мәҗбүр итте. Ул үзенең улына булган мөнәсәбәтләренә әтисе күзе белән карады. Җентекләп, белергә теләп, аңларга азапланып, әти күзе белән карады. Караган саен үткән гомере түгел, киләчәге кызганыч булып тоелды...

Ишек бикләп йөрми иде Мирзанур, кайтып керсә, аны теге кыз көтеп тора.

— Абый, мин ашарга китердем.

— Рәхмәт, рәхмәт.

— Бирәр нәрсә ашыйсыгыз килмиме?

— Юк, бер әйбер дә кирәкми.

— Алайса ярый.

— Кем кызы соң син?

— Белмисезмени? — Кыз матур итеп кызарынды. — Шәүкәт кызы мин. Балалар бакчасында эшлим. Пединститутта заочница. Чаллыда пединститутның филиалын ачтылар бит. Шунда мин.

— Исемең ничек?

— Исемем Ганҗә.

— Матур исем.

— Матур да, русча яңгырамый.

— Ә син яңгырат!

— Ничек итеп?

— Бер дә исең китмәсен! Минем улым бар... Синнән аз гына өлкәнрәк булыр. Аңа хәзер егерме ике.

— Миңа унтугыз да тулмады әле, абый!

— Хат язар идең син минем улыма!
— Ничек итеп?
— Ничек дип, тотасың да язасың...
— Нәрсә языйм соң мин аңа?
— Яз шунда берәр нәрсә...

Ганҗә артыгын сорашып та, сөйләшеп тә тормады, кичтән алып килгән табак-савытларын тиз-тиз генә җыештырды да саубуллашып чыгып китте. Кичкә таба буран күтәрелде. Авыл бураны белән шәһәр бураны арасында аерма бик зур! Авыл белән шәһәр арасында аермалык бетә дип күпме генә каркылдамасыннар, авыл белән шәһәр бураны арасында аерма мәңге калачак!..

Авыл буранында авыл кешесе давыл белән бер җанга әйләнә. Ул, давылның усаллануын уйлап, әллә ниләр уйлый. Юллар турында да, абзардагы терлек турында да, ягулык-җылылык турында да... Давыл кешене табигать белән берләштерә, аның җанын мәшәкатьләр белән урый, куркыта, уйландыра, йокысын калдыра...

Яңгыр ук Мирзанурның күңелен уйнатып алган иде. Аның, өйалды түшәмендәге баскычтан чормага менеп, такта түбәгә яңгыр шыбырдаганын тыңлап утырасы килгән иде. Бүгенге кичке, төнге давыл, зират өстендә калган эре-эре эзләре, ниһаять, ал битле кыз белән булган мәгънәсез диалог аны уйлар тозагыннан ычкындырмыйлар иде... Ул үзенең авылда үткән гомерен, балачагын, яшьлеген башкаларга сөйләргә дә, хәтеренә төшерергә дә яратмый иде. Чөнки ул чагында бик гади кешеләр белән аралашты, бик гади эшләр белән мәшгуль булды. Шәһәргә аяк басканнан бирле бөтенләй башкача яши башладым дип исәпли һәм шул көннән башлап кына үзен кеше итеп саный иде Мирзанур. Ә хәзер, менә бүген, давыл сызгырганын тыңлап ята-ята, авылда чакта үз гомеренең иң матур, кабатланмас үзенчәлекле еллары булганын хәтерләде. Ул гаҗәп кешеләр белән аралашкан икән, тик аларны бәяли генә белмәгән! Дөрес, яшьлектә очрашкан, аралашкан кешеләр белән гомерне янәшә уздырып булмый, тормышның законнары катгый, аера да, оныттыра да. Әмма Мирзанур яшьлегендә үз күңелен баеткан (әтисе сүзләре!) кешеләрнең язмышы белән берчакта да кызыксынмады, аларның дөньяда барлыгын да онытты... Ә хатирәләр шулхәтле күп икән, аларның берсе дә онытылмаган, кешеләр тере, гаҗәеп кызыклы характерлар булып менә бүген генә аның күз алдыннан уздылар.

Һәм ул тагын шул турыда уйланды...

Улы — Мирзанур авылдан китеп, шәһәр кешесе булган яшьләрдә...

Заман килер, аның да узганнарына кайтып карыйсы килер, мәҗбүр булыр. Тик аның күңелендә нинди хатирәләр калыр? Аның хатирәләрендә Мирзанурга урын булырмы?..

Ә Мирзанурның хәтерендә калганнарга килсәк...

Сез боларын алда күрерсез.

Икенче бүлек

1

Балачакта күңелнең таҗы — бәйрәмнәр...

Керәшен авылына ике яшьтә килеп, шунда үскәнгә, Мирзанурның күңеленә нык сеңеп калганнары — керәшен бәйрәмнәре... Тройсын, Олы көн, Кач ману, Май чабу, Покрау... Боларның һәммәсенең дә үз матурлыгы булган кебек, иң хәтердә калганы Тройсын — авылның үзәк бәйрәме. Тройсынны авыллар тоташ бер атна бәйрәм итәләр. Татар атнасы көнне кунаклар килә башлый, шимбәдә кунаклар су булып агылалар һәм урыс атнасы көнне бәйрәмнең иң ныгы башлана.

(Кызганыч, әлеге урында Аяз Гыйләҗевнең каләме язудан туктый. Әсәр төгәлләнми. — Ред.) ■

ХАТЛАР БУЛЫП КАЛГАН ХАТИРӘЛӘР

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ӘЛЕГЕ САНЫНДА СЕЗНЕҢ ИГЪТИБАРГА РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИННЫҢ БАЛАЧАК ҺӘМ ҮСМЕР ВАКЫТЫНДА ДУСТЫ МӘХМҮТ ХӨСӘЕНГӘ ЯЗГАН ХАТЛАРЫН ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ. КАЗАН АРТЫ ТӨБӘГЕ АВЫЛЛАРЫ ОЛЫ МӘҢГӘР, ЯҢА КЕНӘРДӘ ЯШӘП, ИҖАТ ЭШЕ БЕЛӘН КЫЗЫКСЫНГАН, ЯШЬТӘШЛӘРЕ БЕЛӘН ИҖАДИ ДУСЛЫК, ФИКЕР АЛЫШУГА ОМТЫЛГАН БУЛАЧАК ПРОЗАИК РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИНГА НИБАРЫ 14 ЯШЬ БУЛА. КАЗАХСТАНДА ТУЫП ҮСКӘН БУЛАЧАК ШАГЫЙРЬГӘ — 15 ЯШЬ.

1938-1941 ЕЛЛАРДА ЯЗЫЛГАН ХАТЛАРДАН БУЛАЧАК ӘДИПЛӘРНЕҢ ЯЗУЧЫЛЫК ҺӨНӘРЕНӘ ИҖАДИ ОРЛЫК САЛЫНУЫ, МАТУРЛЫКНЫ КҮРЕРГӘ ӨЙРӘНҮЕ, СҮЗЛӘРЕН ХАЛЫККА ҖИТКЕРЕРГӘ ОМТЫЛУ ТЕЛӘГЕ КӨЧЛЕ СИЗЕЛӘ.

РЕДАКЦИЯДӘН

МӘХМҮТ ХӨСӘЕННЕҢ ХАТЫ

Рафаил дус!

Архивтан Синең хатларыңны эзләп таптым — 6 хат. Хәрефен-хәрефкә күчереп, үзеңә җибәрәм — укып рәхәтлән. Кечкенә генә рәсемең дә бар — бик тонык. Хатка салып җибәргән «Чәчкә» һәм «Беренче кар» исемле ике хикәяң дә саклана миндә. Алары үзеңдә дә бардыр, күчереп тормадым.

Нигә миңа бер дә хат язмыйсың? Алай ярамый. Минем «Сайланма» җыентык чыгып килә. Үземнең 2 кульязмам калды редакциялисе. Аннан 1973 елның планы тулысынча үтәлә. Аннан юбилей мәшәкате килеп җитәр.


Рафаил дус!
Архивтан Синең хатларыңны
эзләп таптым — 6 хат.
Хәрефен-хәрефкә күчереп
үзеңә җибәрәм — укып рә-
хәтлән. Кечкенә генә
рәсемең дә бар — бик тонык.
Хатка салып җибәргән
"Чәчкә" һәм "Беренче кар"
исемле ике хикәяң дә сак-
лана миндә. Алары үзең-
дә дә ... күчереп
тормадым
...
Үземнең 2 кульязмам
калды редакциялисе. Аннан
1973 елның планы, тулысынча
үтәлә. Аннан юбилей
мәшәкате килеп җитәр.
Хатларыңны алуың ту-
рында обязательно хәбәр ит,
юкса мин борчылып
торам.
Егетләрчә сәлам.
Мәхмүт
24 II 73
Казан

Хатларыңны алуың турында обязательно хәбәр ит, юкса мин борчылып торам.

Егетләрчә сәлам.
Мәхмүт.
24.02.73 ел
Казан

Олы Мәңгәр авылы. Сулдан беренче – Рафаил Төхфәтуллин. 1938 ел

МӘХМҮТ ХӨСӘЕН ҖИБӘРГӘН ХАТЛАР

Беренче хат

Кадерле Мәхмүт!

Бу хатны мин сиңа Татарстан Республикасы Әтнә районы Олы Мәңгәр авылыннан язам.

Мин әле генә «Яшь Ленинчы» газетасыннан синең Госманга язган хатыңны укыдым, һәм мине тирән уй чолгап алды: «Чыннан да, мин әйтәм, башка өлкәләрдәге укучылар һәм пионерлар белән элемтә тоту нинди яхшы эш ул».

Һәм мин сиңа хат язарга утырдым.

Бераз гына үзем хакында сөйлим.

Шулай, югарыда әйткәнчә, мин Олы Мәңгәр урта мәктәбенең 7 нче классында укыйм, 2 нче чирекне «отлично» билгеләренә генә тәмамладым. Мәктәптә отряд советы председателе булып эшлим. «Яшь Ленинчы» газетасына язышам. (Бәлки газета битләрендә күргәнсездәдер.) Шулай ук әдәбият белән дә бик нык кызыксынам.

Мәхмүт!

Бу хатны алгач та, миңа хат яз. Һәм без туктаусыз язышып торыйк. Бу сиңа да, миңа да бик тә күңелле булачак. Миңа үзеңнең фотокарточкаңны һәм Казахстан күренешләрен җибәр, һәм мин дә шулай эшләрмен.

Без аерылмас дуслар булыйк.

Аннан соң шуны да әйтим: күбрәк «Яшь Ленинчы» газетасы аша да язышыйк. Безнең дуслыкны бөтен ил белсен. Әйеме? Шулай ук миңа үзеңнең язган шигырьләреңне җибәр, ә мин сиңа үземнең хикәяләремне җибәрермен. Мин күбрәк хикәя язарга яратам. Һәм без хат аша бер-беребезнең әсәрләре хакында үз фикерләребезне әйтербез, эш тәҗрибәләребезне уртаклашырбыз, моның файдасы бик зур булачак.

Безнең Татарстанда хәзер елның иң матур вакытлары. Май ае — ул безнең иң матур аебыз.

Мин иң матур айлы кичләрдә тышка чыгып утырырга яратам.

Ай акрын гына күктә күзләп йөри. Агачлар искән җил белән акрын гына шаулашалар, нәрсәдер сөйләшәләр. Бөтен нәрсә тын гына йокымсырый кебек. Тын. Яшьләрнең шат авазлары инде ишетелми. Алар киноларга һәм болыннарга китеп беткәннәр һәм менә шулвакыт инде мине уйлар томаны чолгап ала. Мин уйларым белән әллә кайларга барам, әллә кемнәр белән сөйләшәм.

Шулай, дустым, без туктаусыз хат язышып торыйк.

Хатларны мөмкин кадәр ешрак язарга тырыш. Киләсе хатыңда ук миңа үзеңнең тулы адресыңны җибәр. Зарыгып хат көтеп калам. Хуш!

Пионерларча сәлам белән
Рафаил Төхфәтуллин.
Май, 1938 ел

Икенче хат

Мәхмүт дускай!

Күптән инде сиңа бер хат салган идем. Шулай ук синең үтенечең буенча 3 данә «Пионер каләме» дә җибәрдем. Ләкин шулай да әлегә кадәр алганым юк. Сиңа моның өчен бик нык үпкәлим.

«Артек»та ял итеп кайттың, Кырымның искиткеч һавасын суладың, гүзәл Кара диңгезнең суларында коендың, никадәр күп нәрсәләр күреп кайттың, никадәр бәхет һәм шатлык сиңа! Ләкин нигә инде шуларны дустың белән уртаклашмаска! Мине бөтенләй оныттың. Үзеңнән түбәннәр белән язышасың килми, ахыры! Комсомолга бер дә килешми инде бу!

Үземә килсәк, хәзер минем адрес үзгәрде. Шушы елның сентябрендә Татарстан Республикасының Кызыл-Юл районы Яңа Кенәр авылына күчеп килдек. Авыл яхшы гына. Кызыл-Юл районының үзәге. Үзендә урта мәктәп тә бар. Библиотекасында китап бик күп. Бусы минем өчен бик яхшы!

Авыл шактый матур урында урнашкан. Якында гына урман бар. (Яратам да соң урманны!)

Мин дә хәзер комсомолга кердем. Үзебезнең класс газетасының редакторы булып эшлим. 1 нче чирекне уңышлы тәмамладым.

Сиңа үземнең «Чәчкә» исемле лирик хикәямне җибәрәм. Хикәям турында үзеңнең тәнкыйди карашыңны язып җибәр. Обязательно җибәр. Онытма!

Ярый хуш!

Минем адрес: Тат. Республика, дер. П/о Нов.-Кинер.



Рафаил Төхфәтуллинның егет чагы

Кзыл-Юлский р-н ср. школа.

Хат көтеп калам.

Сәлам белән
Рафаил Төхфәтуллин
10.12.39 ел

Өченче хат

Мәхмүт иптәш!

Хатыңны алдым. Әйе, минем үпкәләвем урынсызрак булган икән шул, гафу ит инде.

Ул менә ничек булды: үземнең беренче хатыма җавап алгач та, сиңа озын итеп хат яздым, шулай ук син сораган журналларны һәм бер карточкамны да җибәргән идем. Ләкин алар, күрәсең, тапшырылмаганнар. Ә мин бик озак җавап көттем, көттем, ниһаять, чыдамадым, сиңа азрак үпкәләп хат салдым. (Ләкин бу син уйлаганча ук бәла ягу түгел, ә болай гына, дусларча үпкәләү генә иде.)

Я, әйдә ярар, килешик һәм бу аңлашылмауны тизрәк онытыйк.

Шулай, мин теге хатымда язганымча, яңа урынга күчеп килдек. Хәзер инде яхшы гына ияләштем. Тыныч кына укып ятам. Комсомол сафына кердем. «Пионерская правда» ачкан «Разведчики» уенына катнашам.

Мәхмүт!

Мин сиңа берничә сорау бирәм (мин моны тапшырылмаган хатымда да язган идем):

1. Синең Казахстанның халык акыны Җамбулны күргәнең бармы? Булса, очрашу истәлегеңне яз.

2. Син кайчан яза башладың, беренче шигырең басылдымы?

Хуш!

Ком.сәлам белән Р.Төхфәтуллин

Син миңа һәрвакыт Сез дип мөрәҗәгать итәсең. Болай итмә, әдусларча «син» дип кенә әйт. Якын дуслар һәрвакыт шулай итәләр бит.

Хат көтәм.

25.12.39 ел

Дүртенче хат

Мәхмүт дус!

Синең 25/11-ндә язган хатыңны алдым. Минем «Артек» турындагы сорауларыма тулы җаваплар язгансың, рәхмәт!

Син «Пионер каләме»нең 12 нче номерын сорагансың икән. Ләкин моны таба алмадым. Чөнки үземә бу номер килмәде, подпискам тулган иде.

Мәхмүт! Миңа үзеңнең бер иң яхшы шигыреңне җибәр әле! Мин аны дуслыгыбызның истәлеге итеп күңелгә бикләрмен һәм үзебезнең мәктәптә үткәрелә торган әдәби кичәләрдә укырмын!

Аннан соң үзеңнең язылган, язылачак һәм языла торган әсәрләрең турында миңа яз!

Укуыңда һәм эшеңдә уңышлар теләп, сәлам белән
Рафаил Төхфәтуллин
6.03.40 ел.

Кымбатты җолдасым, коч бол!

Бишенче хат

Мәхмүт дус!

Сиңа кайнар сәлам җибәрәм һәм күңелле ял теләп калам.

Үзем 8 нче классны «отлично» һәм «яхшы» билгеләренә тәмамлап, 9 нчы класска күчтем. Хәзер яхшы гына ял итәм. Су коенам, физкультура белән шөгыльләнәм, кояш нурларыннан файдаланам. Кичләрен тәмле хыялларга бирелеп, ярыша-ярыша кычкырышкан балалар тавышын тыңлый-тыңлый, үзендә яр буеның матур күренешләрен чагылдырган тыныч су өстенә карап, бик озак яр буенда утырам; офыкны алсуландырып баеп барган кояш нурларын кул болгап озатып калам. Хушисле чәчәкләр исен иснәп, җырчы кошларның шат җырларын тыңлап, акрын гына бакча буйлап атлыйм. Кешеләрнең эчке характерын, үзенчәлекләрен табарга тырышып, аларның эчләренә керердәй булып карап узам. Аларның сөйләшүләренә колак салып, базарларда тулганам. Үз яныма малайларны, иптәшләремне җыеп, урманнарга, болыннарга чыгам. Әбиләрне-бабайларны әкият сөйләтеп алҗытып бетерәм. Менә боларның барсын да түкми-чәчми көндәлегемә яза барам. Фольклор материалларын аерым, ишеткән кызыклы фразаларны, сүзләрне, вакыйгаларны аерым дәфтәргә язам. Шулай итеп хикәяләрем килеп чыга. Шушы арада «Фәйзүк» (хикәя), «Вәли белән Гали» (фельетон) исемле нәрсәләрне яздым. Һәм «Костёр янындагы хикәяләр» исемле хикәяләр циклы өстендә эшли башладым. Моның инде «Васыять», «Инженер хикәясе» исемле бүлекләре язылды да.

«Яшь ленинчы»да минем «Әнәснең теше» һәм «Беренче көн» исемле әйберләрем басылып чыкты. Укыгансыңдыр.

Мин Ю.Твердин (Куйбышев), Фатыйх Хөсни (Казан), Н.Баязитов, М.Галеевләр (Олы-Мәңгәр) белән язышам.

Миңа 16 яшь.

Хат көтеп,
Рафаил Төхфәтуллин
15.06.40 ел

Алтынчы хат

Мәхмүт иптәш!

Син инде, әлбәттә, миңа бик каты ачуланасыңдыр. Гафу ит... Синең үтенечеңне (П.К., №12) үти алмавым оятыннан, буш вәгъдәләр белән генә хат язарга теләмичә, мин язышуыбызны туктатып торган идем. «П.К.»не соратып, барлык иптәшләремә хат яздым. Ләкин ...үч иткәндәй, барсы да, төрле сәбәп табып, кире язалар. (Алар белән ачуланышып та беттем.) Шулай да Азнакай урта мәктәбе укучысы С.Фәйзиев, шактый тырышып эзләп тә таба алмагач, «П.К.» редакциясенә хат язып, аннан синең шигыреңнең күчермәсен алып, миңа җибәрде. Бу күчермә, әлбәттә, сине канәгатьләндерә алмаса да, синең үтенечеңне ничек тә үтәргә тырышуымны күрсәтү өчен, аны сиңа җибәрәм. Киләчәктә «П.К.» журналының үзен дә ничек тә җибәрергә тырышырмын.

Үзем таза-сау. Хисләремдә — давыл, уйларымда — өермә, йөрәгемдә — Идел ташкыны... Шулай да мин хәзерге тормышым белән һич, һич канәгать түгел. Күңелем нәрсәдер эзләнә... Күңелсез мәктәп тормышы (Әйе, Яңа Кенәр мәктәбе минем өчен бик, бик күңелсез. Сәбәпләрен, теләсәң, киләсе хатымда язармын.), өемдәге эчпошыргыч обстановка, эч серләреңне, киләчәк планнарыңны уртаклашырлык чын дустым (Рәфкать Бикчәнтәй (Казан), аның турында да киләсе хатымда язармын) янымда булмау — вакыты белән минем өермәле хисләремне җиңеп, күңел төшенкелегенә бирелергә мәҗбүр иткәлиләр. Ирексездән кешеләрдән читләшеп, ялгызым уйланып утырам... Күңелем еракка, еракка китә. Уйларым ташкалага, Кремльгә барып тотлашалар да тагын уйларымда давыл, йөрәгемдә көчле ташкын башлана... Бу кичерешләрне язып аңлату читен.

Бу арада әдәби иҗат белән шөгыльләнүне дә туктаттым. Социализм чорының социалистик реализм методы белән үлмәс әсәрләр тудыру дәрте аркасында туган, башымдагы мең төрле тормыш сорауларыма җавап биреп бетерми торып, мин яңадан әдәбият мәйданына килмиячәкмен. Ләкин мин, бу сорауларга җавап табып, әдәбиятка, үз сукмагымны салып, үз иҗат җимешләрем — йөрәкләрдә көрәш, оптимизм дәрте тудыра торган әсәр белән килермен. Моның өчен, бәлки, ярты, бөтен гомерем дә китәр. Ләкин мин үз теләгемә ирешермен, ирешермен!

Быелгы җәйге каникул вакытымны авылда, табигать кочагында үткәрдем. Рәхәт урман һавасын суладым, кояшта кызындым. Әдәбият белән дә мавыктым. Кайбер әсәрләрем матбугатта да чыкты. Зурраклары: «Чәчкә» («Яшь ленинчы»), «Наиль дус» («Пионер каләме»), «Шәриповның борылырга да вакыты юк» (фельетон, «Яшь сталинчы»). Шулай ук республика күләмендәге үзешчәнлек олимпиадасына катнашып, библиотека белән бүләкләндем. «Яшь ленинчы», «Яшь сталинчы» газеталары шушы уңай белән үз битләрендә бу беренче тәҗрибәләрем турында язып та үттеләр.

Дускай! Минем берәр әсәремне газетада очратмадыңмы? Алар турында үз фикереңне яз! Чөнки мин яңа көч белән яңадан әдәбиятка кайтырга җиткән вакытта, бу беренче шат балалыгым тәҗрибәләре турында үземнең һәм иптәшләремнең карашларын ныгытып калдырырга телим.

Үзеңдә нихәлләр? Укуың ничек бара? Нинди яңа әсәрләр яздың? һ.б.

Хуш!

Ком.сәлам белән
Рафаил Төхфәтуллин
Тат.АССР, Кзыл Юльский р-н,
дер. Новый-Кинер, СШ.
Тухватуллину Рафаэлю,
2.04.1941 ел

Хатларны басмага
Р.Төхфәтуллинның улы
***Рөстәм Төхфәтуллин** әзерләде.*

РӘШИД РӘШИДОВ

АЙДАР ХӘЛИМ,
язучы, шагыйрь, публицист,
Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты

I.

Шалтыраттылар.

Мөхәммәттер.

Кайчандыр урта катламның дачалар авылы, аннан Мәскәү-Идел каналы төзүчеләре өчен ашык-пошык корыштырылган һәм онытылган бараклар бистәсе, аннан индустриализация чорында хәрби заводлар шәһәренә әверелеп, бүген — Мәскәүнең эчендә калган Химкида яшәп яткан туксан дүрт яшьлек карт чәй касәсеннән күтәрелде, каткан буыннарын иске бишек сиртмәсе шикелле шыңгырдатып, телефон янына сөйрәлде һәм колакчынны күтәрде:

— Тыңлыйм...

— Рәшид әбзи...

Шул, Мөхәммәт. Иптәш бик дулкынланган иде.

— Рәшид әбзи, бүген... көндез уникедә... Ореховода... теге һәйкәлне ачалар... — Чыбыкның аргы очындагы җиңелчә, үзенчә нәфис мишәр сөйләме шундук үкенечен белгертте. — Син килә алмассың инде... Шылаймы?

Әмма кая ди картка үкенү? Ул гомерендә булмаган дәһшәт белән елмаеп җибәрде. Киресенчә, яшәреп, күзләре ачылып киткәндәй булды. Әле генә озын арбаны хәтерләткән арык гәүдәсе гайрәт белән тулышты, яшь мускул утырды, тамырлары яңа кан белән тулышып, гүя борыны өстендәге куе калын кашлары ике якка канат булып киерелде — һәм ул очыштагы лачынга әйләнде. Гади генә яңгыраган «һәйкәл» дигән сүздән кукрәгендә кайнаган горурлыгын яшерергә тырышып, ерык авызын җыйды һәм, керфекләренә саркып чыккан яшьләрен кул сырты белән ышырып, гадәтенчә, кырыс кына эндәште:

— Мондый көннәрне дә күрәсе бар икән!.. Ниһаять!.. Без — фәкыйрь, әмма мескен түгел!.. Мин... Миңа нәрсә?.. Мин, реактив очкычта очыртсагыз да... — Шатлыклы хәбәрдән буынсыз ук калган карт телефонын тоткан килеш басып торуын дәвам итте. — Сез үзегез катнашырга тырышыгыз инде, малайлар... Мәтри, минем исемнән дә берәр чәчкә салырга онытмагыз... Соңыннан бәйнә-бәйнә сөйләрсез...

«Малайлар» дигәне Мәскәү татар җәмгыяте егетләре була инде. Мөхәммәт исә аларның алтын бәрабәрендәге җитәкчеләре буладыр. Ул аны менә кырык еллап якыннан белә. Заманында бергәләп Измаил паркында атна саен татар «пятачоклары», Казаннан үз кесәләре исәбенә кунаклар чакырып, ел саен атсыз-көрәшсез, кем әйтмешли, «кысыр» сабантуйлар үткәрделәр, СССР Тышкы эшләр министрлыгы карамагыннан Әсәдулла баба йортын милләткә кайтара алдылар, Мәскәү оппозициясе арасына кысылып, телнемәктәпне яклап, дистәләгән пикетларда катнаштылар. Һи-и-и, искә алып, сөйләп бетерерлекме?!

Бер уйлап карасаң, нинди бәхетле кеше ул!.. Әтисе, Хәлим мулла, 94тә, әнисе, әтисенең өченче хатыны Гайшәбикә, 95тә үлделәр. Гомерләренең соңгы көннәрендә алар икесе ике сәкегә утырып:

Р.Рәшидов һәм А.Хәлим. Мәскәү. Химки. 2012 ел

Шатланыр идем, атнакич үлсәм,
Җомга көнендә гүрләргә керсәм, —
дип мөнәҗәт әйттеләр.

Һәм әйткәннәре кабул да булды: атнакич Газраил фәрештә җаннарын алып, җомга намазы алдыннан кабергә дә куелдылар.

Ул үзе дә 95кә җитеп бара. Һаман үлә алмый. Дөресе, үләргә теләми. Үләргә теләмәгәч, яши. Дөрес яши. Дөрес яшәгәч, Аллаһы Тәгалә үзе яшәтә, янына алырга ашыкмый. Ватан сугышы чорында япон самурайлары чигеннән Сталинград фронтына барганда аякларын туңдырып, янбалит калса да, аны «Хезмәт ветераны» статусыннан «Ватан сугышында катнашучы» итеп күптән түгел генә таныдылар. Ул үзе иске, кенәгәсе генә яңа иде. Әмма һаман да исән. Коммунистлар Белая Вежа урманында Союзны тараткач, җитмеш бер яшендә билетын тапшырды. Әле бишалты ел элек кенә аны «Бердәм Россия» партиясенә керергә кодалап килделәр. Аларга Рәшид Рәшидов кебек «алтын башлы картлар» кирәк икән. Ишек тупсасыннан да үткәрмәде. «Йөрмәгез әле бугашап, — диде. — Әнә, башта миллиардерларыгызны чыгарып, кительлехром итектә илне атом бомбалы итеп киткән босяк Сталинны алыгыз...»

Рәшид ага кире урынына килеп утырды. Буыннары шыгырдамый иде инде. Чынаягын үзенәрәк шудырды һәм суынуыннан өстенә көмеш алкалы тут калкып чыга башлаган чәенә караш ташлады. Чәе өстендә шама йөзә иде. «Кунак киләчәк, — дип нәтиҗә ясады. — Борынгы болгар бабаларыбызда шундый юрама булган». Бәй, киләсе кунак килгән бит инде, дип үзен-үзе төзәтте ул. Мөхәммәт энекәше бу күптән көтелгән кунакның, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты, аның турыдан-туры якташы, дөньякүләм бөек шагыйрь һәм дөньякүләм сирәк җәмәгать эшлеклесе Муса Җәлилнең килүе, дөресрәге, аның үзе сугышка киткән Мәскәвенә мәңгелеккә һәйкәл булып кайтуы турында ярсып-ярсып хәбәр итте түгелме?! Мәңгелеккә микән? Рәсәйдә сусыл кыярга, Казан ятимнәренә, ата ялкау Обломовның диванына, сыра көрәгәсенә, аракы чәркәсенә һәйкәлләр куелган, ә менә 1921 елда Рәсәй халкын, аеруча Идел-Урал татарларын ачлыктан коткарган АКШның сәүдә министры Герберт Кларкка, галим Фритьоф Нансенга, үзенең «Маобит дәфтәре» кебек үлемсез шигырьләре белән герман рейхын гына түгел, барлык дөньяны тетрәткән Муса Җәлилгә әлегә куелмаган...

Тукта, иптәш Рәшид Рәшидов, нимескә әсиргә төшкән татарларның, шул исәптән «сатлык җан» исеме чәпәлеп, әсәрләре китаплардан алып ыргытылган Җәлил абзаңның истәлеген газиз туган иленә кире кайтару өчен беренче адымнарны кайчан ясадың әле син? Әле партиянең 1952 ел октябрендә Иосиф Сталин катнашында үткән XIX съездыннан соң, ВКП(б) Үзәк Комитетының иң яшь секретаре — идеолог Михаил Сусловка хат языпмы? Үзәк Комитетның бүлек мөдире Брылин дигән кеше үзенә чакыртып: «Бу нәрсә сезгә нигә кирәк?» — дип бик каты эшкәрткән иде. Тукта, бу ниткән «беренче адым»? Шулкадәр дә каһарманлык кирәк булды микәнни сиңа милли шагыйрегезне яклап ясалган шушы кечкенә адымыгызны һавалы «беренче адым»нар дип атау өчен? Нәрсә, шушы гади генә гамәлне башкару өчен дә сиңа пулемёт амбразурасына капланулга тиң батырлык кылу кирәк идемени? Ул, интернациональ каһарман Җәлил, шул ук Рәсәй Федерациясе гражданины түгелмени? Нәрсә, газиз туган илнең шушы газиз туфрагында яратылган, шушы газиз илнең газиз суларын эчеп үскән, аның газиз һавасында, гөл-газизә рәшәсендә, иген бөртегендә тоз булып эрегән Хәтер — Кеше Хәтерен туган җиренә кайтару шулкадәр әрнүле көрәшләр, сабырсыз елаш-ыңгырашлар, җир тырнап үкереш-үкенүләр аша гына мөмкин булган микәнни? Кайда, кайсы илдә, тагын кайсы кыйтгада бар икән мондый мәгънәсез «көрәш»?!

Хәтерендә, «Бу сезгә нигә кирәк?» дип сорау биргән Үзәк Комитет функционеры Брылин белән бәхәсләшеп тә киттеләр.

— Татар телен җир йөзендә иң мәгънәле, логик яктан төгәл һәм иң бай телләрнең берсе буларак саклау өчен кирәк, — дип җавап бирде үзенең кайда утырганлыгын онытып җибәргән Рәшидов.

— Нигә, татар теленә куркыныч яныймыни?

— Яный. Һәм бик зур.

— Ничек итеп?

— Мәктәпләрне ябып. Күп инде алар. Сөйләп китсәң, көн җитмәс.

— Һм. Ә менә татар теленең иң мәгънәле һәм логик яктан камил икәнлеген ничек исбат итәрсез?

— Рус теле белән чагыштырып.

— Кы-зы-ык!.. Мәсәлән?

— Мәсәлән, һун-татарлар Азиядән Европага ат, арба, тәгәрмәч алып килде. Моны бар кешелек тарихы таный. Менә арба сүзен алыйк. Ул татарча да, русча да арба. Ни өчен шулай? Татар сүзе булганы өчен. Ә бу ничек исбатлана? Бик гади итеп. Ул ике өлештән тора. Ары+бара. Арба — «ары бара». Русча мәгънәсе «дальше идёт». Икенче төрле — «телега». Нәрсә ул «телега»? Тагын. Печелгән атка татар алаша, ди. Рус аны алашадан «лошадь» дип кенә үзенеке иткән. Татар теленең логик камиллегенә тагын бер мисал. Татарда «ашказаны» дигән атама бар. Русчага тәрҗемә иткәндә — «котёл, где варится пища». Руста ул «желудок» дип йөртелә. Сез, белүемчә, филология фәннәре кандидаты, «желудок» дип тамыры «жёлудь»тән алынган һәм бу урында мәгънәсез сүзнең кеше организмындагы бик төгәл әйтелгән «аш кайнаган казанга» катнашы бармы? Һәм шул ук рус татарны «корсагы өчен иманын саткан кеше» мәгънәсендә «желудок» дип кимсетә... Ни өчен?

— Сез шикаять язу остасы гына түгел, сез... өстәвенә милләтче дә икәнсез әле!.. — диде йөзе чалшайган Брылин әңгәмәсен тәмамлап. — Безгә бу темага башка сөйләшергә туры килмәс дип уйлыйм!.. Хушыгыз!..

Беренче тапкыр Муса Җәлил исеме, аны инде үз илебездә каршылаган «әсирлек коллыгыннан коткару» уе белән кайчан шулай тилерә башлады ул?! Хәзер анык кына хәтерендә дә юк. Дөрес, бу исем аңа әле сугышка кадәр дә ярыйсы ук таныш

иде. Әүвәлдә гарәп, аннан латин, аннан кирилл язмасында ул аның кайбер шигырьләрен укыштырган, хәтта кайберләре үзләреннән-үзләре ятланган да иде. Ә менә әсирлектә һәлак булуы, дошман зинданыннан исән кайткан «Моабит дәфтәре» дигән шигырьләр бәйләме турындагы беренче хәбәрне ул Константин Симоновның «Литературная газета»да басылган мәкаләсеннән укып белгән иде бугай. Язучыны очрату, аңардан Җәлил турында тагын да күбрәк белү хыялы белән хыялланып, күп тапкырлар редакциядә дә булды. Йөри торгач, Константин Симонов аны берничә генә минутка кабул да итте. «Җәлил — зур халыкның зур шагыйре, — дигәне хәтердә Симоновның «р» авазында сакаулап. — Зур шагыйрьне халыкка кайтару өчен зур көрәш башлана гына. Татар-малай, ярдәм сездән дә кирәк...»

Менә шунда уянды ул. Башына суктылармыни!..

Суык чәй өстендә гүя истәлекләрнең үзе булып кара шама йөзә иде...

II.

Шулай да, ныклап, тирәннән аңлап кайчан кергән иде ул Муса Җәлилгә бирелергә тиешле ихтирам өчен тигезсез көрәшкә?

1966 елда булган икән! Бүген инде 2012 ел. Кырык алты ел. Үткән гомерләр!..

Бәлки мәсьәләне болайрак куярга кирәктер: нигә бу көрәшкә ул кергән, башка түгел? Нәрсә ул, ничек ярала ул адәм баласындагы холык? Характер? Кайдан килә? Җирдәнме, җилдәнме? Уйданмы, суданмы? Каннанмы, җаннанмы?

Әйе, Җәлил өчен утка кергән көнне сәгатенә кадәр хәтерли.

Шагыйрьнең тууына алтмыш ел тулган 2 февральнең кичке җиделәре иде. Ул, Химки бистәсенең, югарыга хатлар яза-яза, йөзләгән барак-хибараларын сүттереп, алар урынында төзелеп яткан йортлар идарәсе мөдире, 301 нче авиация заводының генераль директоры, атаклы авиаконструктор Семён Лавочкин кулыннан партия билеты алган коммунист Рәшид Рәшидов, ул көнне Смоленски өлкәсенең Пржевальский исемендәге «Сосновый Бор» ял йортында сәйранда иде. Аларга Мәскәүдән концерт килде. Алып баручы 700 тамашачыга Лариса Макарова дигән сүз остасының Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең 60 еллык юбилее уңаеннан шигырьләрен укыячагын игълан итеп тә өлгермәде, уртадагы рәтләрнең берсеннән мал кишере кебек бер аксылсары йөзле бәндә торып басты һәм:

— Кемгә кул чабып утырганыгызны беләсезме?! Ул бит — татар!.. Җитмәсә — сатлыкҗан!.. — дип кычкырды һәм залны ерткыч акула кебек урталай ярып чыгып та китте.

Ул үзе артыннан башкалар да иярер дип уйлагандыр, күрәсең. Шөкер, беркем дә чыкмады. Ә менә Рәшиднең ул кешенең артыннан бик тә чыгасы һәм ирләрчә тәпәләп аласы килгән булса да, илтифат саклап чыкмый калды. Ул моңа бүген дә үкенә. Бәлки кирәкмәгәндер дә? Мондый вакыйгадан соң уңайсызланып агарынган актрисаның йөзенә сүлпән алсулык кайтты, ул шагыйрь әсәрләрен җиренә җиткереп укыды, әмма, нишләтәсең, адәм баласының хиссияти халәте шулай корылган: теге ахмак җибәргән коткыдан залның йөрәгендә яралган боз азакка кадәр эреп бетмәде.

Рәшидне шунысы таң калдырды: теге адәмчек каһарман шагыйрьне җиргә салып таптаганда, залдагы җиде йөз кешедән хет бер генә адәмзат ризасызлык күрсәтсә!.. Алар гүя күпмилләтле бердәм фикердәшләрнең бер татар милләтенә генә каршы бердәм малчылык империясе иде. Әйе, үз гомерендә беренче тапкыр шулай секунд эчендә чәчләрен агартып тетрәнде: нидән шулай? Тормышның мәгънәсе шулай бер-береңне түбәнсетеп, үзеңнең өстенлегеңне раслаудамы? Муса

Җәлил, Галәм каһарманы һәм Галәм гражданины булуына карамастан, бары тик алар өнәмәгән, яратмаган милләт вәкиле — татар булганы өчен генә шулай кимсетеләме? Әйтик, Англиядә, Татарстанда Пушкин, Германиядә Лермонтов әсәрләрен укыр алдыннан, шундый әхлаксызлык кылынуын күз алдына китерү мөмкинме? Юк. Чөнки инглизләр дә, алманнар да, татарлар да мондый вәхшилек чорын урта гасырларның мәгарә-таш феодализмында ук үткәннәр.

Менә шул көнне, шул сәгатьтә, эһ тә итми, тавыш-тын чыгармыйча, ул милләтенең, милләттәшенең керсез намусын саклау һәм яклау өчен көрәшкә чыгарга ант итте. Алар өчен генәме? Юк, изелгән, кимсетелгән һәр милләт вәкилен — бар дөнья юксылларын якларга сүз бирде ул. Шунысы кызык: аны бу көрәшкә гүя Җәлил үзе, аңа карата шушы залда карагруһның: «Татар бит ул!» — дип кычкырып чыгып китүе күтәрде. Антын җир йөзендә Аллаһтан башка беркем ишетмәде. Халыкара киң танылып та, үз илендә әле булса тиешле яклау тапмаган шагыйрьнең алтмыш, җитмеш, сиксән, туксан, йөз еллыгы да формаль шомалыкта, тәмсез-гамьсез тантанада үтеп китә биреп, инде килеп, йөз дә ун еллыгы да якынлашкан көннәрдә, әйе-әйе, 1966 елның салкын февраленнән инде өченче меңьеллыкка кергән бүгенге көннәребезнең салкын февральләренә кадәр әле булса көрәшеп ята Рәшид Рәшидов шагыйрьне вөҗдани әсирлектән азат итү өчен.

Муса Җәлилнең Мөхәммәт кардәше хәбәр иткән һәйкәле 2006 елда — моннан алты ел элек, каһарман-шагыйрьнең йөзьеллыгында ук ачылырга тиеш иде. Мәскәү хуҗаларының татар җәмәгатьчелеген «эт — эткә, эт — койрыкка» уены белән алдап йөртүе аркасында менә шулай алты елга соңлап ачыласы булган икән. Кайда, ничек, диегез. Әүвәлдә суза-суза килделәр дә һич көтелмәгән җирдә — Мәскәү читендәге Орехово-Борисоводагы яңа төзелгән урамга Җәлил исеме бирделәр дә куйдылар. Царицын паркындагы Екатерина II төзеткән һәм үзе үк ташлап качкан сарай бинасыннан ерак түгел. Аннан шагыйрьгә һәйкәл куюны исеме бирелгән шул урамына бәйләделәр. Югыйсә, Җәлил исеменә урам да, һәйкәл дә Мәскәүнең үзәгендәрәк, Яңа Кузнец урамы тирәсендәрәк ачылырга тиеш иде. Анда революциягә кадәр Әсәдулла баба йортына илтә торган Кече һәм Зур Татар урамнары булган. Рәшидов аларга Муса Җәлил исемен бирү һәм шунда ук һәйкәл һәм метро стансасы ачу идеясен күтәрде. Әмма хакимнәр икенчерәк хәл итте: күбрәк татарлар яшәгән һәм тарихи татар исемнәрен йөрткән бу урамнарга фашизм төрмәсендә үлемсез шигырьләр тудырган әсир шагыйрь исемен түгел, ә биленә үзеннән дә зур парабеллум асып, буржуйларны атып йөргән ирдәүкә — ач күзле большевичка Землячка (Роза Самуиловна Залкинд) исемен бирде.

Инде Җәлилгә метро стансасы да ачыйк дигәч, урамы бар бит инде, шул җиткән, дип кырт кистеләр. Менә бит ничек ул, җәмәгать. Метро төзүче бетончы Полежаев, кеше үтерә торган атом бомбаларын тагын да камилләштергән академик Янгельгә метро стансасы ачарга ярый, ә менә үлемсез Җәлилгә ярамый — чөнки татар!.. Монысы инде алтмыш елдан соң булды. Югыйсә ул, коммунист Рәшидов, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты, коммунист Муса Җәлилнең Мәскәүдәге Столешник тыкрыгында урнашкан йортына истәлекле такта элү, аның исеменә урам булдыру, әлеге урам әйләнәсендә шул исемдәге метро стансасын ачу, әлеге урамдагы шул метро стансасы каршына Җәлилгә һәйкәл кую, боларның барысына өстәп, Халыклар Дуслыгы университетына Муса Җәлил исемен бирү тәкъдимен күтәреп, КПСС Үзәк Комитетының Генераль секретаре, коммунист Леонид Брежневка әле 1966 елда ук, «Сосновый Бор» ял йортыннан кайткач та, махсус хат белән мөрәҗәгать иткән иде.

Никадәр беркатлы сабый булган икән ул!.. Бу арада «халыкара коммунистик хәрәкәтнең сирәк җитәкчесе, ленинчыл тыйнаклык иясе Леонид Ильич Брежнев, полковниктан маршалга күтәрелеп, бер тапкыр Социалистик, өч тапкыр Советлар Союзы Герое булырга өлгерде, әмма Җәлилнең ертык әрмис гимнастёркасындагы шәүләсе генә шул ленинчыл тыйнаклык кабинетларында таптануын дәвам итте... Менә шул заманнардан ук өстерәлеп килә инде, халык теле белән әйткәндә, «эт сигәнче», аның фикеренчә, җиңел генә, хәтта ки бөек бер куаныч белән эшләнергә тиешле эшләрнең шулай «этнең — эткә, этнең — койрыкка» бирелгән күрсәтмәләр аркасында өерелгән бюрократлык бураннары. Җәлил исеменә мөнәсәбәтле шушы бер кечкенә хаттан башланган энә очыдай агым, чишмә башы, 1952дән санаганда, алтмыш ел эчендә югарыдагы һәм түбәндәге партия-совет инстанцияләренә язылган 1200 хаттан ашып китте һәм кешегә битарафлыкның Ленин мавзолее белән рәттән куярлык янә бер Хатлар Мавзолеена әверелде.

Татарга дигәндә, төпсез чанага әйләнгән иде бу «инстанцияләр» уйлап тапкан уйдырмалар. Нинди генә хәйләгә керешми, нинди генә тозак кормый, нинди генә сәбәпләр уйлап тапмый иде алар мәсьәләдән чишелмәс төен ясар өчен!..

Үз чиратында Рәшидов аларга каршы нинди генә төпле дәлилләр, ышандырырлык мисаллар китерми иде. Әйтик, бер хатында ул народоволец Николай Морозов язмышын искә алды. Морозов 1882 елда патша Александр IIне үтерүне әзерләүдә катнашканы өчен, гомерлеккә Петропавел крепостенә ябыла. 28 ел зинданда утырган чорында ул 11 чит тел өйрәнә, физика, химия, тарих, астрономия, фәлсәфә һәм башка фәннәр буенча 26 том хезмәт яза, дистәләгән ачышлар ясый. Октябрь түнтәрелешеннән соң, 1923 елда Ленин, алпавытларның башына җиткән ата коммунист, Морозовны аерым декрет белән иреккә чыгара һәм аны рәсми рәвештә «совет алпавыты» дип игълан итеп, тартып алынган җирбиләүче утарын кире кайтара. Төрмәдән чыгу белән, урта белеме дә булмаган Николай Морозов «Матдә төзелешенең периодик системасы: химик элементларның әверелү кануннары» дигән темага докторлык диссертациясе яклый...

Бу хатыннан соң, аны чакырып: «Нәрсә, Җәлилнең алпавыт утары да булганмыни?» — дип сорау алдылар. Шаркылдап көлделәр дә әле!..

Ә менә әдипнең Столешник тыкрыгында яшәгән фатирына истәлекле такта кую өчен, андагы пропискасы ачыкланмаган, прописканы ачыклау өчен, ул чактагы паспорт өстәле хезмәте юкка чыккан, дип суздылар да суздылар. Метро стансасына исем бирү өчен, аның исемендәге урам, урамга исем бирү өчен, аның исемендәге метро стансасы, һәйкәл ачу өчен, шунда аның исемендәге урам һәм метро стансасы булуы, университетны аның исеме белән атау өчен, нindидер Коминтерн һәм Варшава бердәмлеге илләре җитәкчеләренең имзалары кирәк икән, имеш!.. Кайбер органнар хатларга җавап бирүне артык санап, үзләренә әңгәмәгә чакыралар иде. Салкын чәй дә эчереп җибәрәләр. Шулкадәр күп хатлар язып, кешеләрне бимазалау, борчу өчен, иптәш Рәшидов, сезнең башка эшегез юкмыни? Кем булып чыга сезгә Муса Мостафа улы Җәлилов? Ни өчен бу кадәр тырышасыз? Ул сезнең агагыз, якын туганыгызмы? Юк. Якташыгызмы, әллә сез дә Ырымбур далаларында көеп яткан Мостафа авылыннанмы? Аһ, сез бөтенләй башка яктан — нindидер тундра тарафларында туңган Тәтешлеләрдән? Димәк, ул сез хат язып, бер вагон кәгазь исраф итүгә лаек җизнәгез, кодагыз? Аһ, беркем дә түгел!.. Алай булгач, пычагыма кирәк булдымы ул сезгә? Аны татар булганы өчен генә яклап, үзегезгә дә «милләтче» ләкабе алудан курыкмыйсызмы? Әңгәмә коручылар кызып китеп, әле кичә генә

«хыянәтче» исеменнән азат ителгән патриот Муса Җәлилне советлар алдында комиссар, немецлар алдында «чит мәмләкәттәге татар премьеры» булып кыйланып, рейхның йөрәгендә Идел-Урал мөселман батальоннары оештырып, алар өчен татарча газета-журналлар чыгарган «Туран милләтчесе», җыр-бию оештырган «ат кәмитчесе» дип атауга кадәр барып җитәләр иде!..

Тагын да шунысы кызык: әле Җәлил шигырьләрен укыр алдыннан залда яңгыраган «Татар бит ул!» дигән көрән гыйбарәдән гарьләнеп, бу исемне мәңгеләштерүгә багышлап язылган хатлар, озак та үтми барлык иселгән җәмгыять, гомумән, хезмәт кешесен яклап язылачак йөзләгән, хәтта меңләгән хатлар миссиясенең чишмә башы гына булган икән. Чишмә чишмәгә кушылып, елга булды. Эш шунда ки, сугыш тәмамланып, хәрби хезмәттән кайтканыннан соң, аны яңа заман очкычларын җитештерәчәк яшерен заводлар төзелеп яткан Химки бистәсенең йортлар идарәсе мөдире итеп куйдылар. Ул, гади вазифа кешесенең үз бурычларын җиренә җиткереп үтәргә тырышкан хәлдә, югары, бик тә югары, хәтта бердәнбер затка язган эшлекле тәкъдим хатларының, район, шәһәр һәм үзәк газеталарга язган кечкенә язмаларының нинди әһәмияткә, нинди яңгырашка лаек булуын йөрәгеннән кичерде. Баткак-сазлыктан чыгар өчен аваз кирәк иде. Аваз бирү өчен, үз сүзенә үзе җавап биргән кеше кирәк иде. Ул кеше табылды. Ул кеше — ул үзе булып чыкты. Бер караганда, Мәскәү дигән алты миллионлы шәһәр эчендә Химки дигән илле мең кеше яшәгән шәһәр бар да кебек. Тик анда тиешле шәһәр транспорты, тиешле элемтә, тиешле сәүдә, тиешле торак, тиешле канализация, тиешле мунча, кыскасы, тиешле булган бернәрсә дә юк. Тиешеннән артык булган бер генә нәрсә бар: ул да булса сырсып чыккан императив бюрократия. Һәм кичәге Тәтешле баласы, фронтка эләгә алмыйча, янбалитка калган Рәшид Рәшидов, шушы бюрократиягә каршы үзенең хатлары, басылган мәкаләләре белән баш күтәрде. Ун-унбиш ел эчендә өч тапкыр имля алыштырып та исән калган, һушын югалтмаган милләт баласы үзен түгел, башкаларны яклап утка керде һәм кытыршы дөнья пычрагын теле белән ялап тазарткан язучыга әверелде. Төнлә язылган хаттан соң күпмедер вакыт үтүгә, аның тәрәзә каршына, сандугач кебек сайрап, ул сораган экскаватор, сварка җайланмасы, трактор-автомобильләр килеп туктый торган иде...

Борынгы яһүдиләрнең дастани бозыклык һәм җимереклек оясы Содом Һәм Гоморра бәлки шушы Химки сыманрак халәттә булгандыр. Шуңа күрә мондагы бер урамның исеме дә Хаос дип атала иде. Бирелдә урамнарның исеме, йортларның номерлары, канализация дә юк, электр юк; утын белән җылытылган баракларда һәр пүлән хакы валютага тиң, кешеләрне утынсыз туңдыру утын магнаты — утын келәте мөдире хапуга Костя Бережной кулында. Һәм Рәшид Рәшидовка менә шушы шартларда Җәлил язмышы буенча язылган мең хатына өстәп, көтмәгәндә Химки кебек ташландык бандитлар оясын тазарту, сафландыру, төзелеш мәйданына әйләндерү, андагы ярым җимерек, бәпкәләре тырпаеп торган түбәсез баракларны җир белән тигезләп, яңарышны тизләтү, чегән таборына әйләндерелгән саланы гүзәл кала итү, матурлау, яшелләндерү буенча Химки районы җитәкчелегеннән алып, Сходня, Мәскәү өлкәсе, Мәскәү шәһәре түрәләренә, КПСС Үзәк Комитетына кадәр тагын да меңләгән хат язу бурычы төште. Ул тирән эчтәлекле хатлары, дистәләгән газеталарда, шул исәптән «Правда», «Известия»да чыккан үткер мәкаләләре белән иң югарыдагы җитәкчеләрнең теңкәләренә шулкадәр дә тиде ки, хәтта Үзәк Комитетның Беренче Секретаре Никита Сергеевич Хрущёв Химкига үзе килергә һәм моңача күрелмәгән зур төзелешкә

юл ачып китәргә мәҗбүр булды. Шулай итеп, Иске Кудаш улы Рәшидов чирек гасыр домоуправ булып эшләү чорында Химки дигән чүплекне чәчәклеккә, чәчәклекне шәһәргә, шәһәрне илнең космос-ракета үзәгенә, Мәскәүнең иң төзек, иң матур өлешенә әйләндерүгә иреште. Ул үзе белән бергә, теге санитар татарлар кебек, хатынын — Разыясын, уллары Наил белән Әнвәрне урамнар тазартырга, бакчалар утыртырга алып чыкты. Хәзер андагы агач ботакларына эленгән оялары тупсасында сыерчыклар һәм сандугачлар ярыша-ярыша сайрый. Күз карашын томалап торган калдык-постык, чүптән тыгылган эстакадалар, путепроводлар Семирамиданың асылмалы бакчаларына, чокыр-чакырдагы чүплекләр бакчаларга, сазлыклар саф сулы күлләргә әверелде.

Әмма тормыш алга барды. Җәлил истәлеген сакларга чакырып язылган мең хаты, Химкины чын социалистик шәһәр итүгә чакырып язган мең хатына кушып, һәрвакыттагыча, тагын да кинәттән, үткән гасырның илленче-сиксәненче елларында аның туган ягы башкорт «патшалыгында», Мәскәү кушуы буенча, татар халкын көчләп башкорт итеп язу һәм башкортча укытуга күчерү кампаниясе башлангач, ул шушы гаделсезлеккә каршы чынчынлап оран салды һәм тиешле органнарга тагын да меңнән артык хат язды. Аны берничә тапкыр КПСС Үзәк Комитеты секретарьлары Михаил Андреевич Суслов һәм Егор Кузьмич Лигачёв аппаратларына чакырып аңгәмә кордылар. Үзәк Комитетның 1989 елның Февраль Пленумындагы нотыгында Лигачёв Башкортстандагы хәлләргә кискен бәя бирде һәм, ниһаять, гадәти күренешкә әйләнеп барган ерткычлыкка чик куелды…

Шулай итеп, рәсми урта һәм югары белеме дә булмаган, үз гомерендә туган телендә тулысы белән, рәхәтләнеп, бер сыйныф та укырга насыйп итмәгән, сигез яшендә гарәп имлясыннан яңалифкә, егерме яшендә яңалифтән кирилл язмасына көчләп күчерелгән, урамнарның «беспризорный» шайкалары, сугышлар-кырылышлар аша үтеп, үзлегеннән укып-өйрәнеп, кырык яшеннән соң марксизм-ленинизм университетын, аннан, 26 имтихан тапшырып, юристларның югары мәктәбен тәмамлаган Рәшидов, кичәге солдат, МУР ((Московский уголовный розыск) – Мәскәү Җинаятьләр тикшерү идарәсе) оперы, урам себерүче-дворниклар «башкомандующие», әле академик Сахаровлардан күпкә алда, халык кадәр халыклар — татарны гына түгел, барча изелгән милләт мәнфәгатьләрен яклаган хокук яклаучы булып җитешкән иде… Каян килгән бу көч мәктәптә әлифбасын да өйрәнеп өлгермәгән кешегә? Нинди чыганаклардан чишмә булып бәреп чыгып, җан курайларыннан өзелгән бу гамь? Кан тамырларында ничәмә-ничә гасырлар буе тупланган ком-ташны нинди сихри, нинди моңнар эретә һәм бозларны агызган язгы ташу кебек агызып алып китә алган? Каян килгән бу туган телгә, туган илгә, туган җиргә-суга булган мәхәббәт һәм бетмәс-төкәнмәс юксыну?!

Ул дымлы күзләре белән суынган чәенә караш ташлады.

Андагы шама һаман да йөзә иде.

Ул хатирәләргә бирелде…

III.

…Әнисе ягыннан бабасы Якуб 1921 ел ачлыгында үлгән. Әтисе ягыннан бабасы Мөхсин, мулла һәм хаҗи, 1930 елда гаиләсе белән кулга алынып, Ерак Көнчыгыштагы Алдан рудникларына сөрелә. Туган ягына бүтән кайта алмый. Аның Ямады авылындагы икекатлы йортында мәктәп ачалар.

Бала ата-ана кылган гөнаһлар өчен җавап бирә, дигән гыйбарә бар. Бәлки чынлап та шулайдыр. Рәшиднең әтисе Хәлимгә килгәндә, бу ихластан расланды кебек. Бабасы кылган гөнаһлар ул заман өчен зур булган, диләр. Әтисе Хәлим туганнан соң, беренче хаты-

ны Галимәне ташлап, күренекле шагыйрь, фикер иясе, дин белгече Гали Чокрыйның (Гали Киеков) үзеннән утыз бер яшькә яшь кызын хатынлыкка ала. Бу кайгыны күтәрә алмаган Галимә озакламый якты дөнья белән хушлаша. Хәлим гаиләдә сөйкемсез сөяк булып үсә. Аны чит күрәләр. 11 яшеннән сабый ун ел буе Уфаның «Галия» мәдрәсәсендә Коръәнне өйрәнә, гарәп, фарсы, төрек телләрендә тирән белемгә ия булып авылга кайта. Авылда мулла булганлыктан, аны мөәзин итәләр. Ул бәхетле булмый, күп югалтулар кичерә. Өч тапкыр өйләнә, өч никахтан унбер бала туа. Беренче хатыны — дүрт, икенче хатыны бер бала китереп үлә. Биш бала белән нишләргә белми язмыш йөген тарткан мөәзин югалып калмый, өченчегә биш чакрым ераклыктагы Иске Кудаш авылыннан — шактый хәлле гаиләдән (бирнәсенә «Зингер» дигән тегү машинасы да керә!) үзеннән утыз бер яшькә кече булган егерме яшьлек чибәр һәм акыллы Гайшәгә — Рәшиднең әнисенә өйләнә. Искиткеч матур мәкамле Хәлим, намазга чакырып, тәүлегенә биш тапкыр азан әйтү белән генә чикләнми, авыл мажиклары белән бертигездән җирен сөрә, малын асрый, итеген тегә, умартасын тота. Гарәпчәдән «юмарт, йомшак, изге күңелле» дип тәрҗемә ителгән атасы Хәлимнең исеме җисеменә тап килә: чынлап та юмарт булган бу гаделҗан, кем нәрсәсен, хәтта бердәнбер атын ошатса да, аны ызаннан чыгарып, бүләк итәргә күп сорамый. Гайшә гаиләгә өч ел саен бер бала алып кайта: 1918 елда Рәшид туа, әмма аны 1919 елгы дип яздыралар. Әмма ул үзен унсигездән исәпләп йөри. Рәшидтән соң Рәшидә, Хамат, Бәһия һәм Хәмис туа.

Түбән һәм Югары Кудаш авылларын бер тән, бер кан, бер җан кебек кушып, туендырып торган кечкенә Кудаш инеше шулай ук кечкенә Рәшид өчен бик зур океан иде. Бередәге басулар, ул үзе раславынча, фәкыйрьләр басуы булса да, мескеннәр басуы түгел иде. Халык та мескен түгел. Әнә ат карагы Галимҗан абзыйлары бар халык алдында мактана: башка якларда ат караклары атларны, тавыш-тынсыз дип, араннан чабата кидертеп алып чыга. Мин вакланмыйм, көмеш тояклы җанкайларымны читек кидереп кенә алып чыгам, ха-ха-ха!»

Ул яшел хәтфә тугайларда казлар, бозаулар көтте, башка малайлар белән аунап, көрәшеп һәм су кереп, тәнен тимер кебек чыныктырды. Аның балачагы җир йөзендә иң бәхетле балачак кебек хәтердә калган: кояш — күпме кирәк! Җылы — күпме кирәк! Салкын — күпме кирәк! Дуслык, әпәләш һәм тәпәләш — күпме кирәк! Һәм — адашып кына килеп ява торган яшел яңгырлар! Бу якта аларны хыялый яңгырлар, диләр. Язын иегән сыер йонынан төкерекли-төкерекли әвәләгән туплар белән малайларның ике төркемгә бүленеп уйнаган «чәкән» уеннарын гына ал. Моннан да татлырак тирдән тамган ләззәтнең тагын да булуы мөмкин микән? Йөз яшькә җитеп тә тормыштан туймавының, кешегә эһ дип тә авыр сүз әйтмәвенең, улы Наилнең: «Әти, син дөрес яшәгәнгә күрә озак яшисең!» — диюенең сере шушы Кудаш ярларында тамган тирләр сихәтеннән яратылмады микән?

Татар бәхете — ата-ана сүзе, табигать кодрәте һәм мал-туар авазы бердәмлегеннән бар булган бәхет ул. Авыллы, игенле-камыллы һәм җилледавыллы булу бәхете. Мондый тормышта югалту да иҗтиһадка, савапка әверелә. Милләтләрнең, диннәрнең төрлелеге аерымлыкка түгел, бергәлеккә хезмәт итә. Шуны аңлап, сабырлыкта һәм шөкердә яши белсәң, тормыш бәхет чыганагына әйләнә. Йөз яшенә якынаеп барган Рәшид һич онытмас: аларның авылына әле ул туганчы — егерменче гасыр башларында килеп урнашкан биш урыс гаиләсе бар иде. Авыл халкы аларга үзләренең җирен бүлеп биргән. Авылда урыс-татар катнаш гаиләләре барлыкка килә. Рәшид хәтерли: аларның күршеләре тегермәнче Михайла бабай һәм Шүрә-түтки иде. Михайла

бабай тире дә или. Аны әтисе (имеш, ул да урысча белә) «шкурник» дип атый. Соңыннан белүенчә, «шкуроизготовитель» белән «шкурник» икесе ике нәрсә икән. Шүрә-түтки аларга һәр җомгада хәер кертә. Кереә-керештән капкадан ук кычкыра: «Гайшә түтки, мин сина хаир китирдим!» Татарда «Күрше хакы — тәңре хакы» дигән сүз бар. Әнисе бирәр нәрсә пешерсә, бар, Михайлага илтеп кайт, дип аны тегермәнгә җибәрә иде. Бермәлне ул шулай аңа кыстыбыйлар илтергә кушты. Кайтырга чыккан Михайла каршы очрады. Әнә, ул инде «Кысбытый — это үтрически якши!» дип яшел үләнгә утырып, кыстыбыйларны бөгә, ә бәләкәй Рәшид, тәмледер диеп, ап-ак он каплаган Михайла бабасын ялап карый…

Әтисенең кулга алынуы да шул тегермәнгә бәйле. 1930 елда әтисе кесәсенә гәзит тә кыстырып, Михайла тегермәненә яңа уңыш арышын тарттырырга бара. Мулла буларак, колхозга кабул итмәсләр дип куркып йөргән Хәлим тегермәндә кычкырып гәзит укый: анда, әгәр ике баласы булса, муллаларны да колхозга кабул итәләр, дип язылган була. Тыңлаучылардан кемдер Хәлим тегермәндә сәвитләргә каршы сөйләде, дип хәбәр итә. Әтисен кулга алдылар, «халык дошманы» дип игълан иттеләр, унбер баланы илнең унбер почмагына тараттылар. Бу вакыйгаларга уналты ел үткәч кенә ачыкланды атасын саткан кеше. 1946 елның кышында, хәрби хезмәттән котылып, теге тар-марлардан соң Мәскәүдә почмак тапкан өлкән агасы Зәкигә үтеп барган уңайдан туган авылларына кереп чыгарга булды ул. «Күршебез Һидият абыең каты чирләп китте, — диде әнисе. — Бар, кереп, хәлен белеп чык». Рәшид, ат җигеп, район үзәгеннән табибны алып килде. Һидият абзыйсының үпкәсе үтәдән үтә җилсенгән икән. Әгәр өендә калдырсагыз, ике көннән дә артык торалмас, диде табиб. Больниска илтергә кирәк. Рәшид аны, нинди җылы нәрсә тапса, шуңа төреп, больниска алып барды. Ике атнадан Һидият терелеп тә кайтты. Аларга керде. Өйдә беркем дә юк иде. Тезләнде һәм кулларыннан үпте: «И-и-туган, мине коткардың, мине бит үтерергә кирәк! Әтиегезне мин утырткание бит!..»

Авыр сугыш заманнарын үткән солдат менә шул минутта изгелекнең нинди көчкә ия булуын мәңгелеккә аңлады. Гаиләне кулга алганнан соң, аларны колхозга керүчеләр өчен өч чакрым ераклыкта төзелеп яткан яңа авылга — япаланга илтеп ыргытырга тиешләр иде. Әмма күршеләре Тәнзилә апа, кызганып, кара мунчаларына кертеп торды. Икенче елны аларның бар нәрсәләрен талап алдылар. Хәмис энесенең күн пинжәген, әнисенең бирнә белән килгән «Зингер» машинкасын да калдырмадылар.

Әтисен ничек хөкемсез-нисез утыртсалар, ике елдан соң шулай хөкемсезнисез чыгардылар да. Әтисе сөйләгән иде. Бермәлне ул утырган хөҗрәгә шундый ук тоткынны кертәләр. Ул Сталины хурлый да, Сталинны хурлый. Ә әтисе Сталинга озын гомер теләп, аның исәнлегенә догалар кылып, намаз укый да намаз укый. Эчендәге уен белү өчен, камерасына кертелгән «ялган үрдәк» бакылдауларына ышанмыйча, намазында Сталинга шөкрана кылып, иреккә чыгарганы өчен, атасы Сталинга чын күңеленнән рәхмәтләр укый иде, мескенкәй. Төрмәдән чыгуга, Түбән Кудашта оешкан «Урал» колхозы әгъзалары мулланы шундук күмәк хуҗалыкка кабул иттеләр. Бер үк вакытта ул мулла вазифаларын да башкарды. Сугыштан соң аларга бер кеше куна керә. Көтелмәгән кунак төне буе Сталинны һәм совет властен сүгә. Атасы бу коткыга да бирелми. Соңыннан билгеле булуынча, бу кеше авылдан авылга мулла-мунтагайларга кереп кунган булып, аларның эч серен белеп йөргән провокатор булып чыккан икән. Күрше авыллардан өч мулла кисәге, бу коткыга бирелеп, язмыш карьераларын Колыма карьерларында тәмамладылар.

Әтисе төрмәдә вакытлар бик тә

үзәккә үтте. Берничә ел рәттән иген уңмады. Халык авыллары-авыллары белән ачтан кырылды. Черек бәрәңге кәлҗемәсен сөян оны белән бергә кушып пешергән коймакларның күңелне уйнатыр дәрәҗәдәге төче тәмен һич тә онытмый Рәшид. Күрше Куеда стансасына мае сыктырылганнан соң калган көнбагыш төбе — «жмых» төялгән вагоннар килеп туктаган көннәр алар өчен бәйрәм иде. Ничә тапкыр брикет урлап, ничә тапкыр камчыдан кыйналды икән ул? Беренче кычыткан, беренче балтырганга җитеп, алардан тере «витамин» пешергән, беренче кымызлык, көпшә ашаган сәгатьләр онытылырмы?! Ярый әле, һаман да шул тегермәнче Михайла бабалары, авыл сәвитләреннән яшереп, «халык дошманы» гаиләсенә кашыклап булса да он керткәли иде. Рәшид үзе, чыдый алмыйча, унөч яшендә авылдан чыгып качкач, аның унбер яшьлек энесе Хамат ачлыктан шешенеп үлә. Җиде яшеннән Изге Китапны коръәнхафизларча яттан укый башлаган, төрмәдәге атасы кебек, вәгазен гарәп, фарсы, татар телләрендә сөйләгән, сирәк талантка ия булган бу сабый үләр алдыннан кулындагы бердәнбер байлыгын — чәй төрелә торган елтыр фольгасын «Чәй көмеше бирәм, ипи генә биреп торыгыз!» — дип инәлә. Каян алсыннар?

Рәшиднең балачагы атасын кулга алган сәгатьтә тәмамланды. Ул, өйдә ир затыннан иң зур кеше, уникенче яше белән бара иде. Башкалар аңа туендыручы ир заты дип карыйлар, хәтта авыл сәвите утырышларына гаилә башлыгы итеп чакырталар. Бермәлне продналог буенча җыелышка өстерәп диярлек алып киттеләр. Малай башкалар күрмәгәндә мич арасына кереп, утыннар белән капланып яшеренде. Аны кисәү агасы белән гөргеләп чыгарып, өстәл артына утырттылар. Белмәгәндәй, сораштырган булалар:

— Фамилияң кем?
— Рәшидов.
— Исемең кем?
— Рәшид.
— Атаң кем?
— Хәлим мулла.
— Ул кайда?
— Өтөрмәдә утыра.
— Ни өчен?
— Халык дошманы, диләр…

Продналогтан читтә калдырмас өчен, аңа өстәмә җир бүлеп бирделәр. Ул исә бик ташлы, таштан бигрәк тимер-томырлы булып чыкты: гражданнар сугышы чорында каты сугыш булган, күрәсең, туфрак патроннар белән шыгырдап тора, сукасы чирәмне күтәрә алмый иде… Ул, унике яшьлек бала, үзе сөрде, тырмады, чәчте һәм урды. Көн саен, үстеләр микән дип, беләк мускулларын капшап карый. Кышын урманнан утынны да берүзе ташый. Бу гамәлнең дә серләре байтак иде: ул, урманчы күрмәгәндә, юкә агачларын аударырга тырыша, алардан чабаталык юкә дә суела, җылысы чамалы булса да, ягарга утын-сутыны да кала. Кичләрен күрше малае Әсхәб белән чабата тукый, аны Куеда стансасында парын берәр тәңкәдән сата, очраганда, кара ипи сатып ала…

Их, укыйсы килгәнлекләре! Матур, нечкә муенлы аккошларга охшаган гарәп хәрефләре белән киләчәккә оча гына башлаганда, гүя аны атып төшерделәр. Җир йөзенең, кешелек тарихының иң грациоз, иң зифа, иң нәфис, иң зыялы, иң йөгерек язмасы булган гарәп язмасы яңалиф үзенең очышта булуы белән күпмедер күләмдә гарәпкә охшаган латин-роман язмасы белән алыштырылды. Рәшид имляның беренчесен үзләштереп өлгермәде, икенчесе аны, әзерлексез сабыйны, авыр атламы белән изде. Тагын сигез генә ел үтәр, гарәбен һәм яңалифен ордыбәрде булса да өйрәнеп маташкан сабый язмышына балта-секираларга охшаган кирилл-славян язмасы килеп керер…

Әйе, ул әле вакыты барда ай яктысында булса да гарәпчә язылган татар китапларын укырга тырышкан, авыл читендәге, дүрт сыйныфы бер бүлмәдә

укыган мәптеккә баргалаган була. Их, аның ничекләр итеп матур язарга өйрәнергә теләвен аңласагыз!.. Әйе, атасын өйләреннән алып чыкканнан соң, ул укуын туктатырга мәҗбүр булды. Һәм ул, аталы-аналы ятим, йортсыз-җирсез «беспризорник», мәктәп бусагасын тарих чүплекләре аша бары тик Казанда уналты яшендә генә эзләп табачак. Кайда гына барса да, нәрсә генә эшләсә дә, аны шушы аяусыз сорау, дар агачындагы элмәк сыман котсыз сөаль алулар озата барачак. Һәм озата барды да:

— Фамилияң кем?

— Рәшидов.

— Исемең кем?

— Рәшид.

— Атаң кем?

— Хәлим мулла.

— Халык дошманы буларак, төрмәдә утырганмы?

— Утырган.

Менә шулчакта барысы да аңлашыла да куя. Урыныгызга утырыгыз, татар баласы!.. Сезнең белән барысы да ачык, ягъни мәсәлән.

Ул боларның барысын да «гүзәл газап» дип атый. Пәйгамбәрлекнең чишмә башы — ятимлектә. Барлык дөнья әдәбияты тарихы — Гомердан башлап Диккенс, Тукайларга кадәр шуны раслый. Яши белсәң, тормыш мең гаҗәп, яши белмәсәң, мең газап. Яши белсәң, тормыш могҗиза, яши белмәсәң, мең җәза. Аның, йөз яшькә җитеп тә, гореф-гадәтенең, кешелек кыйммәтенең үзгәрешсез калуында шушы «гүзәл газаплы» җәфалар хәлиткеч роль уйнамады микән дип уйлый Рәшид кайчакларда.

Зәки абыйсы Мәскәүдә, Сәгыйть абыйсы Серпуховта иде. Серпуховтан Казанга күчкәч, ул бу серле шәһәрнең җитез трамвайлары, биек манаралы мәчетләре, тәмле пәрәмәчләре турында хатлар яза башлады. Күкләрне күкрәтеп, канатларына кызыл йолдызлар кунаклаган очкычлар үткәли. Ә җирдә Рәшидкә ифрат та күңелсез. Анда налог та налог, салым да салым. Әтисе һаман Уфа төрмәсендә утыра, әнисенең, кечкенә энесен тудырганнан соң, чирдән чыкканы юк.

Ярый әле бәхетенә әтисе кайтып төште. Бик тә укыйсы, үсәсе, яңа дөньяларны күрәсе, авылның кара мунча баласы булып калмыйча, яңа дөньяларны күрәсе килгән Рәшид атасына теләген әйтте. Аңлады аны атасы. «Тотмыйм, — диде. — Сиңа, үзем төрмәдә чакта нигезебездә ут саклаган улыма, фатихамны бирәм. Тик бер теләк белән: Казанга, Сәгыйть абкаңа йөз тот. Телеңне, илеңне, динеңне ташлама...»

Шулчак аның күңелендә гөлт итеп ниндидер ут кабынды:

Әйтә иртәнге намазга
бик матур моңлы азан;
И Казан!Дәртле Казан!
Моңлы Казан! Нурлы Казан!..

Каян килде бу илаһи сүзләр өермәсе? Бу — Рәшиднең, вакыты булып, мәктәпкә йөргәндә, дүртенче сыйныфлар ятлаган шигырьдән күңеленә кереп утырган бер өлеш иде. Ул аның башка өлешләрен генә түгел, җир йөзендә Габдулла Тукай кебек бер тылсымчы шагыйрь барлыгын һәм үзе ятлаган өзекнең нәкъ аның шигыреннән булуын да белми иде.

Менә ул атасының төрмәдән кайткан буш токчаен аркасына киеп, авыл капкасына чыкты. Бар тирә-якка карады. Хушыгыз, Кудаш буйлары! Хушыгыз, мине туйдырган туган таулар, урманнар, песи башлы үләннәр! Алдагы офыклар аңа нинди язмышны әзерләгән?

Ул, бисмилласын әйтеп, сәфәр догасын укыды.

Бу аның балачагы белән хушлашуы иде.

Ул, авылдан чыгып, олы юлга төште.

Күктә 1931 елның май кояшы яна, аңа исә нибары унөч яшь иде.

Ахыры алдагы санда

«ТОЛСТОЙ ДА БЕЛГӘН МУЛЛА ИЛЕН...»

Гомерен балаларга белем-тәрбия бирү эшенә багышлаган, бик күп еллар Яшел Үзән районы Мулла Иле мәктәбендә директор булган, университетта бергә белем алган сабакташым Равил Сәйфетдиновның «Мулла Иле моңнары» дип аталган җыентыгы дөнья күрде. Өч кисәктән торган әлеге китап үз эченә авторның күп еллар дәвамында иҗат иткән шигырь-поэмаларын, мәкалә-очеркларын, хикәяләрен, гыйбрәтле хәлләргә бәйле кыска язмаларын сыйдырган.

Чыгышлары белән Мулла Иленнән, яңа бер иҗтимагый, сәяси, дини юнәлешкә нигез салган аталы-уллы Бәһаветдин һәм Гайнан Вәисиләр аның рухи дөньясында, иҗатында аерым урын били.

Мөхәммәд пәйгамбәребез фани дөньяны ташлап китәр алдыннан чапанын бүләк иткән суфи Вәис исемен тәхәллүсләре итеп алган, яклаучылары, дәвамчылары белән бергә дошманнарын, күрә алмаучыларын тапкан бу хәрәкәт XX гасыр башында ук зур бәхәсләр уята. Рәхәт, тыныч, тук тормышлы сәүдәгәр Габдулла Килдишев, «Бәянелхак» газетасы редакторы Әхмәтҗан Сәйдәшевләрнең Вәисиләрне пычраткан мәкаләләре, беренчесенең «Гайнан Вәисов тозагы» (1908) китабы хәтта Тукайга да тәэсир итә. «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» сатирик поэмасында ул Гайнан Вәисовны тискәре персонаж итеп чыгара (*кара: «Чын Мирас». – 2013. – №6. – Б.110-114*).

Р.Сәйфетдин бу юнәлешкә ике язмасын — «Вәисиләр турында хикәят» (2000) исемле күләмле шигъри әсәрен һәм «Мине игелекле мөселман дип санавыгызны үтенәм» исемле хикәясен багышлый. Соңгысын сезгә дә тәкъдим итәбез.

Рус зыялыларының халыкка йөрү (народничество) хәрәкәтенә якын торган оешмага XIX йөзнең икенче яртысында тынгысыз шәхес Бәһаветдин ишан нигез сала. Ул патшага, аның хатынына, министрларга татар халкының җәберләнүе, хокуксызлыгы турында аңлатып, ирек таләп итеп, Коръән кануннары белән яшәргә рөхсәт итүләрен сорап, туктаусыз хатлар яза. Р.Сәйфетдин шагыйрь Бәһаветдиннең Петербург подвалларында югалып калган, яшендәй ялкынлы хатларының эчтәлеген хәзерге укучыга җиткерү заруриятен аңлап эш итә:

Галиҗәнаб патша хәзрәтләре!
Хак сагында торган хөкемдар.
Татарларың хөрлек өмет итә,
Татарларга нигә урын тар?

Алдагы юлларда бу фикер янәдән кабатлана:

Рәхимең киң, изгелекләр эшлә,
Татарларның моңа хакы бар.
(«Вәисиләр турында хикәят»)

Халкына тиешле ташламалар таләп итүе өчен Бәһаветдин ишан хакимиятнең явыз дошманына әверелә. Җегәрле, пырдымсыз кешедән котылу

әмәле дә табыла. «Акча өчен антны» саткан табиблар аны юләрләр йортына ябып куялар. Шагыйрь бу гаделсезлекне Баһаветдиннең үзеннән «фаш иттерә».

— Тикшерегез!
Мондый шигырьләрне
Юләр кеше яза аламы?
Бөтен Казан буйлап өне китте:
— Хаклык уты җирдә янамы?

Вәисиләрнең татар-мөселман халыкларына тигезлек, хаклык таләп иткән фикерләре, бәхетле яшәеш өчен көрәшләре эзсез югалмаган икән, аларның хыял-идеяләре олы шәхесләрне рухландырган, хәтта ил чикләрен үтеп, азатлык өчен көрәшүчеләргә үрнәк-өлге дәрәҗәсенә күтәрелгән.

Толстой да белгән Мулла Илен,
Кунак иткән сөеп Гайнанын.
Хәтта Ганди белеп Һиндстанда
Горур йөрткән Сардар байрагын.

Халык бәхете өчен үзләрен кызганмыйча көрәшкән элгәрләребезнең фидакарьлеге яңа буынны уйландырсын, файдалы киңәш-табышлары онытылмасын, ди шагыйрь.

Хаклык өчен җанын биргәннәрнең
Белерләрме кадрен бер заман?
Аһ, белсәләр кадрен газизләрнең
Булыр иде төзек бу җиһан!

Атасы нигез салган Вәисиләр хәрәкәтен улы Гайнан дәвам иттерә. 16 яшендә төрмә белән куркытып алуларына карамастан, ул сынмый, сыгылмый, корыч кебек нык көрәшче булып җитешә һәм сайлаган юлының, гамәлләренең дөреслеген тикшерү, киңәшләшү нияте белән акыл иясе, мәшһүр язучы Л.Толстойга мөрәҗәгать итә. Р.Сәйфетдин «Мине игелекле мөселман дип санавыгызны үтенәм»

Равил Сәйфетдинов

хикәясен шул тарихи очрашуга багышлый. Ошбу вакыйганы үзе шаһиты булган кешедәй бәян итә.

«1909 елның 15 гыйнварында, тышта буран улаган бер көндә, Толстой Гайнан Вәисовтан хат алды һәм шул көнне үк сиксән бер яшьлек карт аңа җавап та язып җибәрде: «Хөрмәтле туганым Гайнетдин Вәисов! Сезнең миңа килергә теләгегез турында хәбәр алып, мин бик шатландым... Кайчан телисез, шунда килегез, мин беркая да китмим».

Бер ай тулыр-тулмас утыз сигез яшьлек, җыенкы гәүдәле, ачык йөзле Казан татары Толстой кырына килеп тә җитә. Өч көн дәвамында Гайнан шунда яшәп, дөньяның барышы, вәисиләр хәрәкәтенең асылы, диннәр арасындагы якынлык һәм аерма турында ашыкмыйча гына сөйләшү алып баралар.

Тәлгат Галиуллин,
филология фәннәре докторы,
Казан (Идел буе) федераль
университеты профессоры

МИНЕ ИГЕЛЕКЛЕ МӨСЕЛМАН ДИП САНАВЫГЫЗНЫ ҮТЕНӘМ

РАВИЛ СӘЙФЕТДИНОВ

Күрәсезме, сизәсезме, без Колшәриф, Батырша, Гайнан Вәисов кебек корбаннарыбыз хакына мәчетләр төзеп, җай гына булса да алга барабыз.
Айдар Хәлим

1909 елның 15 гыйнварында, тышта буран улаган бер көндә, Лев Толстой Гайнан Вәисовтан хат алды һәм шул көнне үк сиксән бер яшьлек бу карт аңа җавап та язып җибәрде: «Хөрмәтле туганым Гайнетдин Вәисов! Сезнең миңа килергә теләвегез турында хәбәр алып, мин бик шатландым. Сезнең турыда ишеткәннәремә караганда, безнең карашлар бертөрле булыр дип ышанам. Сезнең Аллаһыны һәм җирдәге кешене ничек аңлавыгыз турында фикерләрегезне төгәл беләсем килә. Сезне күрсәм, бик шат булырмын. Кайчан телисез, шунда килегез, мин беркая да китмим».

Гайнан Вәисов Ясная Полянага 1909 елның 11 февралендә — кояшлы, җылы бер көндә килде. Утыз сигез яшьлек бу мөлаем Казан татарын Толстой беренче күрүдә үк яратты. Пөхтә кыркылган кара сакаллы, озын мыеклы бу татарның ак йөзе шундый матур һәм тыныч иде. Алтын кысалы күзлек аша карап торган зур күзләрдә аның әчке тирән фикерләре чагыла.

Вәисов Толстой янында өч көн булды. Өч көн буе бөек язучы әлеге сөйкемле һәм акыллы мөселман кешесе белән дөньясын онытып фикер алышты. Гайнан үзе тыйнак кына, гади генә күренсә дә, оялчан түгел. Утырып сөйләшкәндә, бераз як-якка чайкала. Русча иркен, җиңел сөйләшә.

— Кадерле туганым, — диде Толстой елмаеп, — мин Сезне күрүемә бик шат, мин Сезне көттем. Мин Казанны, татарларны өзелеп яратам. Бабам да Казанда үз вакытында губернатор булып торган. Әтиемнең сеңлесе гомер буе Казанда яшәде. Яшь чагымда Казанда алты ел тордым. Казан университетында укыдым. Гарәп телен укырга да туры килде. Болгарга да бардым. Анда манарага да менеп карадым.

Гайнан Толстойны үзенең тормыш юлы белән таныштырды. Күренеп-күренеп киткән ап-ак тигез тешләре сөйләменә аерым бер ямь бирәләр иде. Мулла Иле авылы турында да, әтисе Баһаветдин шагыйрь турында да сөйләде ул. Ә Толстойга барысы да кызык иде, таралып торган озын сакал-мыегын сыйпаштырып, йотылып тыңлады, аннары кисәк кенә әйтеп куйды: «Минем дә Сезнең шикелле, Зөя елгасында көймәдә йөзгәнем булды. Көймәдән төшеп, Зөя каласын карап йөрүләрем әле дә истән чыкмый», — дип, бер тын уйланып торды, аннары сүзне кинәт дин мәсьәләләренә борды:

— Дин — кешелек мәдәниятенең иң югарысында һәм иң өстендә булган каймактыр. Мин бөтен гомеремне вә гакылымны Аллаһы юлында фида иттем. Мөселман өчен дә, христиан өчен дә Аллаһы бер. Мөселман белән христиан бер-берсен кыерсытмыйча, бер-берсенә изгелек кылып яшәргә тиешләр. Иманлы кеше үзен сөймәгән, үзен рәнҗеткән кешене яратырга тырышырга тиеш. Әгәр дә моны булдыра алса, аның шунда ук күңеле күтәрелеп, яктырып китәчәк. Үзүзеңне төзәтә барып, һәр көн һәм һәр сәгать саен аз гына булса да яхшыра барырга тырышырга кирәк. Дөньядагы иң зур бәхет — кешеләргә изгелек кылу. Бүген эшли алырлык изге гамәлләрне

иртәгә калдырма. Кеше үзенең кылырга теләгән изгелеген эшләп бетерәме-юкмы, үлем аны көтеп тормый. Үлем беркемнең дә эшләп бетергәнен көтеп тормый. Кешенең эшләргә өлгергән гамәлләре аның язмышы була. Язмыш яхшы да, начар да була ала. Шуңа күрә дә кеше өчен дөньяда иң мөһиме — аның бүген кылган гамәле.

Толстой шкафының иң өске киштәсеннән яшел тышлы Коръәнне алды һәм, тиз генә кирәкле битен ачып, алда әйткән сүзләренә туры килә торган аятьләрне укырга тотынды, аннары тагын бер үк фикерне кат-кат тәкърарлады:

— Явызлыкка-усаллыкка бары миһербанлык, изгелек белән җавап бирергә кирәк. Берәү кемне дә булса рәнҗетсә, ул шуның белән бөтен явызлыкның тамыры булган нәфрәт хисен кабыза. Явызлыкка каршы явызлык эшләү нәфрәт хисен көчәйтә генә.

Бераздан сүз дин галимнәре, муллалар һәм поплар турында китте.

— Ислам мине көннән-көн үзенә тарта бара. Мин чиркәүгә йөрмим, чөнки поплар саф динне боза. Сафлыкны мин Коръәннән табам.

Гайнан шунда йөрәгендә йөрткән иң олы максатын ачып салды:

— Кызганычка каршы, безнең бик күп муллалар Коръән кушканча яшәми. Без Исламны сафландыру, аны һәртөрле бозулардан саклап калу өчен көрәшәбез. Коръәнне төрлечә аңлатуларга юл куелмаска тиеш. Максатыбыз — гадел һәм гүзәл җәмгыять төзү.

Толстойның бөтен йөзе яктырып китте, ул, иң кирәкле нәрсәсен тапкан кешедәй сөенеп, шкафыннан хәдисләр китабын алды һәм һәр сүзенә басым ясый-ясый укып күрсәтте: «Икейөзле галимнәр ислам нигезен какшаталар, хакыйкать юлын югалталар, алдашалар».

— Нинди әйбәт әйтелгән! — диде Толстой, балаларча шатланып. Аның соры күзләре эчкерсез елмая иде.

Толстойның бу халәте Гайнанны чиксез сөендерде.

Коръән ул — кешеләр өчен юл күрсәткеч, — диде Гайнан.

— Дөрес әйтәсез, — дип куәтләде Толстой, — мин Мөхәммәд пәйгамбәрнең сүзләреннән үземә файдалы байтак фикер таптым. Аллаһы Тәгалә барлык милләтләргә дә бертөрле карый, бар милләтләргә дә аның кануны бер. Бар милләтләр дә үзара туганнардай яшәргә тиеш. Мин ышанам: киләчәктә шулай булыр да. Аллаһыга мәхәббәт, аермыйча бөтен кешегә мәхәббәт — менә төп кануны шушы.

Өч көн сизелмичә дә үтеп китте. Сардарның (Сардар — Вәисовның псевдонимы, гарәп телендә юлбашчы дигән мәгънә бирә) Казанга китәр вакыты килеп җитте. Толстой аны: «Колач җәегез, үсегез, чәчәк атыгыз, чын күңелдән шуны телим», — дип озатып калды.

Сардар Казанга кайткач, карагруһчылар аңа этләрдәй ташландылар, ул төзегән Татар Академиясен туздырырга керештеләр. Бик авыр көннәрдә шәфкать иясе Толстойдан хат килеп төште: «Кадерле туганым Вәисов! Сезнең нинди авыр халәттә яшәвегез: мине борчуга салды. Аллаһы Тәгалә һәм Сезнең дипегез авыр хәлегезне җиңеп чыгарга ярдәм итсен. Миңа хат языгыз. Сезгә берәр ярдәм күрсәтә алмаммы, күрсәтә алсам, шат булыр идем. Сезне яратучы туганыгыз».

Вәисов Толстойга ярдәм сорап хат язды. Озак көттермичә бөек язучыдан өч мең сум акча, бераздан хаты килеп төште.

Ләкин Гайнан Толстойга чиксез рәхмәтләрен әйтә алмады: 1910 елның ноябрендә бөтен Россияне «Толстой вафат» дигән хәбәр тетрәтте. Мөбарәк тәсбих өзелде…

…Күп тә үтмәде, бөек шәфкать иясеннән мәхрүм калган Сардарны Себергә сөргенгә алып киттеләр.

Толстойның архивыннан мондый юлны да таптылар: «Мине игелекле мөселман итеп санавыгызны үтенәм».

2005

МӘКТӘП ЯШЕНДӘГЕ БАЛАЛАРГА

ОЛУГ ШӘҺӘРДӘ КУНАКТА

(1235 елның җәе)

РУХИЯ АХУНҖАНОВА,
шагыйрә, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы

ТАНЫШУ

Күрше авылның тар урамы буйлап тирә-якны күзәтеп атлый торгач, нарат йортларның берсе каршында кинәт икебез дә берьюлы туктап калдык. Ихатасы аркылы җимеш бакчасы күренеп торган бу йорт безне үзенә тартты. Юлда килә-килә сусаган энемә су эчәргә ишегалдында коесы да бар. Кыюлыгыбызны җыеп, энем Айтимер белән капка аркылы уздык.

Ишегалды уртасында сүлпән генә учак яна. Аннан шактый читтә, алма агачыннан төшкән күләгәдә, ике бала уйнап утыра иде. Башлап без исәнләштек. Алар: «Вә галәйкем әссәлам!» — дип җавап кайтардылар.

Кызчык — Тәңкәсылу, аның энесе Айдаш атлы булып чыкты. Икесенең дә өсләрендә үзләренә тап-таман гына киндер күлмәк, аякларында бизәкле күн башмаклар.

Безнең тавышны ишетепме, үз эше беләнме, өй эченнән бер хатын-кыз килеп чыкты. Исәнләшкәннән соң, мин аңардан эчәргә су сорадым.

— Мөмкин, мөмкин! — диде ул, безгә ачык чырай күрсәтеп.

Учак янына барып, боткасына кайнар су өстәгәннән соң, безнең белән кызыксынды.

Мин:

— Без — Кушнарат авылыннан. Туктаман һәм Албикә балалары. Айтимер — минем энем. Үзем Сөембикә атлы. Җамигъ мәсҗиден күрергә баруыбыз, — дидем.

Нарат бүрәнәләргә карап торган энем:

— Бер-берсенә чөй белән тоташтырылганнар, — дип әйтеп куйды.

Айтимернең зурларча сөйләшүенә исе китеп, хуҗа апа да

Ихата — койма.
Әссәламе галәйкем! — Сезгә тынычлык булсын!
Вә галәйкем әссәлам! — Һәм сезгә тынычлык булсын!
Башмак — кунычсыз аяк киеме.
Атлы — исемле.
Җамигъ мәсҗиде — җомга намазлары укыла торган мәчет.
Чөй — бер башы очлы тимер кисәге.
Терсәкле — бөгелешле.
Олан — бала.
Калач — ак күмәч (ипи).
Җәйләү — җәйге тору урыны.
Акшарлау — ак балчык белән буяу.
Сәке — идәннән ярты метр чамасы күтәртеп җәйгән калын такталардан гыйбарәт утыру-яту урыны

ботка болгаткан җиреннән сүзгә кушылды. «Бүрәнәне терсәкле тоташтыру җае да бар», — диде ул һәм агач өйне мактарга керешге.

— Ылыслы агачтан салынган йортның һавасы иркен, оланнар. Яз көне бер кат юып-җыештырып чыгарсаң, яңа салган өй шикелле була. Шул чисталыкны саклар өчен, җәй көне ашсуны да шушында, ишегалдында әзерлибез. Калач кына мичтә пешә. Тормышыбызның яртысы җәйләүдәге кебек. Җәен монда сәүдәгәр, һөнәрче гаиләләре генә кала. Башкалар кырларда иген үстерәләр, болында терлек көтәләр...

Ботка пешеп өлгерде. Хуҗа апа барыбызны да үзе белән чакырды. Ләкин без капкага таба атламакчы булдык.

— Аштан олы булмагыз. Әйдәгез, әйдәгез...

Без, аңа ияреп, өйгә кердек. Өй эче үзенә күрә җыйнак һәм тыйнак кына иде. Кышын — җылы, җәен ямь биреп торучы мич тигез итеп акшарланган. Мич алдында учак көлен саклау өчен чокыр ясалган. Түр якта такта сәке. Аның өстенә пөхтә итеп урын-җир өеп куелган. Янәшәдә ике агач сандык. Икесенә дә җиз калайдан ясалган бизәкләр беркетелгән. Диварга кыска сүрәләр язылган матур шәмаил эленгән. Идән-сәке чиста итеп юылган.

— Ишек катында тормагыз. Түргә узыгыз. Әйдәгез, әйдәгез...

— Ярар, апа...

— Сусылу апагыз булам мин. «Сусылу апа» диярсез.

— Ярар, Сусылу апа...

Кулларыбызны сабынлап юып, чаршау белән бүлеп алынган почмакка — «аш бүлмәсе»нә уттек. Һәрберебез, тезләнеп, өчаяклы кечкенә өстәлчекләр каршына — идәндәге киезгә уңайлап утыр-

(бөтен түрне алып торган урын).
Сандык — әйбер саклый торган зур озынча тартма (ачылма өсле, йозаклы).
Дивар — стена.
Шәмаил — рам эченә язып куелган дини текст.
Ишек катында — ишек янында.
Чаршау — иңле тукымадан тегелгән зур пәрдә.
Киез — йоннан басып эшләнгән тыгыз материал.
Бисмиллә — эшне башлар алдыннан яки ашарга утырганда әйтелә: Бисмил-ләһир-рахмәнир-рахим.
— Дөньяда һәркемгә шәфкатьле, ахыйрәттә иман әһелләренә генә рәхимле Аллаһ

дык. «Бисмиллә»сен әйтеп, Сусылу апа башта — безгә, аннары ике баласына тары боткасы салынган агач савытлар сузды, агач кашыклар өләште. Шуннан соң бер зур түтәрәм калачны дүрт өлешкә кисеп, алдыбызга куйды.

— Кайнар килеш ашамагыз, — диде хуҗа апа, безне кисәтеп, — бераз суына төшсен. Кайнар ризык сәламәтлеккә зыянлы.

Ашаганда, беребез дә сөйләшмәдек. Тары боткасын яраттык. Колмак кулланып пешерелгән ипи дә бигрәк тәмле була шул. Үлән чәен бал каба-каба эчтек. Шуннан соң дога кылдык та, хуҗа ападан канәгать булуыбызны белдереп, табын яныннан кузгалдык. Юынгычтан су агызып юынып алдык.

Йортның хуҗасы тимерче Ирҗемәс абый өйдә булмаса да, без «хатын-кызлар ягы»на кереп утырдык. Энемә тәмам ияләнеп җиткән Айдаш аның алдына шатранҗ сыннары тезеп куйды. Кош кыяфәтле балчык сыбызгысын да күрсәтте. Әтисенең «Өйдә сызгырырга ярамый, янгын чыга» дип кисәткәнен онытмаган идеме, сызгыртмыйча, аны урынына куйды һәм нигәдер өстәл өстендәге шәмгә карап алды.

Тәңкәсылу да, төреп куйган җиреннән алып, сөяк कураен күрсәтте. Ләкин курайда уйнамады. Мин ишетелер-ишетелмәс кенә болгар халык көе «Зиләйлүк»не көйләдем. Кушымтасына Тәңкәсылу да кушылды.

Җил-җил, җилләр исә, Зиләйлүк,
Җил-җил, җилләр исә, Зиләйлүк,
Зиләйлүкнең биле нәзек, биле нәзек,
Зиләйлүкнең беләгендә беләзек.
Зиләйлүкнең биле нәзек, биле нәзек,
Зиләйлүкнең беләгендә беләзек...

Без китәргә дип болдырга чыктык. Яшелчә бакчасы ягыннан кулына кыярлар тотып килүче Сусылу апаны күргәч кенә, уйларымнан арындым. Ул безгә бодай калачы белән урман чикләвеге янына күчтәнәч итеп кыяр да өстәргә уйлаган икән.

Сусылу апа чикләвек салынган төенчекне энемнең кулына тоттырды, ә калач белән кыярлар төрелгәнен миңа бирде. Хуҗа апа безнең әнкәй кебек бик юмарт икән.

Безне озатып калырга дип, Тәңкәсылу белән Айдаш та баскыч алдына чыгып бастылар.

— Хөзер һәм Ильяс пәйгамбәрләр юлдашыгыз булсын, — диде Сусылу апа, икебезнең дә башыбыздан сыйпап.

Без: «Амин», — дидек тә, үзләренә дә иминлек теләп, юлга кузгалдык.

«АК ТИРӘК, КҮК ТИРӘК»

Без, Сусылу апалар белән саубуллашып, күңел ачу урынына килеп җиткәндә, малайлары, ике рәткә тезелеп, уеннарын башларга әзерләнәләр иде.

исеме белән.
Түтәрәм — дүрттән бер өлеш, чирек.
Дога — теләк, теләү, ялынып сорау, үтенү.
Шатранҗ — шахмат.
Болдыр — өйалды баскычы.
Төенчек — кечерәк төен (эченә төрле әйберләр салынып, оч-очлары бергә бәйләнгән яулык, тукыма кисәге).
Хөзер һәм Ильяс пәйгамбәрләр — Аллаһы Тәгаләнең җирдә калдырылган илчеләре.
Амин — Шулай булсын!

— Албарс, минем төркем әзер! — диде какча гәүдәле малай.

— Афәрин, Алпак!

Албарсның җавабы кыска булды.

— Албарс, минеке дә әзер! — диде шундый ук чандыр гәүдәле икенче малай.

— Афәрин, Әрдуан!

Иптәшләренә уенның барышын аңлатып бетергәч, башларга фәрман бирер алдыннан, Албарс тагын: «Дыңлагыз!» — диде. Тамаша кылырга җыенучылар берьюлы тынып калдылар.

— Ак тирәк! — диде Алпак, уенны башлап.

— Күк тирәк! — дип каршы төште Әрдуан.

— Күктә, күктә ниләр бар? — дип сорадылар Алпакныкылар, кызыксынып.

— Җофар белән шикәр бар, — дип җавап бирде Әрдуан ягы.

— Көкләш, җофарыңны бир миңа! — дип таләп итте берсе.

— Аван, ник бирәем мин сиңа? — дип турсайды икенчесе.

— Шикәреңне бир миңа! — диде Алпак.

— Ник бирәем мин сиңа? — дип каты торды Әрдуан.

— Кая миңа хан юлы? — дип сорады, җитди кыяфәт чыгарып, өченчесе.

— Байдык, менә сиңа хан юлы, — диделәр Әрдуанныкылар, җитәкләшкән кулларына ишарәләп.

— Сыртлан, хан юлында елан бар, — диделәр Алпакныкылар, куркуларын белдереп.

— Кылычың булса, кый да чык! — дип боерды Сыртлан.

«Дошман чылбыры»н өзәргә Алпакның үзен сайладылар. Ул, бөтен көченә йөгереп барып, Көкләш белән Сыртланны ике якка аерып чыгып китте һәм, «Безләр!» дип мактанып, каршы төркемдәге «гаскәри»не үзләренә китереп кушты.

Мин исә, Алпакка карап, сәргаскәрлек осталыгына ия булган Сәлим һәм Илһам ханнарны уйлап куйдым. Янымда басып торган энемнең колагына: «Һөҗүмдә хәйлә дә, көч тә кирәк», — дип пышылдадым.

Малайлар уеннарын дәвам иттеләр.

Энем дә катнашып уйнарга теләде. Ләкин мин:

— Болай булгач, Җамигъ мәсҗиденә бүген барып җитә алмыйбыз икән, — дигәч, үзенең уеннан кире кайтты — карышмады. Һәм без шәһәргә таба китеп бардык.

Какча, чандыр — ябык.
Афәрин — «бик шәп», «бик яхшы», «яшә» мәгънәсендәге хуплау сүзе.
Фәрман — боерык.
Дыңлагыз — тыңлагыз.
Тамаша кылу — кызык итеп яки дикъкать белән карап тору.
Җофар — хуш исле су җәнлеге (выхухоль).
Турсаю — ризасызлыктан авыз яки ирен бүлтәю.
Ишарәләү — кулны, башны хәрәкәтләндереп, нәрсәгә дә булса күрсәтү.
Кыю — өстен кисү; кистереп алу.
Безләр — без.
Гаскәри — армиягә мөнәсәбәтле.
Сәргаскәр — гаскәр, армия башлыгы.
Хан — ил башлыгы.
Һөҗүм — өскә ташлану, дошман өстенә ыргытылу; атака.

ТЫШКЫ ШӘҺӘРДӘ

Ниһаять, еракта Биләрнең тышкы шәһәр ныгытмалары күренде. Каршыбызда калкып чыккан зу-ур шәһәрне күреп аһ иттек.

Энем:

— Әллә-лә! — дип тел шартлатты. — Апа, апа, кара әле, күрәсеңме? — дип, җиңемнән тартты.

Мин:

— Ә күрәсеңме син әнә теге манарадагы сакчыларны?! Кул-

Биләр (Бүләр) — урта гасырның (X-XIII йөзләр) Идел буе Болгар дәүләтендәге шәһәр.
Асылма — асып куела торган.
Олаучы — олау йөртүче.
Дилбегә —

ларына нинди озын сөңге тотканнар, — дип, шәһәр диварларына төртеп күрсәттем.

Өч кат дивар белән әйләндереп алынган тышкы шәһәргә узу өчен, асылмалы күпер янына килеп бастык. Безнең бәхеттән, олаучылар да бар. Арба түрендә дилбегә тотып утырган бер абзый үзе башлап безгә сүз катты:

— Апалы-энеле бу мосафирлар ханбалыкка баралармыни?

— Җамигъ мәсҗиден күрергә барабыз, абзый.

— Ә-ә-ә, шулаймыни?! Юлдашлар икәнбез, алайса. Без дә шуның янындагы йортка барабыз ич. Утырыгыз, әйдә, утырыгыз.

Олаудагы ике бала янына без дә менеп утырдык.

Безнең җайлап урнашуыбызга ышангач, ул сүзен дәвам итте:

— Юлчының юлда булуы хәерле. Шулай бит, углым Белемчәк?! Синеңчә ничек, кызым Айсылу? Кояш баеганчы, әйләнеп кайтасы да бар. Асылма күперне күтәреп, капкага бик элеп куелганчы...

Өстенә яшькелт казаки, башына такыя кигән бу мөлаем абзый Теләй атлы икән. Үзе белән таныштыргач, ул безнең ни атлы булуыбыз, нигә юлга өлкәннәрдән башка чыгуыбыз белән кызыксынды.

Мин:

— Энем — Айтимер, ә үзем Сөембикә атлы. Өйдәгеләр шәһәр күреп кайтырга үзләре рөхсәт бирделәр. Энемне миңа ышанып тапшырдылар, — дидем. «Без — Кушнарат авылыннан. Туктаман һәм Албикә балалары», — дип тә өстәдем.

— Елга буенда яшисез икән. Су коенып үсәсез инде, алайса. Ә минем балалар, Белемчәк белән Айсылуны әйтүем, Салкын Чишмә дигән авылның шифалы суын эчеп үсәләр...

Арба тәгәрмәче келтер-келтер тәгәри. Без тирә-якны күзәтәбез. Монда йортларның барысы да агачтан салынган. Ниргәсенә юан имән бүрәнә кулланганнар, диварын нараттан күтәргәннәр. Түбәләре такта белән ябылган. Йорт аралары кысан түгел.

— Эчке шәһәрдә яшәүчеләрнең җәйге йортлары да биредә урнашкан, — диде Теләй абзый, озакка сузылган тынлыкны бүлеп. — Алар янында яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчалары...

Чыннан да, йортлар янында алмагач, чия һәм шомырт агачлары, кура җиләге куаклары үсеп утыра. Әнә ерракта аерым-аерым йөргән ат, сыер көтүләре күренә. Бодай, борай, борчак, ясмык, тары, арпа басулары җәйрәп ята.

Без, арбадагылар, бер көйгә келтер-келтер барабыз. Юл читендәге зифа каеннар, биек усаклар безне озатып калалар.

— Әй-йе-е, — дип сузды Теләй абзый, эчке бер хушлану белән, — безнең гүзәл табигатькә гарәп сәяхәтчесе әл-Гарнати да сокланган, диләр. Бездәге сәхрә тагын кайда бар?!

— Биләргә килгәнмени ул?!

— Әйе, Биләргә Әбү Хәмид әл-Гарнати килгән.

— Кайдан? — диде гаҗәпләнгән энем.

—Испаниядән. Әбү Хәмид — «Хәмиднең әтисе» дигәнне белдерә. Гарнати — аның туган җире.

җиккән атны идарә итә торган озын каеш тасма (йөгәнгә тоташтырыла).
Мосафир — юлчы.
Ханбалык — башкала.
Олау — атлы транспорт.
Углым — улым.
Бик — йозак.
Казаки — озын камзулга (күлмәк өстеннән кия торган җиңсез һәм якасыз кыска өс киеменә) охшаган, ләкин җиңле һәм кечерәк кенә утыртма якалы өс киеме.
Такыя — түбәтәй сыман баш киеме.
Ниргә — нигез, фундамент.
Борай — бодайның бер төре.
Хушлану — күңел булу, канәгатьләнү.
Сәхрә — бик матур күренешле җәйге табигать; чәчәкле, саф һавалы болын.
Әбү Хәмид әл-Гарнати (1100-1170) — дин белгече, гарәп сәяхәтчесе.
Ягъкуб бине Ногман (XI-XII йөзләр) —болгар тарихчысы, казый.
Риваять — борынгылардан, буыннан-буынга сөйләнеп (күчеп) килгән хикәя, тарих.
Һөнәрханә — мастерская.
Тимерче учагы — горн.

— Әллә-лә! — диде Айтимер.

Әйе, гарәп сәяхәтчесе безнең илгә ике мәртәбә килгән икән. Ягъкуб бине Ногман атлы казыйдан болгарларның тарихын, риваятьләрен язып алган. Илегез мин ишеткәннән бик күпкә шәп дип мактаган. Җиләк-җимешләрнең төрлелегенә, күплегенә сокланган. Мондый байлык башка бер җирдә дә юк, дип әйткән.

Җимешле бакчалар артта калып, юлыбызда төрле-төрле һөнәрханәләр очрый башлады. Түгәрәк тимер баш киеменә охшап торганына ымлап, Теләй абзый:

— Менә монысы — бакыр эретү миче, — диде. — Монда бакыр һәм аккургаш эретмәсе белән эш итәләр. Осталар таштан ясалган махсус калыпка кайнар эремәне агызып, йозак һәм көзгеләр ясыйлар.

Энем Айтимер тимерче учакларына дикъкать белән карап барды. Әткәйнең безгә тимерчелек һөнәрханәсе турында сөйләгәне бар иде, энем шуны исенә төшергәндер.

Һөнәрчеләр арасында иң дәрәҗәлеләре тимерчеләр, ди. Ни өчен дигәндә, алар кирәк-яраклар, эш һәм яу кораллары ясыйлар. Шуңа күрә иң кирәкле кешеләр булып саналалар икән.

КӘРВАНСАРАЙ

— Тышкы шәһәрдәге атаклы кәрвансарай менә шушы инде! — дип, Теләй абзый гаять зур кирпеч бинага ишарә ясады. — Кече Чирмешән елгасының борынгы атын йөртә ул Кәрвансарай. «Дәү Шир» дип атала.

Без кызыксынып киттек. Теләй абзыйның тәртип белән сөйләвен көтмәстән, аңа бер-бер артлы сорауларыбызны яудыра башладык.

— Бу кәрвансарайда кемнәр яши?

— Ерак иллардән килгән сәүдәгәрләр урнашкан биредә. Алар яши торган мосафирханә биек койма белән әйләндереп алынган.

— Алар үз өйләрендәге кебек яшиләрме?

— Әйе. Һәрберсенә аерым бүлмә бирелгән. Аш-су әзерләү бүлмәсе дә бар. Мунчасы бер дигән! Аның миче ишегалды ягыннан ягыла. Кайнар һава агымы идән астындагы махсус торбалар буйлап уза. Кыскасы, бөтен уңайлыклар тудырылган.

— Алар монда озак торалармы?

— Алып килгән сәүдә малының кайчан сатылып бетүенә карап…

— Алар нәрсәләр саталар соң?

— Кыйммәтле тукымалар, затлы келәмнәр, керәч чынаяклар… Алар сата торган әйберләрне санап чыгу мөмкин түгел. Барып күрергә кирәк, — дип, Теләй абзый безне үзе белән кәрвансарай алдындагы зур базарга әйдәде.

Базар киң мәйданны биләп алган. Андагы халыкны санап бетерерлек түгел. Төрле-төрле тавышлардан базар умарта күче кебек гүләп тора.

Без Теләй абзыйга тагылып барабыз.

Кәрвансарай — стеналар белән әйләндереп алынган, ныгытылган кунакханә (чит ил сәүдәгәрләре яшәгән).
Ишарә — ым, мимика.
Борынгы — бик күптәнге.
Дәү Шир — Дәү Дон.
Мосафирханә — юлчылар өчен номерлар; гостиница.
Сәүдә малы — сатыла торган әйбер.
Керәч — фаянс.
Аршын — метр системасы кертелгәнгә кадәрге озынлык үлчәү берәмлеге, 71 см.га тигез.
Туар — товар; мал.
Бадәм — миндаль.
Калкан — борынгы гаскәриләрнең кылыч, сөңге

Әнә бер урында ефәк тукыма саталар. Айсылу белән икебезнең дә күзләр шул якта. Кулына аршын тоткан гарәп сәүдәгәре:

— Зираг, зираг, — дип кабатлый.

Теләй абзый безгә аның бу сүзен «тукыма үлчәү берәмлеге» дип төшендереп бирде.

Этелә-төртелә атлый торгач, тактадан корылган кибет сыман бер урынга барып чыктык.

— Монда саклану кораллары сатыла, — диде Теләй абзый, малайларга дәшеп.

Барыбыз да, кызыксынып, хәрби туар карарга керештек. Әнә теге вак бөҗралардан эшләнгән күлмәк «көбә» дип атала икән. Аның янәшәсендә күкрәк һәм арка япкычлардан торган күлмәкләр дә бар. Алары ян якларыннан һәм җилкәләрдән каптырылып куела, ди.

Безнең, бер ноктага төбәлгәндәй, кабарынкы түгәрәк һәм бадәмсыман калканга озаклап карап торуыбызны күреп, сәүдәгәр абзый:

— Бу калкан — атлы гаскәри өчен, — диде.

Күзләребездәге кызыксыну чаткыларын кибет хуҗасы тиз күреп алды. Бит каплавычлы хәрби баш киемен хәтта киеп карарга да рөхсәт итте. Аннары:

— Монысын, гадәттә, атаклы гаскәриләр генә кия, — дип өстәде.

Ачык йөзле, киң күңелле сәүдәгәрдән барыбыз да канәгать калдык.

Кинәт Белемчәк әтисенең кайчандыр биргән вәгъдәсен исенә төшерде бугай:

— Әткәй, әткәй! Ак кашкага асылмалы бизәкләр беркетелгән йөгән сатып алыйк әле, — диде.

— Алырбыз, улым, алырбыз… Көмештән эшләнгәнен алырбыз. Кәрвансарайга кергәч, таныш сәүдәгәр абыеңнан үзең сайлап алырсың. Килештекме? — дип тынычландырды аны Теләй абзый.

Әтисенең сүзеннән Белемчәкнең йөзе кояштай балкыды.

Базарда тагын аны-моны караштырып бераз йөрүгә, Белемчәк, кәрвансарай ягына ымлап, әтисенең җиңеннән тарта башлады.

Теләй абзый кәрвансарай юлына борылды. Без, тезелешеп, барыбыз да аңа иярдек.

Менә мәһабәт кәрвансарай. Аның түбәсе гөмбәз сыман. Кунакханәгә алып керә торган юлга тигез итеп кирпеч ватыклары һәм вак ташлар түшәлгән. Ишегалдында кое бар. Ул имән агачыннан буралап ясалган. Теләй абзый, беренче эше итеп, шул кое янындагы баш-башына такта кисәге кадаклап ясалган улактан Ак кашкага су эчерде.

— Су — яшәү чыганагы. Аны күп сарыф итү гөнаһ санала, — диде ул, безгә төбәп әйткәндәй.

Кунакханәнең дивары калын. Баскыч төбеннән ишеккә кадәрге аралыкның түшәме матур итеп, көймәләп эшләнгән.

«Бисмиллә»сен әйтеп, бина эченә иң элек Теләй абзый атлады.

кебек салкын кораллардан саклану өчен тактадан яки металлдан махсус эшләнгән кул сугышы коралы.
Йөгән — җигеп, атланып йөрүдә файдалану өчен, атның башына кидерә торган, каештан ясалган тезгенле җайланма.
Мәһабәт — сокланырлык матур; зур.
Гөмбәз — кабарынкы формада ярымшарсыман итеп эшләнгән түбә; купол.
Кунакханә — кунак йорты.
Буралау — бура белән әйләндереп алу.
Улак — суны агызу өчен агачтан ясалган озынча җайланма.
Ак кашка — маңгаенда ак тап булган ат.
Сарыф итү — чыгымга тоту, файдалану.
Гөнаһ — гаеп эш, язык; әдәп-әхлак кагыйдәләрен, дини кануннарны үтәмәү.
Аралыкның түшәме — ике нәрсә арасындагы ачыклыкның көймәләп эшләнгән а́ркасы.
Урынлашу — урнашу.
Дарчин — тропик лаврлар семьялыгыннан булган бер төр агачның киптерелгән кайрысы; корица.
Җәһәт — тиз генә, бик тиз.

— «Бисмиллә»гезне әйтегез. Ишек бусагасына басмагыз. Уң аяктан атлап керегез, — дип, үзе артыннан безне дә чакырды.

— Яхшы, әткәй…

— Яхшы, Теләй абзый…

Барыбыз да эчкә уздык. Теләй абзый безгә тәрәзә буендагы утыргычларга утырырга кушты. Аннары:

— Өлкәннәргә үзегез башлап сәлам бирегез. Кешеләргә төртеп күрсәтмәгез. Берүк шаулашып утырмагыз. Тыныч тавыш белән генә сөйләгез, — дип өстәде.

— Яхшы, әткәй…

— Яхшы, Теләй абзый…

Теләй абзый, Белемчәкне ияртеп, таныш сәүдәгәренең бүлмәсенә юнәлде. Без урыннарыбызда утырып калдык.

Керүче-чыгучы юк. Бик бирелеп, бинаның безгә күренгән өлешен күздән кичерәбез.

Кәрвансарайның эчке ягы да күз явын алырлык матур итеп эшләнгән. Дивар, кытыршы урын калдырмыйча, тип-тигез итеп сыланган. Аңа дарчин төсендәге табигый буяу белән төрле бизәкләр төшерелгән.

Белемчәк белән Теләй абзый озак юанмадылар. Кулына искиткеч матур йөгән тоткан Белемчәк шатлыгыннан, тып итеп, безнең каршыга килеп басты. Чыннан да, йөгән каешына көмеш бизәкләр беркетелгән иде. Теләй абзыйның да таныш сәүдәгәре белән саубуллашкан тавышы ишетелде.

Без кәрвансарайның ишегалдына чыгып бастык. Белемчәк, Ак кашкага эндәшеп, йөгән тоткан кулын болгады.

Җыенысыз бергә кое янына килеп, Теләй абзый чиләктән салып торган су белән җәһәт кенә кулларыбызны, битләребезне юдык та бераз капкалап алырга утырдык.

Дәвамы алдагы саннарда

Әдәбият

1. Әхмәтьянов Р. Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2003.
2. Давлетшин Г.М., Хузин Ф.Ш. Булгарская цивилизация на Волге. — Казань: Татар.кн.изд-во, 2011.
3. Дәүләтшин Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1999.
4. Измайлова С., Измайлов И. Булгарское вооружение X-XIII вв. Буклет.
5. Ислам (белешмә-сүзлек). — Казан: Татар. кит.нәшр., 1993.
6. Мифтахов З.З. Курс лекций по истории татарского народа. — Казань, Издательство «Дом печати», 1998.
7. Мөхәммәтшин Җ., Вәлиев Р. Бөек Болгар — болгар-татар цивилизациясенең һәйкәле. — Анкара, 2000.
8. Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре сүзлеге. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1981.
9. Хәмзин К.З., Мәхмүтов М.И., Сәйфуллин Г.Ш. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1965.
10. Хуҗин Ф. Биләр — Олуг шәһәр. — Казан: «Печатный Двор» типографиясе, 1997.
11. Хуҗин Ф. Җир астында серләр бар. — Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2008.
12. Хузин Ф. Биляр — Великий город. — Казань: Татар.кн.изд-во, 2007.
13. Хузин Р., Измайлов И. Волжская Булгария глазами живописца и историка. — Казань: Заман, 2011.
14. Яхин Ф. Пәйгамбәрләр тарихы. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1992. ■

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНӘ

Сәхифәне филология фәннәре докторы ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

ИСЛАМ ДИНЕ ҺӘМ ТУКАЙ. Тукай иҗатын татар халкы тарихында, рухи дөньясында, көнкүрешендә зур урын тоткан ислам диненнән аерып карау мөмкин түгел. Аның әсәрләрендә «Ходай», «Алла», «Тәңре» образ-сурәтләре әледән-әле очрап тора. 1909 елда язылган «Васыятем» дигән шигыре исә Тукай тормышы һәм иҗатының кыйбласын ачыктан-ачык аңлата: *«Әһле тәкфир бер гаҗәпләнсен, күреп актык сүзем: / Күр, нә рәсмә тулган иман берлә Корьән садремә».* Гомере буе ул иманына тугры кала. Дини, корьәни сурәтләр, ахырзаман күренеше, бәйрәмнәр, гыйбарә-афоризмнар аның иҗатын нык сугарган. Ә Мөхәммәд пәйгамбәрнең илаһи сурәте аның шигъри юлларында ачык әйтеп тә, яшерен ишарә белән сиздереп тә еш очрый. Бу бөек сурәт Тукай өчен гел изге булып күңелендә яшәгән, шигъриятендә һаман яши. Аның сурәте шагыйрьнең «Пәйгамбәр» (1909) дигән шигырендә дә бар, җәя эчендә «Лермонтовтан үзгәртелгән» дип бирә. «Туган авыл» (1909) дигән атаклы шигырендә ул, пәйгамбәрне бөек тә, фаҗигале дә шәхес дип белеп, авыл мәдрәсәсендә алган мәгълүматы турында яза: *«Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган, / Шунда әүвәл Корьән аятен укыган; // Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәдне, / Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган».* Шагыйрь пәйгамбәрнең тормышына багышланган кыйссалардан үз иҗатына шактый эпизодлар кертә, могҗизаларын тасвирлый.

Корьәннең «Мигъраҗ» (1910) дип аталган сүрәсендә (17 нче) Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккәдәге әл-Хәрам мәчетеннән Кодестәге (Иерусалимдагы) әл-Әкъса мәчетенә Буракка атланып ясаган төнге сәяхәте, Аллаһ белән сөйләшү өчен күккә ашкан көне — ләйләт әл-Мигъраҗ турында бәян ителә. Тукайның «Мигъраҗ» (1910) шигыре, исеменнән үк аңлашылып тора, әнә шул сюжетка корылган, анда пәйгамбәр образы бик җылы буяуларда, тирән ихтирам белән иҗат ителгән. Бөтен иҗатында дини-корьәни сурәтләрне бик мул кулланган Тукайның «Мигъраҗ»ында исә алар бигрәк тә күп («Пырак» — Бурак, мәляикләр — фәрештәләр, Гарше, мөнкир һ.б.). Әсәрдә пәйгамбәрнең Аллаһ каршында сәҗдәгә китүе үтә җитди тонда тасвир ителә: *«Күрде Аллаһны пәйгамбәр, сәҗдә кыйлды, баш иде; // Ушбу җир булды бөтен мәсҗедләрең дә мәсҗеде».*

Тукайның ислам дине әһелләренә карашы исә шактый катлаулы. Шиһабетдин Мәрҗанине «милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт» дип санаган Тукай кайбер «җаһил мулла»ларның тискәре сыйфатларын еш кына үтә зәһәр тәнкыйть утына тота, ислам диненең сафлыгын саклауны җан ачысы белән таләп итә. Мөхәммәд пәйгамбәргә исә аның мөнәсәбәте һәрчак ихтирамлы. «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә дин тарихын өйрәнгән татар зыялысы буларак, Тукай аның бөек тарихи шәхес икәнен әйбәт белгән.

Корьәннең 97 нче сүрәсенә ияреп, мөселманнар өчен изге ай — рамазан аеның 26 нчы көнендә Мөхәммәд пәйгамбәргә беренче тапкыр Корьән

иңдерелә башлауга багышлап, Тукай 1911 елда «Кадер кич» дигән шигырь иҗат итә. Анда бу көннең әһәмияте, изгелеге, теләкләр кабул булуы турында уйлануы бик тәэсирле детальләр белән бәян ителгән: *«Бу кадер кич елда бер кич — барча кичләр изгесе; // Сафланыр таптан бу кич мөэмин күңелләр көзгесе»*. Тукайның ислам диненә, мөбарәк дини бәйрәмнәргә ихтирамы һәрчак сизелә. Гает бәйрәмен котлап язган «Бәйрәм бүген» (1908) исемле шигыре исә халыкның үз әсәре булып әверелгән, хәтта аны, совет чорында дини рухтагы әсәрләр юкка чыгарылгач та, сәхнәләрдән сөйләп, җырлап килделәр, мәктәпләрдә совет бәйрәмнәрендә дә башкардылар. Чөнки ул гимн ритмында яңгырый, күтәренке рух белән, шатлык белән тулышып тора: *«Бар күңелләлек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген. / Нәрсәдән бу? — Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!»*. «Бәйрәм бүген!» һәр икеюллы строфада кабатланып (рәдиф вазифасын үти), якты хисләрне, бәйрәм атмосферасын аеруча көчәйтә.

Тукай Коръәнгә чын ихтирам белән карый. Аның әсәрләрендә мондый мөнәсәбәте ачык чагылуга дәлил итеп «Тәэссер» (1908) дигән шигырендәге менә бу юлларны да китерергә була: *«Әгәр янсам каты хәсрәт вә кайгының мин утында, // Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗаиб сүрә Коръәннән, — / Газаплар мәгънәви бер кул илән алынадыр җаннан. // ... Ходайа! Син тыйган эшләр тәмам әкътагъ вә әбтәр, дим; / Иям башым сәҗдәгә: «Аллаһе хак! Аллаһе әкбәр!» — дим»*. Намаз укучының, сәҗдәгә баручы кешенең халәтен дини гамәлләрне үзе үтәгән кеше генә шулай нечкәләп аңлата ала. Бу әсәрләрнең күбесе атеизм хөкем сөргән совет чоры басмаларында дөнья күрмәде. (Шагыйрьнең 1975-1977 елларда басылып чыккан дүрт томлы әсәрләре арасында «Тәэссер» юк.) Чөнки Тукайның динчеләргә каршы көрәшен дингә каршы итеп күрсәтү атеистик тәрбиягә ярдәм итәргә тиеш иде.

Шагыйрьнең милли гимн булып әверелгән «Туган тел» (1909) исемле атаклы шигырен төрле җыеннарда, милли рухлы мәдәни чараларда татарлар дәррәү аяк өсте басып, күз яше белән җырлыйлар. Соңгы ике юлы үзәк өзгеч, әмма өметле булып яңгырый: *«И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам! / Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!»*.

Чыганак

Тукай Г. Әсәрләр. Академик басма: 6 томда. — I т. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. — Б.221, 267; Тукай Г. Әсәрләр. Академик басма: 6 томда. — II т. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. — Б.9, 55, 116, 197.

Әдәбият

Хисамов Н. Тукайны төшенү юлында. — Казан, 2003. — Б.34; Садыйкова А.Х. Габдулла Тукай иҗатында борынгы дини әдәбият традицияләре // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни бәйләнешләр. — Казан, 2001. — Б.40-42; Исмәгыйлев Н. Иман белән Коръән тулган садремә // Дин вә мәгыйшәт. — 2012. — №17. — Б.1-4; Габдулла Тукай әсәрләре. Сүзлек-белешмә. — Казан, 2012. — Б.136-137; Хайруллин Г. Ислам и Тукай // Материалы конф.(Уральск, 17.05.2011). — Уральск, 2011. — С.20-24.

Айсылу Садыйкова,
филология фәннәре докторы

Бәйрәмнәребез

Минем илдә синең илгә
изгелек тели һәркем.
— Йортыңа иминлек, кардәш,
әссәламегаләйкем!

Сажидә Сөләйманова

КОРБАН ГАЕТЕ

НИЯЗ ХӘЗРӘТ САБИРОВ,
Үзәкләшкән дини оешма —ТР мөселманнары Дания нәзарәте рәисе, Мөфти урынбасары

ӘГҮҮЗҮ БИЛЛӘӘҺИ МИНӘШ-ШӘЙТААНИР-РАҖИИИМ. БИСМИЛЛӘӘҺИР-РАХМӘӘНИР-РАХИИИМ. ӘЛХӘМДҮЛИЛЛӘӘҺИЛ ЛӘЗИ ҺӘДӘНӘ ЛИЛ-ЙИМӘН ВӘССАЛӘӘТҮ ВӘССӘЛӘӘМҮ ГАЛӘӘ РАСҮҮЛИҺИ МҮХӘММӘДИН СӘЙЙИДИЛ ӘНӘМИ ҮӘ ГӘЛӘӘ ӘӘЛИҺИ ҮӘ ӘСХАБИҺИ ӘҖМӘГИИН.

Безнең күңелләребезне иман, Ислам нуры белән нурландырган Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләгә чиксез хәмед һәм шөкраналарыбыз булса иде. Бөтен мәхлукатның хәерлесе булган, безгә бу дөньяда һәм ахирәттә бәхетле булырга өйрәткән сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вәссәлам хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Сезне динебезнең иң күркәм сәламе белән сәламлим: әссәламегаләйкем үә рахмәтуллаһи үә бәракәәтүһ!

Елга бер мәртәбә була торган бөек бәйрәмебез — Корбан гаете барчабызга мөбарәк һәм хәерле булсын! Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә ил-көннәребезгә, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык, күңелләребезгә тәүфыйк-һидаять биреп, һәркайсыбызга хәерле һәм бәрәкәтле тормышлар насыйп итсен. Мөкатдәс Корбан бәйрәме көннәрендә ихлас күңелдән изге гамәл-гыйбадәтләр кылып, корбаннарыбызны чалып Аллаһы Тәгаләнең иксез-чиксез рәхмәтлренә барчабызга да ирешергә насыйп булсын!

Хөрмәтле мөселманнар! Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә ышанып, Аның кушканнарын үтәп, тыйган гамәлләреннән тыелып яшәү — кешенең төп вазифасы булып тора. Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә кешене бу дөньяга нәкъ менә шуның өчен җибәрде дә. Һәрбер мөселман үзенең Раббысына омтылырга, Аны искә алырга, һәрбер гамәлне Аның ризалыгы өчен кылырга тиеш, чөнки ул бары тик Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте аркасында яши. Кайвакыт кеше, үз Раббысын онытып, хаталар, гөнаһлы гамәлләр кыла, үзен һәлакәт чокырына ташлый, калебен каралта. Шушы гөнаһлардан, хата-кимчелекләрдән пакьләнү, Аллаһы Тәгаләгә якынаю юлларының берсе — хаҗ гыйбадәте. Бөтен Ислам галимнәренең уртак фикере буенча, хаҗ гыйбадәте һәрбер хәлле мөселман өчен фарыз (тиешле) гамәл булып тора. Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

وَلِلّهِ عَلَى النَّاسِ حِجُّ الْبَيْتِ مَنِ اسْتَطَاعَ إِلَيْهِ سَبِيلاً

«Мөмкинлекләре булган кешеләрнең Аллаһы Тәгалә каршындагы бурычлары — Аның йортына хаҗ кылу» («Гыймран» сүрәсе, 97 нче аять).

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенең бер хәдисендә әйткән: «Әгәр берәү хаҗ кылып, бозыклык кылмаса, өенә анасы тудырган көндәге кебек гөнаһсыз булып кайтыр», — дигән (Бохари, Мөслим, Насаи).

Корбан бәйрәмендә, ягъни зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә хаҗиларыбыз хаҗ гыйбадәтенең төп гамәлләрен тәмамлап, ихлас күңелләре белән Кәгъбәтуллага юнәлеп тәлбия, ягъни «Ләббәйкәллаһүммә ләббәйк. Ләббәйкә ләә шәриикә ләкә, ләббәйк! Иннәл-хәмдә вән-нигъмәтә ләкә вәл-мүлк, ләә шәриикә ләк!» («Йә Аллаһ, менә мин Синең каршыңда! Менә мин Синең каршыңда! Менә мин Синең каршыңда! Сиңа иптәш булырлык бернинди дә зат юк! Барча мактау Сиңа гына, барлык нигъмәт һәм хөкем Синең кулыңда гына! Сиңа иптәш булырлык бернинди дә зат юк!»), — дип әйтәләр.

Газиз дин кардәшләрем! Төрле илләрдә яшәүче ничәшәр йөз миллион мөселманнар кебек, без дә изге Корбан гаетенә шатланып, тәһарәт-госелләр алып, пакь, матур киемнәр киеп, хушбуйлар сөртеп, тәкбирләр әйтеп, Аллаһ йортына, ягъни мәчеткә җыелабыз.

Корбан сүзе нәрсәне аңлата соң? Корбан гарәпчәдән «якынаю», «якын булу» дип тәрҗемә ителә. Без бу мөбарәк бәйрәмдә мәчетләребездә Гает намазларын укып, Аллаһ ризалыгы өчен корбаннар чалып, игелекле гамәлләр кылып, Аллаһның рәхмәтенә якынаябыз, шуңа күрә бу олуг бәйрәмебезне шатланып каршы алабыз.

Корбан гаете барлык мөселманнарны берләштерә, якынайта, аларның күңелләре сөю, хөрмәт, бер-береңә миһербанлык һәм шәфкать хисләре белән тула. Бу мөбарәк көнне нәфрәт һәм ачулар юкка чыга, дошманлык һәм үпкә хисләре бетә.

Хөрмәтле мөселманнар! Аллаһның рәхмәтенә якынайта торган изге Корбан бәйрәме тирән мәгънәгә ия. Гарәпчә бу бәйрәм «Гыйд әл-әдха» дип атала. «Әдха» сүзе корбан чалу дигәнне аңлата. Мәгълүм булганча, корбан чалу йоласы безгә Ибраһим галәйһиссәлам белән Исмәгыйль галәйһиссәламнән калган. Без корбан чалганда, шуны аңларга тиеш: Аллаһы Тәгаләгә корбанның ите дә, каны да кирәк түгел, Аңа безнең тәкъвалыгыбыз гына ирешә. Бу хакта Аллаһы Раббыбыз Коръәндә үзе әйтә:

ن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَكِن يَنَالُهُ التَّقْوَى مِنكُمْ كَذَلِكَ سَخَّرَهَا لَكُمْ لِتُكَبِّرُوا اللَّهَ عَلَى مَا هَدَاكُ

وَبَشِّرِ الْمُحْسِنِينَ

«Аларның (корбанга чалынган хайваннарның) ни ите, ни каны Аллаһка түгел, Аңа фәкать сезнең тәкъвалыгыгыз гына ирешә» («Хаҗ» сүрәсе, 37 нче аять).

Тәкъва булган, Аллаһны чын күңелдән сөйгән кеше корбанны Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен чалып, гаиләсен, килгән кунакларын һәм күршеләрен, фәкыйрьләрне һәм мескеннәрне хөрмәт итә, аларның күңелләрен күтәрә. Шулай итеп, ул Аллаһның ризалыгына ирештерә торган гамәлләр кыла. Коръәни Кәримдә әйтелгән:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُواْ اتَّقُواْ اللّهَ وَابْتَغُواْ إِلَيهِ الْوَسِيلَةَ وَجَاهِدُواْ فِي سَبِيلِهِ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ

«Әй иман китергән кешеләр, гөнаһ эшләп, Аллаһ каршысында җавап бирүдән куркыгыз. Аңа якынлашырга юллар эзләгез, Аның юлында Җиһад кылыгыз (тырышыгыз): бәхеткә ирешерсез» («Маидә» сүрәсе, 35 нче аять).

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Әгәр без Аллаһ газабыннан котылырга һәм Аның рәхмәтенә ирешергә, бәхетле булырга телибез икән, алдагы аятьтә әйтелгәнчә, Ислам юлында тырышырга, ягъни Корбан бәйрәме көннәрендә генә түгел, ә һәркөнне гөнаһлардан сакланып, Аллаһка шөкрана кылып, күбрәк игелекле гамәлләр эшләп яшәргә тиешбез.

Аллаһы Тәгалә «Бәкарә» сүрәсенең 29-30 нчы аятьләрендә болай дип әйткән:

هُوَ الَّذِي خَلَقَ لَكُم مَّا فِي الأَرْضِ جَمِيعاً ثُمَّ اسْتَوَى إِلَى السَّمَاء فَسَوَّاهُنَّ سَبْعَ سَمَاوَاتٍ وَهُوَ بِكُلِّ شَيْءٍ عَلِيمٌ

وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلاَئِكَةِ إِنِّي جَاعِلٌ فِي الأَرْضِ خَلِيفَةً قَالُواْ أَتَجْعَلُ فِيهَا مَن يُفْسِدُ فِيهَا وَيَسْفِكُ الدِّمَاء وَنَحْنُ نُسَبِّحُ بِحَمْدِكَ وَنُقَدِّسُ لَكَ قَالَ إِنِّي أَعْلَمُ مَا لاَ تَعْلَمُونَ

«Җир йөзендә ни булса, Ул барысын да сезнең өчен яралтты. Соңрак күкне төзергә теләде һәм аны җиде кат итеп корды. Ул — барысын да белүче. (Ий Мөхәммәд) исеңдә тот, Раббың фәрештәләргә әйтте: «Мин Җир йөзенә (Адәмне) хәлифә (башлык, хуҗа) итеп яралтачакмын», — диде. Фәрештәләр әйтте: «Без Сине мактап, тәсбих әйтеп, Аллаһы Тәгалә кимчелекләрдән азат, дип, Сине зурлап торганда, Җир өстендә азгынлык кылачак һәм кан коячак бәндәңнеме хәлифә итеп куячаксың?» — диделәр. (Аллаһ аларга) әйтте: «Сез белмәгәннәрне һәрхәлдә мин беләмен», — диде.

Шул рәвешле, Аллаһы Раббыбыз Адәм балаларын күркәм сурәттә яралтып, акыл, зиһен биреп, барлык мәхлуклардан өстен кылган. Аллаһы Тәгалә җир өстендә һәм астында булган байлыкларны, судагы хисапсыз күп балыкларны, бөтен җан ияләрен безгә буйсынучы, итагать итүче итеп яралткан. Безгә, Адәм балаларына, бернинди мәхлукка бирелмәгән хәлифә дәрәҗәсе бирелгән. Инде Аллаһ Раббыбыз безне шундый олуг нигъмәтләр белән бүләкләгәннән соң, безгә зур гына вазифалар, бурычлар йөкләгән. Коръән Кәримдә «Тәхрим» сүрәсенең 6 нчы аятендә адәмнәр өстендәге олуг вазифаларның кайберләре искә алына. Шул вазифаларны үтәмәүчеләр каты газапка дучар булачаклары турында белдерелә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا قُوا أَنفُسَكُمْ وَأَهْلِيكُمْ نَارًا وَقُودُهَا النَّاسُ وَالْحِجَارَةُ

Әй, иманлы бәндәләр, үзегезне, гаиләгезне уттан саклагыз. Ул утның утыны кешелек вазифаларын, кешелек бурычын үтәмәгән адәмнәр булыр.

Шулай итеп, Аллаһы Раббыбыз бу аять белән безгә белдерәдер ки, үзебезне һәм гаиләбезне дөнья, ахирәт бәхетсезлегенә сәбәп булган начар эшләрдән тыеп, җәһәннәм газабыннан сакларга куша. Өстебездә булган зур бурычларыбыз хакында Расүл әкрам галәйһиссәлам үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: «Әй, бәндә, синең өстеңдә Раббыңның хакы, нәфесең һәм әгъзаларыңның хакы бар һәм гаиләңнең хакы бар, һәрбер хак иясенә хакларын бир, вазифаңны үтә», — дигән.

Беренче вазифа — Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә каршында булган вазифа, ягъни дөньяны, бөтен галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһны тану, биргән барлык нигъмәтләренә шөкрана кылып, һәрвакыт, һәр җирдә Аллаһ хозурына барып, хисап бирәчәгебезне истә тоту.

Икенче вазифа — кешенең үзе хакындагы вазифа, ягъни Аллаһ биргән тән сәламәтлеген саклау. Авыру булса — дәвалану. Күп кенә тән авырулары дөрес тукланмаудан килә. Бүген без чамадан тыш күп ашыйбыз һәм эчәбез, ашказаннарыбызга ял бирмибез. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам ашказанын өчкә бүләргә кушкан: бер өлеше ризык өчен, бер өлеше — су, бер өлеше һава өчен (Тирмизи). Аллаһы Раббыбыз бу хакта Үзенең китабында да әйткән:

كُلُواْ وَاشْرَبُواْ وَلاَ تُسْرِفُواْ إِنَّهُ لاَ يُحِبُّ الْمُسْرِفِينَ

«Ашагыз, эчегез, ләкин исраф кылмагыз. Аллаһ исрафчыларны сөйми» («Әгъраф» сүрәсе, 31 нче аять).

Күп ашау кунак сыйлаганда һәм сәхәр вакытында гына дөрес санала. Без һәрвакыт дөрес туклануга игътибар итәргә тиеш, чөнки 50 процент авырулар ризыктагы матдәләр аша килә. Мәсәлән, шәригатьчә бугазланмаган хайваннарның итләрендә зарарлы матдәләр күп була. Ризыкны яхшы ният һәм фикер белән әзерләү, шулай ук мөһим булып тора. Сырхау килгәнче сәламәтлегебезнең кадерен белик.

Аллаһның Расүле галәйһиссәлам үзенең бер хәдисендә: «Пакьлек (чисталык) — иманның яртысы», — дигән (Мөслим, Тирмизи). Шуңа күрә суны еш кулланырга, һәрвакыт таһарәтле килеш йөрергә тырышырга кирәк. Су — яшәү чыганагы: суны никадәр күбрәк куллансак, шулкадәр сәламәтлегебез артачак. Ашаганчы һәм ашаганнан соң, бер чеметем тоз куллану — авыруның профилактикасы булып тора. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам, тәннең сәламәтлеген саклау өчен, корсакка ятып йокламаска, уң якка ятарга киңәш иткән.

Адәм баласының үзе хакындагы икенче бурычы — акылны гыйлем белән баету. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйткән: «Белем алу — һәрбер мөселман өчен фарыз (тиешле)», — дигән (Ибн Мәҗә).

Мөселман кеше, дөньяви гыйлемме, дин гыйлемеме — икесен дә тигез күреп өйрәнергә бурычлы, чөнки дөньяви гыйлем белән дини гыйлем, үзара бәйләнгән рәвештә, бер-берсен тулыландыра.

Адәм баласының үзе хакында өченче бурычы — күңелен, җанын тәрбияләп, начар сыйфатлардан арындырып, күркәм сыйфатлар белән бизәп, бөтен кешеләр белән дус, тату, тыныч торырга һәм игелекле гамәлләр кылырга тырышу. Расүл әкрам галәйһиссәлам әйткән: «Аллаһы Тәгалә сезне тышкы кыяфәтегез һәм матди байлыгыгыз буенча бәяләмәс. Ул сезнең күңелләрегезгә (калебләрегезгә) һәм сез кылган гамәлләрегезгә карый», — дигән (Табарани).

Икенче хәдис-шәрифтә болай дип әйтелгән:

«Белегез, кеше тәнендә бер ит кисәге бар, әгәр ул сәламәт булса, бөтен тән сәламәт булыр, әгәр ул авыру булса, бөтен тән авыру булыр. Белегез ки, ул ит кисәге — калебтер» (Бохари, Мөслим).

Бу хәдисләрдән күренгәнчә, динебез калебкә зур әһәмият биреп, аңа игътибарлы булырга боера. Һәр мөселман үз калебенә хуҗа булырга тиеш. Калебләребезне сафландыру — һәрбер мөселманның изге бурычы. Калебләрне өч төргә бүләргә мөмкин.

Беренчесе — иман белән нурланган калебләр. Алар — Аллаһка һәм Аның расүле Мөхәммәд галәйһиссәламгә бәйләнгән, Ислам шәригатенә буйсынган бәхетле калебләр.

Икенчесе — ширек һәм көферлек белән каралган калебләр. Алар — яшәү мәгънәсен аңламаган, бары тик матди, дөньяви ләззәтләргә бирелгән бәхетсез калебләр.

Өченчесе — гөнаһ белән пычранган калебләр. Аларга ия булган кешеләр беренче карашка иман нигезләрен кабул иткән булып күренсәләр дә, намаз, ураза кебек гыйбадәтләрне вакытында үтәмиләр яисә бөтенләй башкармыйлар. Шундый калебләр исерткеч эчемлекләр куллану, отыш уеннар уйнау, риба, ялган кебек гөнаһларга баткан.

Иң гүзәл калебләр — иман, Ислам нуры белән нурланган, күркәм гамәлләр белән бизәлгән һәм һәртөрле гөнаһтан сакланган сөенечле калебләр. Аларга ия булучылар ике дөньяда да бәхеткә ирешәчәкләр. Шуңа күрә мөселман һәрвакыт һәм һәр урында калебне каралта торган гамәлләрдән ерак торырга тырыша. Киресенчә булса, ул үзен олы куркынычка илтә. Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйткән: «Мөэмин

бер гөнаһ эшләгән вакытта, аның калебендә бер кара тап барлыкка килә. Әгәр ул тәүбә итеп, бу гөнаһтан ваз кичсә, аның калебе пакьләнә. Әгәр ул тәүбә итмәсә һәм гөнаһлы гамәлне кылуны дәвам итсә, аның калебендә кара таплар саны арта һәм калебе каралана», — дигән (Ибн Мәҗә).

Түбәндәге аятьләрне истән чыгармыйк:

قَدْ أَفْلَحَ مَن زَكَّاهَا

وَقَدْ خَابَ مَن دَسَّاهَا

«Җанын пакь тоткан кеше морадына (сәгадәткә) ирешәчәк. Вөжданын кер каплаган кеше, әлбәттә, хәтәр зыян күрәчәк» («Шәмес» сүрәсе, 9-10 нчы аятьләр).

الا بِذِكرِ اللهِ تَطمَئِنّ القلوبُ

«Мәгълүмдер ки, Аллаһ турында уйлаганда, Аны зекер иткәндә, күңелләр рәхәт тынычлыкка ирешә» («Рәгыд» сүрәсе, 28 нче аять).

يَوْمَ لَا يَنفعُ مَالٌ وَلَا بَنَون إِلَّا مَنْ أَتَى اللهَ بِقَلْبٍ سَلِيمٍ

«Ул Көнне мал да, угыллар да файда китермәс. Әмма Аллаһка саф күңел белән инанганнар бәхетле булыр» («Шөгарә» сүрәсе, 88-89 нчы аятьләр).

Мөхтәрәм мөселманнар! Шуны һәрвакыт истә тотыйк: изге гамәлләребез Аллаһ тарафыннан кабул булсын өчен, калебләребез иманнан башка ихласлык белән дә бизәкләнгән булырга тиеш. Күпсанлы изге гамәлләрне ихлассызлык белән үтәүгә караганда, азсанлы гамәлләрне ихласлык белән кылу күпкә яхшырак. Бу турыда бөек ислам шагыйре, фикер иясе Җәләлетдин Руми (Аллаһның рәхмәтендә булса иде) әсәреннән бер кыйсса сөйләп үтәсем килә.

Кешеләр үзләренең җитәкчеләренә аларның зур территорияләр белән идарә итә белүләре өчен генә түгел, ә халыкка эчкерсез мөнәсәбәтләре, күркәмлекләре өчен илтифат иткән заманда, еш кына Багдадка (башкала) бүләк яки яхшы сүз белән җитәкчегә үзләренең хөрмәтләрен һәм рәхмәтләрен тапшырырга бара торган булганнар. Бервакыт бер фәкыйрь дә үзеннән бүләк тапшырырга уйлаган, ләкин озак уйланулар һәм эзләнүләр нәтиҗәсендә, үзендә берниндн кыйммәтле нәрсә дә тапмаган. Инде өметен өзеп, ул үзенең бердәнбер байлыгы — кырые кителгән, ләкин әле кулланып була торган иске чүлмәкне искә төшергән. Ул аңа үзенең коесыннан су тутырган һәм юлга чыккан.

Багдад юлында берәү очрап, фәкыйрьдән кая һәм ни өчен юл тотуы турында сораган. Җавапны ишеткәч, сораучы: «Тыңла әле, хакимдә күпме телисең, шулкадәр су бар, хәтта синең коеңдагы су да аныкы!» — дигән. Фәкыйрь аптырап калган, ләкин элекке ниятен саклап: «Мин гади кеше, кыйммәтле бүләгем булмаса да, җаным аңа мәхәббәт белән тулы һәм мин аңа бу суны булса да бүләк итү теләге белән янам», — дип җавап биргән.

Ул юлын дәвам иткән һәм исән-имин килеш солтан сараена килеп җиткән, үзенең бүләген тапшырган, аны хөрмәт һәм кунакчыллык белән каршы алганнар. Өйгә кайтырга җыена башлагач, солтан да аның бүләгенә каршы бүләк бирергә теләгән: «Синең бүләгеңнең тышкы яктан нинди булуы мөһим түгел, — дип әйткән хаким, — аның чүлмәген алтын белән тутырыгыз!» — дигән.

Адәм балаларының өченче вазифасы — гаиләсе, ата-анасы, туган-тумачалары хакындагы вазифасы. Гаилә турында шуны әйтергә кирәк: бөек динебез аның һәрбер

әгъзасына күп кенә вазифалар йөкләгән. Гаиләнең һәр әгъзасы үз вазифаларын төгәл үтәсә, шулвакытта гаилә нык булачак, шуңа күрә әлеге вазифаларны белү генә җитми, аларны җиренә җиткереп үтәргә дә кирәк. Ул вазифалар түбәндәгеләр:

— гаилә башлыгы буларак, ир кеше бәхетен һәм сөенечен үз гаиләсендә генә эзләргә, башка гаилә әгъзаларыннан җитдирәк һәм төплерәк булырга, үз гаиләсен кирәк нәрсәләр белән тәэмин итәргә һәм ислам буенча яшәргә бөтен шартлар тудырырга тиеш;

— хатын-кыз, иң беренче чиратта, иренә карата булган вазифаларны үтәргә тырышырга, аны үз мәхәббәте, йомшаклыгы, игътибарлылыгы белән бүләкләргә һәм, әлбәттә, гаиләнең намусын һәм шәрәфен сакларга тиеш;

— ир һәм хатын якты чырайлы, тәмле телле, бер-берсен аңлап, хөрмәт итеп яшәргә, гаилә серләрен тышка чыгармаска, нинди дер аңлашылмаучанлык, каршылык килеп чыкса, бер-берсенә юл куярга, кирелек күрсәтмәскә тиеш;

— ата-ана үз балалары өчен күркәм үрнәк булырга, матди һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тиеш. Алар һәрбер балага гадел булырга, начар дуслардан, хәрам гамәлләрдән сакларга, яхшы белем һәм тәрбия бирергә, киләчәктә үзләренә күркәм холыклы тормыш иптәшләрен табарга ярдәм итәргә тиеш;

— балалар, үз чиратында, әти-әниләрен хөрмәт итәргә, тел белән дә, гамәлләре белән дә рәнҗетмәскә һәм үлемнәреннән соң да онытмыйча, алар өчен дога кылып торырга тиешләр.

Алда әйтелгән кагыйдәләр буенча яшәгән гаилә, иншаллаһ, нык, сәламәт һәм бәхетле булачак.

Туган-кардәшләребез — безнең өчен ата-аналарыбыздан соң иң якын кешеләр, шуның өчен алар белән һәрвакыт әдәпле һәм мәрхәмәтле булырга тырышыйк. Алар хакында сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйткән: «Ризыгы киң һәм гомеренең озын булуын теләгән кеше туганнары белән элемтәне өзмәсен», — дигән (Бохари, Мөслим).

Газиз дин кардәшләрем! Вәгазем ахырында сезне бер риваять белән таныштырып үтәсем килә.

Бөек галим Җүнәйд Багдадига (Аллаһы Тәгалә аны Үзенең рәхмәтеннән аермаса иде) 7 яшь булганда, абыйсы Сарий Сакати аны үзе белән хаҗ гыйбадәтен кылырга алып барган. Хәрам мәчете («Изге мәчет» дигән сүз) эчендә, ягъни Кәгъбәтулла янында төрле мәсьәләләр буенча сөйләшүләр барган, шуларның берсе шөкрана кылу турында булган. Анда катнашкан һәр шәех бу турыда үз белем-тәҗрибәләре белән уртаклашкан. Сарий Сакати Җүнәйдкә борылып, аңа шөкрана турында үз фикерен белдертергә кушкан. Бераз уйлагач, 7 яшьлек Җүнәйд түбәндәге гаҗәеп матур җавап биргән: «Шөкрана кылу — ул Аллаһы Тәгалә каршында гөнаһлы булмау, Аның нигъмәтләрен файдаланып, шулар белән гөнаһ кылмау», — дигән.

Мөхтәрәм җәмәгать! Бу җаваптан күренгәнчә, Аллаһка шөкрана кылу, Аңа рәхмәт әйтү — ул намаз уку, ураза тоту, Коръән уку кебек гыйбадәтләр белән генә чикләнми. Без Аллаһы Раббыбыз биргән әгъзаларыбыз белән дә гөнаһ эшләмәскә тиеш. Күзебезне хәрам булган нәрсәләрдән, телебезне — гайбәттән, ялганнан, яла ягудан, буш сүзләрдән саклыйк. Телләребез белән күбрәк Аллаһны искә алыйк, файдалы, дөрес сүзләр сөйлик. Карыныбызны хәрам ризыклардан, кулларыбызны хәрам гамәлләрдән, аякларыбызны Аллаһның ачуын китерә торган җирләргә барудан саклыйк. Хәдис-шәрифтә болай диелгән: «Файдасыз эшләрдән качу — яхшы мөселманның билгесе» (Тирмизи).

Аллаһы Тәгалә барчабызга да ихлас шөкрана кылучылардан булырга, күңелләребездә булган барлык изге ниятләребезгә, максатларыбызга ирешергә, чалыначак корбаннарыбызның бәрәкәтен күрергә, бу дөньяда һәм ахирәт тормышында да бәхетле булырга насыйп итсә иде. ■

ГАЛИӘСГАР
ГАФУРОВ-ЧЫГЪТАЙ.
САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР. «ТУТАМ», «ИСАБӘТ» ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛӘР. —
Казан: «Ихлас», 2013. — 528 б.

Башлыча Чыгътай псевдонимы белән иҗат иткән, 1907-1908 һәм 1913-1915 елларда татар вакытлы матбугаты битләрендә әсәрләре, мәкаләләре, публицистик язмалары шактый еш күренгән татар әдибе, журналист, дин эшлеклесе Галиәсгар Гафуров (1867-1946) исеме бүгенге укучыларга аз мәгълүм. Аның Р.Фәхретдин, Ф.Кәрими, Н.Ашмарин, Г.Тукайлар тарафыннан уңай бәяләнгән «Тутам» повестен профессор М.Гайнуллин моннан кырык еллар элек хәзерге татар язуында бастырып чыгарган иде. «Татар әдәбияты һәм җәмәгатьчелек фикере тарихында үзенчәлекле урыны бар» (М.Гайнуллин), дип саналса да, Чыгътайның күләмле һәм катлаулы язма мирасы өйрәнелми кала бирә, хәтта аның әсәрләренең библиографиясе дә төзелмәгән әле.

2007 елның көзендә, язучының тууына 140 ел тулуга багышланган конференциядә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре: «...аның әдәбиятта биләп торган урыны иң түрдә, язучының әсәрләрен кабат нәшер итү фарыз» (Диндаров И. Каберенә эзләр суынмас / http: // adiplar.ru/chigtay2.htm), — диеп, XX гасыр башында Фатих Кәриминең «Кырымга сәяхәт»ендә (1903) язылган: «...Галиәсгар әфәнденең бериш әсәрләре бардыр ки, басылып таралулары бик матлубтыр (сораладыр)...» — дигән сүзләрен яңарталар.

Ниһаять, 2013 елда Галиәсгар Гафуров-Чыгътайның беренче җыентыгы — «Сайланма әсәрләр»е дөнья күрде. Ул Зөфәр Рәмиев һәм Гүзәл Газизуллиналар тарафыннан төзелгән. Кереш сүздә Чыгътайның XX гасыр башы татар мәгърифәтчелеге

дөньясында тоткан урыны, Габдулла Тукай белән булган иҗади бәйләнешләре киң яктыртыла, авторның тәхәллүсләре турында мәгълүмат бирелә. Җыентыкта авторның тәүге тапкыр беренче кисәге 1902 елда Оренбургта, икенче кисәге 1908 елда Казанда «Бәянелхак» типографиясендә басылган «Тутам» повесте, 1908 елда Казанның «Шәрекъ» матбагасында балалар өчен нәшер ителгән «Мәче белән Төлке» әкияте, 1909 елда Казанда Харитонов лито-типографиясендә басылып, татар вакытлы матбугатында зур шау-шу куптарган «Исабәт» исемле публицистик хезмәте, 1914 елда «Мәгариф» нәшриятында басылган «Хан Баскак» хикәяте, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана торган «Галинең алтмыш еллык истәлеге. 1875-1935» дигән автобиографик очеркы урын ала. Гүзәл Газизуллина тарафыннан язылган «Тутам» повестенда хатын-кыз мәсьәләсенең бирелеше» мәкаләсе, Татар энциклопедиясеннән алынган, А.М.Ахунов тарафыннан язылган Чыгътайның биографик мәгълүматы һәм әсәрләренә библиографик белешмә язучының шәхесен һәм иҗатын киңрәк күзалларга ярдәм итә. Әлеге хезмәттә Чыгътайның шәхси архивыннан кульъязма үрнәкләр, үзе эшләгән «Фән һәм дин» журналының титул битләре күчермәсе, «Тутам» повестеның тышлыгы рәсеме, Аксубай районындагы туган авылы Яңа Ибрайны (Чәтрәнне), авыл мәчетен, музее, мәктәбе, әдипнең каберен сурәтләгән фотолар да урын алган.

З.Рәмиев «Чыгътай иҗаты турында бер-ике сүз» мәкаләсендә, әдәбиятчыларга үз теләген җиткереп, болай ди: «... бу язучы, публицист, дин эшлеклесенең (1921-1923 елларда авыл мулласы) иҗат мирасын киләчәктә барларга, бүгенге карашларга туры килеп бетмәгән якларын да яшермичә укучыларга кайтарырга иде». Әлеге җыентык Чыгътайның шактый бай һәм кызыклы мирасын бүгенге көн укучысына җиткерүдә беренче адым, әйтергә кирәк, уңышлы адым булып тора. Киләчәктә дә бу мирасны өйрәнү дәвам итсен иде.

Алия Мөбарәкшина,
Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты аспиранты

Индекс 54132
70275

Халкыбыз тарихы, әдәби, мәдәни мирасыбыз, тәнкыйди фикер һәм заманча караш – барысы да «ЧЫН МИРАС» журналында



ИНДЕКС

ТАТАРСТАНДА – 54132

ЧИТ ТӨБӘКЛӘРДӘ – 70275

БЕЗ МИРАСЛЫ ХАЛЫК. «ЧЫН МИРАС» БЕЛӘН БЕРГӘ БУЛЫГЫЗ!